
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕНЕҢ**
**Ш.МӘРҖАНИ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАРИХ ИНСТИТУТЫ**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕНЕҢ**
**Г.ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСИТУТЫ**
**ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ**
**БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
**«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ МӘГАРИФ ИДАРӘСЕ» МУНИЦИПАЛЬ КАЗНА УЧРЕЖДЕНИЕСЕ**
**«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ 5 НЧЕ ГИМНАЗИЯСЕ»**

# IV Регионара Афзал Шамов Укулары

**“КЕШЕ БИТ МИН, ҖАНЫМ БАР, ҖАНЫМ БАР, ВӨҖДАНЫМ БАР”**
**А.ШАМОВ**




**31 нче март, 2017 нчы ел**
**Яшел Үзән шәһәре**

## Эчтәлек


**Секция: А.Шамовның иҗат мирасы.** ................ 4

«Танайда - гади бер авылда, Шамов дигән язучы туган... » ................ 4

**“Афзал Шамовның балачак истәлекләреннән” һәм иҗатына күзәтү** ................ 10

**Ризаэддин Фәхреддиннең “Тәрбия” китабы һәм Афзал Шамовның “Ата күңеле” әсәрендә рухи-әхлакый тәрбия бирүдә аталарның роле** ................ 19

**Афзал Шамовның “Рәүфә” повестендә тел-сурәтләү чаралары** ................ 22

**Афзал Шамов – төбәгебез горурлыгы** ................ 25

**“Афзал Шамов музеена сәяхәт”** ................ 29

**Секциянең исеме: “Каләм! Калбеңдә ни сер бар, гаян ит. Килеп-кичмешләр әхвален бәян ит!”** ................ 37

Үкенү ................ 37

**Илем- ак күгәрченем** ................ 37

**Гомернең мизгелләре** ................ 38

**Татарлар без!** ................ 39

**Бүре белән куян (мәсәл).** ................ 40

**Якташым-горурлыгым!** ................ 41

**Суган нигә ачы?** ................ 41

**Кышның салкын айлары.** ................ 42

**Габдулла Тукайга** ................ 42

**Беренче адымнар** ................ 43

**Әбием мәкальләре.** ................ 44

**Уйлану.** ................ 45

*ПЕСИКӘЙ* ................ 46

**Туган ягым** ................ 46

**Мин-табигать баласы** ................ 46

**А.С.Пушкинның “Евгений Онегин” романыннан “Татьянаның Онегинга хаты” тәрҗемәсе** ................ 47

**Секциянең исеме: Татарстан Республикасының яшь язучылары һәм шагыйрьләре иҗаты** 48

**Шагыйрь Рифат Сәлах - гармунчылар нәселеннән** ................ 48

**Күңел бөртекләрен күккә сибәм!**.....61
**(Яшь шагыйрь Рифат Сәлах)**.....61
**РИФАТ СӘЛАХНЫҢ ШИГЪРИ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ТЕЛ-СУРӘТЛӘҮ ЧАРАЛАРЫ КУЛЛАНЫЛЫШЫ**.....64
**Татарстанда туып, Германиядә яшәүче яшь шагыйрә – Гөлназ Вәлиева**.....71
Фәнил Гыйләҗев иҗатына күзәтү.....72
**Секциянең исеме “Дәрестән тыш эшчәнлектә яшь шагыйрьләр һәм язучылар иҗатын файдалану”.**.....75
Рифат Сәлах – иҗатында туган як.....75

**Афзал Шамов исемендәге төбәкара фәнни-гамәли укулары 2017 ел**

## Секция: А.Шамовның иҗат мирасы.

*Автор: Низамиева Айсылу Рәмис кызы,Мөхетдинова Динә Хәлил кызы*
*Фәнни җитәкче:Садыйкова Фәнзия Мәүлит кызы,Беренче квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
*МБОУ «Яр буе Морквашы гомуми белем бирү мәктәбе,Югары Ослан муниципаль районы,Татарстан Республикасы, 8 сыйныф*

«Танайда - гади бер авылда, Шамов дигән язучы туган... »

(Күренекле якташыбыз А. Шамовка багышлана)

эчтәлек

I.Кереш өлеш…………………………………………………....…..…..
II.Төп өлеш
1. язучының тормыш юлы һәм иҗаты…………………………...
2. каеннарың да сине сагына……………………………….......
3. фронт хатлары…………………………………………..........
III. Йомгаклау…………………………………………..……........
IV. Кулланылган әдәбият……………………………...……........

**Кереш**

Ак каеннар , исемә төшерәсез
Балачакның газиз көннәрен.
Туган авылым Танай бакчасында
Энем үстергән каеннарын.
( Нурсәйлә Ишимова.)

Кеше гомере шәм кебек бит ул. Күз ачып йомганчы яна да бетә. Кемдер кыска гына вакыт эчендә эзсез югала, ә кемдер исемен мәңгеләштереп калдыра.

Күренекле татар язучысы Афзал ага Шамов әнә шундый бөек шәхесләрнең берсе. Нинди кеше соң ул? Олы гәүдәле, шактый озын буйлы, һәркемне сокландырырлык кара бөдрә чәчле, баһадир кыяфәтле, күркәм йөзле, тыныч табигатьле кеше ул. Язучы-әдип, зур художник Шамов әдәбиятыбыз түрендә талантлы әдәби әсәрләр язганлыгы белән генә түгел, бәлки кешелек сыйфатлары өчен дә күренекле урын алып тора.

Күренекле якташыбызның Афзал Шамов иҗатына багышлап эзләнү эшләре башлап җибәрдем.

Эзләнү максаты: Афзал Шамов безнең якташыбызның тормыш юлы, иҗаты белән танышу, материаллар туплау. Музей һәм аның хезмәтләре белән танышу, истәлекләр буенча эзләнү.

Эзләнү объекты: А.Шамовның тормыш юлы, музее.

Проблема: Язучының тормыш һәм иҗат юлын, музеен өйрәнү; әдәбиятта булмаган истәлекләрен укучыларга күрсәтеп бирү.

Эзләнү мәсьәләләре: куелган максаттан чыгып хәл ителәсе мәсьәләләр:

-эзләнү проблемасына багышланган фәнни-методик әдәбиятны өйрәнү;

- әдәбиятта булмаган истәлекләрен укучыларга күрсәтеп бирү;

- якташыбызның тормыш юлы, иҗаты белән танышу, материаллар туплау;

Эзләнү методы: язучының туган авылының материалларын туплау , музее белән танышу, туган -тумача, кардәш-ыру турында истәлекләр тыңлау.

Эзләнү актуальлеге:

“...Кеше бит мин, җаным бар, җаным бар, вөжданым бар”. Бу – Афзал ага сүзләре. Кеше. Җан. Вөждан. Шушы төшенчәләрнең тирән мәгънәсен, бер-берсеннән аерылгысызлыгын күңеленә салган кешенең дөрес сукмактан тайпылмаслыгына, хилаф гамәлләр кылмаслыгына чын күңелдән инанып әйткәндер әдип, үзеннән соң туар

буыннарга барып җитәчәген белеп әйткәндер?! Чынлап та, бүгенге көндә бу төшенчәләр барыбызны да борчый. Укытучы, ата-ана һәр баланың вөҗданлы, йортыбызга, илебезгә файда китерерлек кеше булып формалашуын тели.

Авыл уртасында биек-биек булып үскән зифа бөдрә каеннар, безгә Афзал абый истәлеген хәтерләтәләр. Шамов исән вакытта алар тугызау иде. Ә бүгенге көндә алты каены исән. А.Шамов исемендәге мәктәп янында да "Шамов каеннары бар икән бит..." (бу каеннар укучылар тарафыннан утыртылган)

Мин шушы эзләнү эшем белән халкымның олы язучыга-олы хөрмәт күрсәтүен тагы бер кат расладым.

А.Шамов 90 яше тулган көнне күрә алмыйча, 1990 елда вафат булды.

Афзал Шамов татар әдәбияты тарихында тирән эз калдырган зур язучы, әдәбиятка чын йөрәктән бирелгән кеше иде. Каюм Насыйри туган төбәктә дөньяга килгән А.Шамовның татар галәменә олуг язучы булып калкып чыгуы һич тә очраклы түгелдер.

**Язучының тормыш юлы һәм иҗаты**

Безнең якташыбыз Афзал Шиһабутдин улы Шамов, 1901 елның 4 мартында Яшел Үзән районы Татар Танае авылында, хәлле крестьян гаиләсендә туа. Гади авыл малаеның балачагы капка төбендәге куе яшел чирәмдә уйнап, әти-әнисенә булышып үтә.

Ун яшенә кадәр ул әти-әнисе белән бергә бабасы йортында үсә. Бабасының гаиләсе авылдагы иң зур патриархаль гаиләләрнең берсе була. Шамовны бик кечкенәдән үк эшкә өйрәтә башлыйлар. Җиде яшеннән инде ул әнисе белән уракка чыга башлый.

Бераз үсә төшкәч, сука да сукалый, печән дә чаба, урак та ура, ашлык та суга – кыскасы, чын авыл егетенә хас булганча, хуҗалыктагы барлык эшләрне башкарып тора.

Алты яше тулгач, кулына "Иман шарты"исемле кечкенә генә, юка гына китап алып, апалары белән бергә мәзин өенә укырга йөри башлый.

1914-1915 нче елларда Танайдан ерак түгел Кулабердино исемле рус авылындагы башлангыч мәктәпнең беренче сыйныфында укый. 1915-1916 нчы елларда Акъегет авылындагы русча-татарча мәктәптә белем ала.

1917 нче елның сентябреннән алып 1918 нче елның февраленә кадәр Шамов Казандагы «Касыймия» мәдрәсәсендә сигезенче сыйныфта укый. Бу мәктәп белемгә сусаган Шамовка бик күп белем бирә. Дәресләрдән соң Афзал ага, ул заманда Казанда бердәнбер булган «Шәрык» китапханәсенә барып, төрле-төрле китаплар укый.

Афзалның беренче татарча китап белән танышуы исә Танайда үткән балачагының хәтердә мәңге җуелмас бер хатирәсе булып сакланган.

"...Я алла, татарча китап бит бу! Мин һәм авыл малайлары сөйләшә торган телдә. Мондый китапны әле минем беркайчан да күргәнем юк иде, хәтта андый китапларның барлыгын үземнең кечкенә акылым белән башыма да китерә алмый идем," –диячәк ул соңрак үзенең истәлекләрендә. Булачак әдипне шулай сихерләгән, бөтен дөньясын оныттырган китап Шәриф Саттаровның "Тәгассеб вә җәһаләт корбаны" исемле драмасы була. "...Туган телемдә миңа тел ачкычы биргән беренче һәм бер көнлек дәреслегем булды ул," –дип тә яза Афзал Шамов бу китап турында.

Китап укуга мәхәббәт уяту, китап уку аркылы рухи байлык, әхлак, мәрхәмәтлек кебек сыйфатларны үстерү, туган телебездә милли тәрбия бирү бүгенге көндә төп максатыбыз.

Кечкенә генә китап, ә күпме хәзинә эчендә! Афзалның беренче китабы да аның тормышына зур үзгәрешләр кертә: "Шул көннән башлап мин авылыбыздагы кешеләрдән татарча китаплар эзләргә керештем. Тапканын берен тиз генә укып, кире кайтарып бирә идем." Бала күңелендә китап дигән могҗизага мәхәббәт уяна.

А.Шамовның бик күп хикәяләре укучыларга аң-белем, тәрбия бирүгә юнәлгәннәр. Шундый әсәрләрнең берсе-әдипнең башлангыч иҗатына караган "Суган" исемле хикәясе.

"...Сәлимнең анасы Гөлҗиһан апа түтәлдән яңа өзеп кергән яшел суганны тозга манып ашарга ярата. Ләкин быел алар суган утыртмыйча калганнар. Гөбенә елгасы буендагы колхоз бакчасында суган бик әйбәт уңган. Сәлимне бакчага каравылчы ярдәмчесе итеп алалар. Беркөнне Сәлим соң гына эштән кайта һәм итәгендәге суганны

сәкегә сала. Анасы рәхмәт әйтергә ашыкмый. Соңыннан суганның рөхсәтсез өзелгәнлеге ачыклана.” “...Их оятсыз, оятсыз! Бөтен авыл алдында йөземә кара яктың бит син. Кем малае? - Аның малае диячәкләр!” Гади генә хикәя, ләкин нинди тәрбия көченә ия ул. Дөреслек, үзеңнең әхлакый йөзеңне саклау, ата-ана йөзенә кызыллык китермәү - болар милли тәрбиянең дә нигез ташлары бит.

Моннан соң язылган хикәяләрендә дә Афзал ага яшь буынга тәрбия бирүне иҗатының үзәгенә куя, үз тормыш тәҗрибәсенә таянып, бу мәсьәләне еш кузгата.

Соңрак туган якларына кайтып, совет укытучылары әзерли торган курсларга йөри. 1918-1919 елларда әдип Татар Исламы авылында башлангыч мәктәптә белем бирә. Нәкъ менә шушы еллардан башлап, Шамов укытучы эшеннән тыш төрле җәмәгать эшләрендә катнаша башлый. Зөя өязе укытучылары тарафыннан төзелгән труппа составында пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә авылдан авылга йөреп, спектакльләр куя, әдәби кичәләр, концертлар оештыра.

Афзал Шамовта язу теләге шундый көчле була ки, ул 1919 ел башыннан Казандагы “Эш” газетасында авыл хәбәрчесе булып катнаша башлый. Хәбәрләрдән тыш зарисовкага тартышлы озынрак язмалар да бастыргалый. Озак та үтми “Анда...монда...” исемле шигыре дә басылып чыга. Ләкин ул шигырьләр күп язмый. (Барысы да берничә генә.) Икенче шигырен аның бөтенләй бастырмыйлар. Галиәскәр Камал белән Ибраһим Куди да Шамовка шигырь язарга киңәш итмиләр. Озак та үтми, Шамовның бер-бер артлы “Очрашу” һәм “Кызыл корбан” исемле хикәяләре дөнья күрә.

1920 елның август аенда әдип мәгариф инструкторлары әзерли торган курсларны тәмамлый алмыйча, үзе теләге белән гражданнар сугышына китә. Хәрби хезмәттә чакта, бигрәк тә фронтта, язарга мөмкинлекләр булмый диярлек. Тик күкрәгендә язучы уты кабынган шәхесне туктатып буламы соң? Юк, әлбәттә!

Кызыл армиядән исән-имин килеш кайтып, 1922 елның сентябрендә Шамов Казан дәүләт университеты рабфагына укырга керә. Анда укыган чакта, 1923 елдан башлап, яңадан нәсерләр, хикәяләр язу эшенә керешә. Шул елларда ул язучыларның Казандагы беренче әдәбият түгәрәген оештыруда катнаша. Бу түгәрәк ул чакта татар яшь әдипләрен һәм шагыйрьләрен берләштергән бердәнбер түгәрәк була.

Афзал Шамовның хикәяләре, нәсерләре “Кызыл шәрык яшьләре”, “Октябрь”, “Яшь эшче” журналларында басылып тора.

1926-1930 елларда әдип Мәскәүдәге Беренче дәүләт университетының әдәбият һәм сәнгать факультетында укый. Егерменче елларның икенче яртысында Мәскәүдә “Эшче” газетасы битләрендә көн саен булмаса да, көн аралаш Шамовның очерклары, фельетоннар, репортажлар , яңа чыккан китапларга рецензияләр басылып тора.

Афзал ага Шамовны язучы итеп таныткан һәм әдәбиятның олы юлына чыгарган “Рәүфә” повесте 1926 елда дөнья күрә. Галимҗан Ибраһимовның “Татар хатыны ниләр күрми” дә Гөлбану, Мәҗит Гафуриның “Татар йөзләре” ндә Галимә, Галиябануларга тиң образ –Рәүфә иҗат ителә.

Үз гомерендә Шамовка бер генә сугыш күрергә туры килми шул. 1943 елның гыйнварендә ул үзе теләп Бөек Ватан сугышына китә. Башта Калинин, аннары беренче Балтыйк буе фронтында чыгып килгән “Алга, дошман өстенә”, һәм Байкал арты фронтынның “Суворовча кысрыклау” газеталарында хәрби корреспондет булып эшли. Атнага ике тапкыр чыгып килә торган газета битләрендә Афзал Шамов алгы сызыктан хәбәрләр, яңалыклар, хикәяләрен бастыра.

1942 елның ноябрендә чыга башлаган “Алга, дошман өстенә” газетасының татар редакциясе 1295 километр юл үтә: Калинин, Ржев, Витебск, Кенигсберг һәм башка шәһәрләр аркылы. Шамов хәрби корреспондет булса да, үзе дә фронтта батырлыклар күрсәтә. Хәрби журналистның юллары кайдан гына үтми, кемнәр белән генә очраштырмый.

“Капитан Шамов, бер частьта эшен бетереп, ашыгып икенче бер частька китә. Бу көнне 30 нчы километр атлаганга һәм берничә төннәр йокы күрмичә эшләгәнгә күрә дә язучы яхшы ук арган була. Шуңа күрә дә ул, куе арыш арасына кереп, хәл аларга утыра. Язучы тарихи һөҗүм көннәрендәге тәэсирләр турында һәм үзенең язачак хәбәрләре,

хикәяләре турында уйлана. Ләкин кинәт шикле кыштырдау ишетелә. Капитан тиз генә кулына револьверын ала, һәм арыш арасыннан көнбатышка таба качып баручы бер төркем фашистларны күреп, башта беркадәр каушап кала. Ләкин шунда ук Афзал Шамов үзендә көч, гайрәт тоя, биек арышка ышыкланып килүче эре гәүдәле фрицларны якын ук җибәрә дә кинәт:

- Стой!-дип кычкыра. Аннары немецча:

- Кул күтәр!-дип боерык бирә һәм һавага атып җибәрә.

Язучы Афзал Шамов 7 немецны тиешле урынга илтеп тапшыра...”-дип яза 1944 елда Абдулла Әхмәт.

Әйе, шулай уйламаганда фронт газетасы корреспондеты үзе дә бик зур батырлык күрсәтә.

Нәкъ шушы елларда ул хөрмәт, сагыну, өмет хисе белән сугарылган хикәяләр иҗат итә. “Өзелгән кыллар”, “Көзге чәчәкләр”, “Дустым кабере янында” менә шундыйлардан.

“Дустым кабере янында” хикәясен Шамов авылдашы, дусты Нәсыйх Җәгъфәровка багышлый:

“ Дустым! Без синең кабереӊ янына үзебезнеӊ соңгы өметебезне җиткерергә, сиңа булган чиксез ихтирамыбызны, олылавыбызны белдерергә килдек. Без сине өч ел буенча күңелебезнең түрендә сакладык. Синең батырлыгың безне көрәшкә, дошман өстенә алып барыр, ул безнең рәхимсезлек һәм үч байрагы булыр. Синең исемеңне, синең батырлыгыңны без гомеребезнең иң соңгы минутына кадәр онытмабыз.”

Шушы кечкенә генә өзектә дә А.Шамовның олы җанлы, кеше эшен күрә белә торган, Ватаны, иптәшләре өчен гомерен бирергә әзер булган шәхес икәнен күрәбез.

Татар халкының батыр улы гомерендәге икенче сугыштан да исән-имин килеш 1946нчы елда әйләнеп кайта.

1949нчы елга кадәр ул иҗат эше белән генә шөгыльләнә. “Миңнур карт” (1946), “Озын мыеклы абый”(1947) шул елларда языла. Шамов шул ук вакытта тәрҗемә эшен дә дәвам итә. Аларның күләме 3000 бит – бу 10 томлык иҗади хезмәт дигән сүз.

1949-1950 елларда Шамов “Совет әдәбияты”(“Казан утлары”) журналы мөхәррире, 1958-1961 елларда Татарстан язучылар берлеге идарәсе рәисе булып эшли.

1962 елдан әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә, ләкин зур җәмәгать эшләрен дә башкара: өлкә комитетында, Югары совет депутаты, язучылар берлегендә, тынычлык саклау һәм гыйльми советта эшли. “Авыр көннәрдә”, “Ата күңеле”, “Хисаметдин абзый”, “Ике төп миләш”, “Яңгырлы кичтә” – бу чорда Афзал Шамов иҗат иткән әсәрләрнең кайберләре генә. Бу хикәяләрнең бик күпләре аң-белем, тәрбия бирү ягыннан игътибарга лаек. Тормыш тәрбиясенә таянып, яшь буынга тәрбия бирү мәсьәләсен әдип һәр әсәрендә күтәрә.

“Кечкенә кунак”(1982) хикәясендә Шамов икмәккә хөрмәт хисе тәрбияләү, аны кадерләп тотуның әһәмияте проблемасына зур игътибар бирә.

Әйе, вак, әһәмиятсез булып күренгән нәрсәләр дә киләчәк кешесен, яшь буынны тәрбияләүдә, кеше хезмәтенә хөрмәтле була белүдә зур урын тота.

“Якташым” хикәясендә исә бүгенге көннең тагын бер иң актуаль проблемасы – экология, табигатькә сакчыл караш тәрбияләү күтәрелгән.

Барысы да хәтердә, барысы да йөрәктә. Әдипнең үз сүзләре белән:

“Әйтегез, зинһар, безнең кайсыбыз ата-бабаларыбызның ил алдындагы мактаулы эшләре белән горурланмый? Кайсыбыз аларны үрнәк итеп, балаларыбызны, оныкларыбызны яхшы, тугры юлга кертеп җибәрергә тырышмый?

Изге юлда хезмәт иткән, халык бәхете өчен көрәшкән кешеләр белән бөтен авыл, бөтен колхоз, бөтен коллектив горурлана”

Бу сүзләр аның үзенә дә туры килеп тора.

**Каеннарың да сине сагына**

Син үлмәдең,
Ап-ак каеннарда
Яшел бөре булып яралдың…

Афзал Шамов турында истәлекләргә тотынуга, иң әвәл күз алдына Яшел Үзән районының Татар Танае авылының уртасында картаеп беткән каеннар рәте килеп баса. Шамов исән вакытта алар тугызау иде. Ә хәзер алты каены гына исән.

Каеннар, каеннар!.. Алар безнең якын урманда да, зиратта да, авыл уртасында да үсәләр.

Каеннар... Бу авыл уртасында биек-биек булып үскән зифа бөдрә каеннар, һәр көнне безгә Афзал абый истәлеген хәтерләтәләр. Шагыйрь Мәхмүт Хөсәеннең шул каеннарга багышлап язган " Ун баш каен" исемле шигырен искә төшерәм.

Танай дигән гади бер җирнең
Туфрагында йөреп киткәнсең
Хәтфә чирәмендә йөгергәнсең
Кизләвенең суын эчкәнсең.
"Иман шарты" монда ятланылган
Тормыш өчен күзең ачылган
Танаемда гади бер авылда
Шамов дигән язучы туган.
Танаемның горурлыгы син
Эшең белән аны данладың
Сокландырды синең якташларны
Тарих битләренә атлавың.

А.Шамов үзенә 10 яшь тулу уңаеннан, ун төп каен утыртырга булган (бабае Нәҗметдин киңәше белән). Каяндыр каен үсентеләре төпләп алып кайткан. Караңгы төшкәч кенә бик арып, әмма каеннарның унысын да утыртып, сулар сибеп, өйгә кереп егылган. Иртән чыгып караса – каеннар арасы да тигез түгел, бакча буйлап туры да утыртылмаган. Дәү әнисе Гайнивафа белән кәкре торганнарын турайтыбрак куйганнар.

1963нче елда А.Шамов (30 елдан соң) авылга кайткач үз каеннарын кочаклаган. Авыл халкы: "Афзал абый яшьлеген сагынып каеннарын кочаклап елады" дип сөйләгәннәр. Халык арасында А.Шамовка карата хөрмәт шулкадәр матур булган, ул каеннарга сугыш вакытында да кул тидерүче булмаган, ә башка урыннардагы утынга яраклы таллар һәммәсе дә киселгәннәр.

2001 нче елның 3 нче мартында үзенең танылган улы, татар әдәбияты күгендә балкыган иң зур йолдызларның берсе - Афзал ага Шамовның 100 еллыгын танайлылар аеруча зур бер горурлык хисе белән олылап билгеләп үтте. Мәркәзебез Казаннан әдипне хөрмәт иткән, иҗатына мөкиббән кунаклар бихисап кайткан. Алар арасында – ТР мәдәният министры Илдус Тарханов, ТР Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин, КДУ профессоры, тел белгече Гомәр ага Саттаров, язучылар Мөсәгыйт Хәбибуллин, Шаһинур Мостафин, шагыйрә Эльмира Шәрифуллина һ.б. бар. Юбилейны бәйрәм итәргә Яшел Үзәннән, Казаннан, Мәскәүдән үк Афзал аганың кыз-уллары, туганнары, эне-сеңелләре, якыннары кайту ямь өстенә ямь бирде. Иң әүвәле урта мәктәпкә Афзал Шамов исеме бирелү турында мемориаль такта куелды, аннары язучының музее ачылды.Тантана гаҗәеп җанлы һәм матур узды, ул мәдәният йортында әдәби-музыкаль кичә белән тәмамланды.Кичәдән соң А.Шамовның кызлары Миләүшә һәм Әлфия Шамовалар, улы Альфред һәм оныгы Айдар Шамовлар, апасының кызы Лалә Ишимова, сеңлесенең кызы Алсу Зия, энесе Салих Нәҗметдинов, сеңлесе Мәдинә Нәҗметдиноваларны сәхнәдән тирән алкышлар белән озаттылар.

Афзал Шамовның тууына 100 ел тулу уңаеннан татар әдәбияте өлкәсендә аеруча зур казанышларга ирешкән каләм ияләренә әдип исемендәге бүләк булдырылды. Бу хакта Яшел Үзән шәһәре һәм район хакимияте башлыгы Равил Зиннәтуллин карар чыгарды.

**Фронт хатлары**

Язучы А.Шамовның архивында Бөек Ватан сугышы чорына караган әллә никадәр документаль материаллар ята икән: унбиш фронт блакноты, 1943-1945 нче елларда Калинин һәм Беренче Балтик буе фронтларында язучы үзе очраткан һәм алар турында материаллары булган сугышчылар исемлеге (биш йөздән артык исем!), дистәләрчә фронт

газеталары, фронтта төшерелгән рәсемнәр, сугышчан листовкалар, гади солдат хатлары һәм фронтлардагы каләмдәш дусларыннан килгән хатлар...

Хат авторлары арасында – сугыш кырында ятып калганнары да, сугыштан соң арабыздан киткәннәре дә бар.

Солдат хатлары, гадәттә, гади карандаш белән язылганнар, кайберләре,еллар үтү белән, танымаслык хәлгә килгән. Бу хатларның тагы бер кимчелеге: аларның күбесе гарәп хәрефләре яисә яңалиф белән язылганнар. Бик күп хатлар вак, хәтта чамадан тыш вак хәрефләр белән төрле кәгазьләргә язылган.

Тылда калган язучылар да фронтовик язучылар белән һәрвакыт элемтәдә булган. Аларның хатлары исә яхшы кәгазьгә язылган, алары да бу архивта саклана.

Ләкин фронтовик язучылардан килгән хатлар әле башкаларыннан күбрәк тә. Сугыш елларында ут эчендә йөрүче татар язучылары бер-берләре белән даими рәвештә хат язышып торган. Бу хатлар язучыларның фронттагы тормышын, аларның уй-хисләрен, омтылышларын, каләмдәш иптәшләренең язмышларын, кайгыртучанлык тойгыларын, үзара иҗади дуслыкларын ачык күрсәтә. Болар- истәлекле, әдәби кыйммәткә ия хатлар...

Бу хатлар барысы да язучы Афзал Шамовка язылган.

Күренекле каләм остасы Ибраһим Гази язучы Афзал Шамовның якын дусты. Хатларны укыганда Афзал Шамовка И.Гази тарафыннан Әбҗәлетдин дип эндәшү күзәтелә. Моның кыска гына тарихы да бар икән. «Утызынчы елларның башында ул, минем фатирыма килгәч, әнинең миңа Әбзәлетдин дип эндәшүен ишетте дә, моны бик ошатып, мине шулай атап йөртә башлады, тик «з» хәрефен «җ» белән генә алыштырды » - дип сөйли Афзал Шамов.

Хатларның оригиналлары язучы Афзал Шамов архивында саклана. И.Гази хатлары А.Шамов һәм Ә.Шамова тарафыннан әзерләнде, искәрмәләр дә алар каләме белән язылды. Тарихи истәлек буларак, хатлар үзгәрешсез – редакцияләнмичә бирелә.

## Йомгаклау

Афзал Шамовның тормыш һәм иҗат юлы белән кызыксыну мине фәнни-эзләнү эшенә этәрде. Остазыбызның үткән юлын өйрәнү йөзеннән күп язучыларның эшләре белән танышырга туры килде. Язучыларның күбесе аның эшчәнлегенә сокланып, аның күпкырлы талант иясе булуына басым ясыйлар. Гамил Афзал олы тарихны халык хыяллары югарылыгыннан килеп бәяли, туган иле аңа фаҗигале һәм бөек үткәне белән газиз.

Еракларданкилде ул, гасырлар түреннән,
Риваятьләр, җырлар аһәңенә төренгән.
Елаган – көлгән,
Җиңгән – җиңелгән,
Алтын өмет дигән рухым минем.

Г.Афзал − чорыбызның халыкка иң якын, күп укыла торган әдибенә әйләнде. Ул − халкыбызның йөз аклыгы, горурлыгы. Әдип Г. Тукай исемендәге премия лауреаты.Гомер кичүләре... Һәркемнең тормыш юлында үзеннән соң кылган эшләре һәм аның үзе турында нинди дә булса истәлек кала. Гамил Афзал яшәгән канлы, газаплы 20 гасыр инде тарихка күчте, ул кичергән гомер исә һаман да дәвам итә. Ул кабаттан яшәрер, өлкәнәер һәм гел шулай кабатланып торыр. Чөнки ул кичергән гомер – батырлык үрнәге, безнең әдәбиятыбыз, сәнгатебез, рухыбыз, иманыбызның аерылгысыз бер өлеше.

Гамил Афзал туган җиргә, аның табигатенә, халыкның гореф-гадәтләренә, әхлак-кануннарына хөрмәт белән карап яшәде, Ватанга тугрылыклы булуын иҗатында ачык чагылдыра алды.

Әдәбият мәйданына юл ярганда, Гамил Афзалга бик зур ярдәм кулы сузган каләмдәш дусты Сибгат Хәким шагыйрь турында: "Аның бердәнбер максаты - халыктан алган шигъри таланты белән шул халыкка хезмәт итү", дип язган иде. Гамил Афзал үзенең бөтен иҗатында аны чолгап алган тирәлек, чорның матурлыгы, замандашының батырлыгы турында уйлана, аны аңларга омтыла. Тормыш кыенлыкларын үтеп, алга атлаган саен, шагыйрьнең көче арта, рухы ныгый бара.

А.Шамовның үз сүзләре белән әйткәндә: “Халык үзенең батыр улларын онытмый. Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый. Барысы да хәтердә, барысы да күңелдә, барысы да йөрәктә.” Күренекле язучы, Афзал ага Шамовның замандашы Г.Әпсәләмов сүзләре күңелгә  килә: “Ак чәчле, күркәм йөзле, тыныч табигатьле Афзал ага Шамов безнең әдәбиятның түренә яшенең өлкәнлеге, талантлы әдәби әсәрләр язганы өчен генә түгел, бәлки кешелек сыйфатлары өчен дә менеп утырды.”  Мин бу сүзләр белән килешәм: күренекле авылдашыбызның тормыш юлы да, ул тудырган әдәби геройлар да өйрәнүгә, үрнәк алуга лаеклы.

Нәтиҗәдә мин үз алдыма куйган максатыма ирештем. Халкым олы язучыга, олы хөрмәт күрсәтә. Халык яраткан язучысын онытмый!

**Кулланылган әдәбият**

1. « Казан утлары » 1991. №3. 157-159б.
1. Шамов А. Чын хикәяләр: Хикәяләр, очерклар, истәлекләр. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1986.
2. Шамов А. Зөя буенда: Очерк. – Казан: Таткнигоиздат, 1956.
3. «Ватаным Татарстан» газетасы, 20 март, 2001 ел.
4. «Мәгърифәт”газетасы,31 март,2001 ел.
5. “Мәдәни җомга”газетасы,16 март, 2001 ел.
6. «Яшел Үзән» газетасы, 23 март, 2001 ел.№35-36
7. «Шәһри Казан» газетасы, 2 март, 1990 ел.
8. «Мирас» Афзал Шамовка 90 яшь, 1990 ел.
9. «Сабантуй» газетасы, 2001 ел.
10. Музей материаллары

*Автор: Газизова Гөлия Наил кызы*
*Фәнни җитәкче – Әкрамова Наилә Рәшит кызы ,беренче категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
*МБББУ “Афзал Шамов исемендәге Татар Танае гомуми урта белем бирү мәктәбе”,7 сыйныф*

## “Афзал Шамовның балачак истәлекләреннән” һәм иҗатына күзәтү

Эчтәлек

I. Кереш өлеш……………………………………………………...
II. Төп өлеш.......................................................................
III. Йомгаклау……………………………………………………...
IV. Кулланылган әдәбият………………………………………
V. Кушымта……………………………………………………..

**Теманың актуальлеге:**Татар халкының тарихын, әдәбиятны тарихи яктан өйрәнмичә нигезле итеп белеп булмый. Телне саклау- татар милләтенең киләчәген саклау ул. Татар милләте үзенең татар теле аркасында көчле. Шуңа күрә татар халкы үзенең туган телен саклауга бөтен көчен, акылын бирергә тиеш.Телне саклаучы, аның үсешен тәэмин итүчеләр булып татар әдипләре тора. Якташыбыз Афзал Шамов иҗатын өйрәнү теманың актуальлеген тәшкил итә.

**Эшнең максаты:** Афзал Шамовның балачак истәлекләренә күзәтү,иҗади мирасын өйрәнү, татар әдәбияты тарихындагы күпкырлы эшчәнлеген ачыклау. Китап укуга мәхәббәт уяту, китап уку аркылы рухи байлык, әхлак, мәрхәмәтлелек кебек сыйфатларны үстерү, туган телебездә милли тәрбия бирү бүгенге көндә төп максатыбыз.

**Бурычлар:**

1. Афзал Шамовның тормыш юлын ачыклау.
2. А.Шамовның иҗатына  күзәтү ясау.
3. Татар әдәбиятына керткән өлешен бәяләү.

**Эзләнү ысуллары:**

-мәгълүмат туплау;
-мәгълүматны эшкәртү;

**Эзләнү объекты:** Афзал Шамовның балачак истәлекләре; иҗаты

**Кереш**

“...Кеше бит мин, җаным бар, җаным бар, вөҗданым бар”. Бу – Афзал ага сүзләре. Кеше. Җан. Вөҗдан. Шушы төшенчәләрнең тирән мәгънәсен, бер-берсеннән аерылгысызлыгын күңеленә салган кешенең дөрес сукмактан тайпылмаслыгына, хилаф гамәлләр кылмаслыгына чын күңелдән инанып әйткәндер әдип, үзеннән соң туар буыннарга барып җитәчәген белеп әйткәндер?! Чынлап та, бүгенге көндә бу төшенчәләр барыбызны да борчый. Укытучы, ата-ана һәр баланың вөҗданлы, йортыбызга, илебезгә файда китерерлек кеше булып формалашуын тели.

Авыл уртасында биек-биек булып үскән зифа бөдрә каеннар, безгә Афзал абый истәлеген хәтерләтәләр. Шамов исән вакытта алар тугызау иде. Ә бүгенге көндә (116 еллыгына) алты каены исән.

Афзал Шамов татар әдәбияты тарихында тирән эз калдырган зур язучы, әдәбиятка чын йөрәктән бирелгән кеше. Каюм Насыйри туган төбәктә дөньяга килгән А.Шамовның татар галәменә олуг язучы булып калкып чыгуы һич тә очраклы түгелдер.

А.Шамов – татар әдәбиятында, иң беренче чиратта, оригиналь проза әсәрләре – хикәяләр һәм повестьлар авторы буларак танылган язучы. Аның егерменче еллар татар авылы тормышына багышланган «Рәүфә» (1926), Гражданнар сугышы вакыйгаларына бәйле «Днепр буенда» (1927), «Бер мәхәббәт турында» (1933), тыныч тормыш шартларында гаилә кору һәм башка әхлакый мәсьәләләрне яктырткан «Ана» (1933), «Госпитальдә» (1938), «Туйда» (1938) кебек повесть һәм хикәяләре XX йөз татар әдәбиятының сәнгатьчә югары дәрәҗәдә эшләнгән матур үрнәкләре булып саналалар. Язучының Ватан сугышы чорында һәм сугыштан соң иҗат иткән хикәя һәм повестьлары да, зур-зур документаль очерк китаплары һәм күпсанлы публицистик мәкаләләре дә заманны чагылдыруда әһәмиятле әдәби елъязма хезмәтен үтиләр.

А.Шамов – озак еллар күптөрле җәмәгать эшләре алып барган язучы. 1931–1932 елларда ул Татарстан язучыларының оештыру комитетында җаваплы секретарь булып эшли. 1959–1963 елларда партиянең Татарстан өлкә комитеты әгъзасы, Татарстан Югары Советы депутаты, 1939 елдан 1974 елга кадәр Татарстан Язучылар берлеге идарәсе әгъзасы, Берлекнең рәис урынбасары, рәисе, идарә президиумы әгъзасы булып эшли, 1958–1959, 1962–1974 елларда СССР Әдәби фондының Татарстан бүлегенә җитәкчелек итә. Шулай ук ул РСФСР Язучылар берлеге идарәсендә (1958–1963), «Советская Россия» нәшриятында (1960–1975) һәм башка бик күп мәдәният оешмаларында әгъза буларак төрле җәмәгать эшләре алып бара.

Татар халык иҗатын һәм язма әдәби мирасны өйрәнү-барлау, аларны бастырып чыгару буенча да Афзал Шамов зур, әһәмиятле, гыйльми эшләр башкара.

А.Шамов – әдәби тәрҗемә остасы. Аның тәрҗемәсендә татар укучылары дөнья, рус классикасының, совет чоры рус язучыларының бик күп әсәрләре белән танышалар. Алар арасында Ф.Гладковның «Цемент» (1928), «Энергия» (1934) романнары, немец язучысы Э.Ремаркның «На западном фронте без перемен» («Көнбатыш фронтта үзгәреш юк», 1930) романы, А.Пушкинның «Капитанская дочка» («Капитан кызы», 1936), Н.Островскийның «Как закалялась сталь» («Корыч ничек чыныкты», 1936) һәм «Рожденные бурей» («Давылда туганнар», 1938), Ж.Верннның «Дети капитана Гранта» («Капитан Грант балалары», 1938), Н.Гогольнең «Старосветские помещики» («Борынгы алпавытлар», 1939), «Сорочинская ярмарка» («Сорочин ярмаркасы», 1939), А.Фадеевның «Разгром» («Тар-мар», 1939) әсәрләре, Л.Толстойның «Воскресение» («Яңадан туу», 1950) романы белән «Хаҗи Морат» повесте (1953), В.Панованың «Ясный берег» («Якты яр», 1950), С.Бабаевскийның «Кавалер Золотой Звезды» («Алтын Йолдыз кавалеры», 1951), А.Чехов, М.Горький хикәяләре һәм башкалар.

Гомеренең соңгы елларында А.Шамов истәлекләр, мемуар характерындагы документаль әсәрләр язу белән шөгыльләнә («Чын хикәяләр», 1986; «Соры мәче», 1990; «Картлар» («Гомерем таңында» исемле автобиографик повесть, 1999) һәм башкалар.

Ватан сугышы чорындагы батырлыклары һәм әдәби иҗат өлкәсендәге фидакарь хезмәтләре өчен А.Шамов Кызыл Йолдыз (1944), Хезмәт Кызыл Байрагы (1957), Октябрь Революциясе (1971) орденнары һәм бик күп медальләр белән бүләкләнә.

Ул 1990 елның 19 гыйнварындаКазандавафатбула.

А.Шамов – 1934 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

**“Афзал Шамовның балачак истәлекләреннән”**

“Мин, Афзал Шиһабетдин улы Шамов, 1901 елның 4 мартында Татар Танае авылында (элекке Казан губернасы Зөя өязе Әҗәл волосте) хәлле крестьян гаиләсендә туганмын.

Ун яшемә кадәр, әти-әнием белән бергә, бабам йортында үстем. Бабайның гаиләсе авылдагы иң зур патриархаль гаиләләрнең берсе иде.Дүрт улының өчесе өйләнгән,бала-чагалы, сакал-мыек үстергән,ир уртасындагы кешеләр (әтинең генә дә җиде баласы бар).Шулай да бабай улларының берсен дә үз башларына аерып чыгарырга теләми, хуҗалыкның таралуыннан, җимерелүеннән курка, гаиләсендә кашык күтәрүчеләр саны егермедән артса да, бергә яшәүне артыграк күрә.

Мин үземә 10 яшь тулу уңаеннан, ун төп каен утыртырга булдым (бабам Нәҗметдин киңәше белән). Каяндыр каен үсентеләре төпләп алып кайттым. Караңгы төшкәч кенә бик арып, әмма каеннарның унысын да утыртып, сулар сибеп, өйгә кереп егылганмын. Иртән чыгып карасам – каеннар арасы да тигез түгел, бакча буйлап туры да утыртылмаган. Дәү әнием Гайнивафа белән кәкре торганнарын турайтыбрак куйдык.

Бабайлар да, әтиләр дә мин туган елларда иген игү эше белән шөгыльләнгәннәр, үз иманаларына тигән җирләрне генә эшкәрткәннәр, читтән сатып алмаганнар.

Авылыбызның җире бик аз иде.Бер иманага өч басудагы җирне бергә кушып санасаң, бер дисәтинәгә тулмый иде.

«Күңелем белән балачагыма кайтып, андагы хатирләрне актарып карасам, һәрвакыт диярлек бабайның һәм абыйларның, шомарып беткән имән бүкәннәргә утырып,тәрәзә каршында,ян сәке буенда итек тегүләре күз алдыма килә. Алларында төрле зурлыктагы калыплар, күн кисәкләре, чүкечләр-кыскасы,итекчелек эшенә нәрсә кирәк булса бар да бар.

Тегүче абыйларым арасында әти генә юк.Нигәдер ул тегүчелекне яратмаган,бераз шөгыльләнеп караган да, тиз арада кул селтәгән, сәүдә эшенә тотынган. Ул,кызыл мал төяп,тирә-яктагы базарлардан базарларга йөри,кыш көннәрендә баштанаяк карга,буранга күмелеп, төн урталарында кайта,үзе белән бергә, толыбына,киез итегенә ияртеп,өйгә салкын алып керә.Без, бөтен идәнне тутырып йоклап яткан бала-чага,шул салкыннан уянабыз,әтинең сакал-мыегына берегеп каткан боз кисәкләренә гаҗәпләнеп карыйбыз”

“Ике кыш итек туздырып йөргәннән соң,кызлар арасында йөртүне инде яхшы түгел дип санап,мине, сигез яшендәге малайны,Танайдан унҗиде чакрым ераклыктагы Бузай авылы мәдрәсәсенә бирделәр. Ул да кадим мәдрәсәсе иде.Анда да “Иман шарты”ннан башладым. Мәдрәсәнең бердәнбер укытучысы булган муллага рәхмәт,ул әлифбаны ятларга түгел,ә хәрефләрне танырга,бармагым белән төртеп күрсәтеп укырга өйрәтте.

Шул җәйне безнең өйгә куе саргылт тышлы бер китап каяндыр килеп керде.Аны абыйлар базардан яисә Казаннан алып кайттылар булса кирәк.

Хәрефләре- “Иман шарты”ндагы төсле хәрефләр, әмма миңа бернәрсә дә сөйләми, бернәрсә дә аңлатмый торган мәгънәсез, җансыз хәрефләр түгел. Алар хәзер үк миңа нәрсәдер әйтергә, нәрсәдер сөйләргә торалар сыман.

Акъегет авылындагы мәктәп русча-татарча иде. Бу- мин укырга кергән беренче яңача мәктәп. Татарча дүрт классны, русча өч классны Мактау грамотасы белән бетердем.Укытучым-учитель вә мөгаллим Фатыйх Сәйфи-Уфалы иде. Заманындагы күренекле педагогларның берсе иде ул.Аның үзе төзегән грамматика дәреслекләре бар иде. Газета һәм журнал битләрендә оригиналь мәкаләләре белән катнаша иде. Андерсынның берничә әкиятен, татар теленә тәрҗемә итеп, бастырып та чыгарды.

Бу укытучының миңа бик зур тәэсире булды. Ул миңа нинди китаплар укырга кирәк икәнен киңәш итә, әгәр ул китаплар мәктәп китапханәсендә булмаса (мәктәпнең

бүләк китаплардан җыелган кечкенә генә китапханәсе бар иде), квартирасыннан алып килеп бирә иде.

1916 елны үзебезнең авылда яңача мәктәп ачылды, шәһәрдән мөгаллим килде. Шунда бер ел укыдым. Минем беренче татарча китап белән танышуым исә Танайда үткән балачагымның хәтердә мәңге җуелмас бер хатирәсе булып сакланган.

“...Я алла, татарча китап бит бу! Мин һәм минем кебек авыл малайлары сөйләшә торган телдә. Мондый китапны минем әле беркайчан да күргәнем юк иде, хәтта андый китапларның барлыгын үземнең кечкенә акылым белән башыма да китерә алмый идем...

Мине таңга калдырган, чамасыз гаҗәпләндергән китапны алып, чормага менеп утырдым бик азапланып, көчәнеп, хәрефне хәрефкә кушам, таныш иҗекләр, таныш сүзләр килеп чыга. Мин шатлыгымнан нишләргә белмим.

Чормага менгәндә мин укый белми торган идем, аннан укый белүче малай булып төштем, шатлык алып төштем.

Мине бу кадәр сихерләгән, бөтен дөньямны оныттырган китап нинди китап идее соң? Ул Шәриф Саттаровның “Тәгассеб вәҗәһаләт корбаны” исемле драмасы иде.” “Туган телемдә миңа тел ачкычы биргән беренче һәм беркөнлек дәреслегем булды ул,” –дип тә яза Афзал Шамов бу китап турында.

Кечкенә генә китап, ә күпме хәзинә эчендә! Афзалның беренче китабы да аның тормышына зур үзгәрешләр кертә: ”Шул көннән башлап мин авылыбыздагы кешеләрдән татарча китаплар эзләргә керештем. Тапканын берен тиз генә укып, кире кайтарып бирә идем.” Бала күңелендә китап дигән могҗизага мәхәббәт уяна.

**Иҗатына күзәтү**

Афзал Шамов – повестьлары, хикәяләре белән киң катлау укучыларга таныш өлкән язучыларның берсе. Сайланма әсәрләр китабында аның егерменче, утызынчы елларда иҗат ителгән, заманның таләпчән сынауларын узган, әдәби-эстетик әһәмиятен югалтмаган, укучыларны әле һаман да уйландыра, дулкынландыра торган әсәрләре (“Рәүфә”,”Днепр буенда”, ”Бер мәхәббәт турында”, ”Очрашу”, ”Туйда”, ”Кыз урлау”, ”Госпитальдә” һ.б.) урнаштырылган. Афзал Шамовның бик күп хикәяләре укучыларга аң-белем, тәрбия бирүгә юнәлгәннәр. Шундый әсәрләрнең берсе-әдипнең башлангыч иҗатына караган “Суган” исемле хикәясе.

“Сәлимнең анасы Гөлҗиһан апа түтәлдән яңа өзеп кергән яшел суганны тозга манып ашарга ярата. Ләкин быел алар суган утыртмыйча калганнар. Гөбенә елгасы буендагы колхоз бакчасында суган бик әйбәт уңган. Сәлимне бакчага каравылчы ярдәмчесе итеп алалар. Беркөнне Сәлим соң гына эштән кайта һәм итәгендәге суганны сәкегә сала. Анасы рәхмәт әйтергә ашыкмый. Соңыннан суганның рөхсәтсез өзелгәнлеге ачыклана.” “.Их оятсыз, оятсыз! Бөтен авыл алдында йөземә кара ягтың бит син. Кем малае? - Аның малае диячәкләр!” Гади генә хикәя, ләкин нинди тәрбия көченә ия ул. Дөреслек, үзеңнең әхлакый йөзеңне саклау, ата-ана йөзенә кызыллык китермәү - болар милли тәрбиянең дә нигез ташлары бит.

Моннан соң язылган хикәяләрендә дә Афзал ага яшь буынга тәрбия бирүне иҗатының үзәгенә куя, үз тормыш тәҗрибәсенә таянып, бу мәсьәләне еш кузгата.

“Дустым кабере янында” хикәясен Шамов авылдашы, дусты Нәсыйх Җәгъфәровка багышлый:

“ Дустым! Без синең кабереӊ янына үзебезнең соңгы өметебезне җиткерергә, сиңа булган чиксез ихтирамыбызны, олылавыбызны белдерергә килдек. Без сине өч ел буенча күңелебезнең түрендә сакладык. Синең батырлыгың безне көрәшкә, дошман өстенә алып барыр, ул безнең рәхимсезлек һәм үч байрагы булыр. Синең исемеңне, синең батырлыгыңны без гомеребезнең иң соңгы минутына кадәр онытмабыз.”

Шушы кечкенә генә өзектә дә А.Шамовның олы җанлы, кеше эшен күрә белә торган, Ватаны, иптәшләре өчен гомерен бирергә әзер булган шәхес икәнен күрәбез.

“Кечкенә кунак”(1982) хикәясендә Шамов икмәккә хөрмәт хисе тәрбияләү, аны кадерләп тотуның әһәмияте проблемасына зур игътибар бирә.

Әйе, вак, әһәмиятсез булып күренгән нәрсәләр дә киләчәк кешесен, яшь буынны тәрбияләүдә, кеше хезмәтенә хөрмәтле була белүдә зур урын тота.

“Якташым” хикәясендә исә бүгенге көннең тагын бер иң актуаль проблемасы – экология, табигатькә сакчыл караш тәрбияләү күтәрелгән.

«Мәңгелек ут янында уйланулар»ында ул болай яза: «Әгәр без Җиңү көнен, бу зур бәйрәмне Бөек Ватан сугышында һәлак булган туганнарыбыз, абыйларыбыз, этиләребез, бабаларыбыз истәлегенә һәр авылда, һәр районда, һәр шәһәрдә агачлар утыртып, бакчалар, парклар булдырып каршыласак, батырлар алдындагы бурычыбызның бер өлешен үтәгән булыр идек... Кулына көрәк тота алган һәр кеше, аларга багышлап, алар истәлеге итеп, үз бакчасына, үз өйләре алдына берәр төп агач утыртса да, яхшы булыр иде. Илебез матурланыр, яшеллеккә күмелер иде».

Афзал Шамовның уңай образлары-Ватанабызга, халыкка җаннары-тәннәре белән бирелгән гади кешеләр. Алар яшь Совет властен саклап калу, аны ныгыту өчен кулларына корал тотып көрәшәләр, утларга керәләр, халык бәхете өчен җаннарын фида итәләр; кешеләр арасында яңа мөнәсәбәтләр урнаштытырга, коммунистик моральне тормышыбызның үзгәрмәс кануны итәргә тырышалар, саф, пакь мәхәббәтне яклыйлар, сөяләр, сөеләләр...

А.Шамовның үз сүзләре белән әйткәндә: “Халык үзенең батыр улларын онытмый. Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый. Барысы да хәтердә, барысы да күңелдә, барысы да йөрәктә.”

“Әйтегез, зинһар, безнең кайсыбыз ата-бабаларыбызның ил алдындагы мактаулы эшләре белән горурланмый? Кайсыбыз аларны үрнәк итеп, балаларыбызны, оныкларыбызны яхшы, тугры юлга кертеп җибәрергә тырышмый?

Изге юлда хезмәт иткән, халык бәхете өчен көрәшкән кешеләр белән бөтен авыл, бөтен колхоз, бөтен коллектив горурлана”-дип әйткән ул.

Бу сүзләр аның үзенә дә туры килеп тора.

Күренекле язучы, Афзал ага Шамовның замандашы Г.Әпсәләмов сүзләре күңелгә килә: “Ак чәчле, күркәм йөзле, тыныч табигатьле Афзал ага Шамов безнең әдәбиятның түренә яшенең өлкәнлеге, талантлы әдәби әсәрләр язганы өчен генә түгел, бәлки кешелек сыйфатлары өчен дә менеп утырды.” Мин бу сүзләр белән килешәм: күренекле авылдашыбызның тормыш юлы да, ул тудырган әдәби геройлар да өйрәнүгә, үрнәк алуга лаеклы. Шуңа күрә дә аның таланты алдында баш иясе килә.

**Кулланылган әдәбият**

1. “Татар әдәбияты тарихы”, Казан, Татарстан китап нәшрияты – 1986;

2. Л.И.Минһаҗева, И.Х.Мияссарова “Татар балалар әдәбиятыннан хрестоматия”, Казан, ТаРИХ – 2010

3. Татар әдәбиятыннан хрестоматия, Казан, Татарстан китап нәшрияты – 1986. « Казан утлары » 1991. №3. 157-159б.

4. Шамов А. Чын хикәяләр: Хикәяләр, очерклар, истәлекләр. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1986.

5. Шамов А. Зөя буенда: Очерк. – Казан: Таткнигоиздат, 1956.

6. «Ватаным Татарстан» газетасы, 20 март, 2001 ел.

6. «Мәгърифәт”газетасы,31 март,2001 ел.

7. “Мәдәни җомга”газетасы,16 март, 2001 ел.

8. «Яшел Үзән» газетасы, 23 март, 2001 ел.№35-36

9. «Шәһри Казан» газетасы, 2 март, 1990 ел.

10. «Мирас» Афзал Шамовка 90 яшь, 1990 ел.

11. «Сабантуй» газетасы, 2001 ел.

12. Музей материаллары

**БЕЛЕМ БАСКЫЧЛАРЫ**

**1907-1909 елларда авыл мәзинендә укыган.**

**1909-1910 еллар-Бузай авылы кадим мәдрәсәсе.**

**1910-1912 еллар- Олы Өтәк кадим мәдрәсәсе.**

**1912-1914 еллар-Татар Танае кадим мәдрәсәсе.**

**1914-1915 еллар-Колыбирде башлангыч земство мәктәбе.**

**1915-1916 еллар-Акъегет авылы русча-татарча мәктәбе.**

**1916 елда Татар Танае авылында яңача мәктәп ачыла.**
**1917-1918 елларда “Касыймия” мәдрәсәсендә укый.**




Афзал Шамовның балачагы үткән йорт




Афзал Шамов яшәгән Ындырчы урамы



**Авыл тимерчелеге**




Афзал Шамов туганы Галәветдин
белән („Җиндер букча" хикәясе аның
турында)



Афзал Шамов

КИНДЕР БУКЧА

*Автор: <u>Сәлимуллин Динар Рафаэль улы,</u> МБОУ "Лицей №9 им. А.С. Пушкина ЗМР РТ" 11 Б сыйныфы укучысы*
*Фәнни җитәкче: Габидуллина Динә Гаяз кызы*

**Ризаэддин Фәхреддиннең "Тәрбия" китабы һәм Афзал Шамовның "Ата күңеле" әсәрендә рухи-әхлакый тәрбия бирүдә аталарның роле**

I. Кереш
II. 1 бүлек. Афзал Шамов- халыкның зур ихтирамын казанган әдип----
2 бүлек. Ата-баш, хатын -муен -------------------------------
3 бүлек. Ризаэддин Фәхреддиннең "Тәрбия" китабы Һәм Афзал Шамовның "Ата күңеле" хикәясенең уртаклыгы -------------------------------
III. Йомгаклау ---------------------------------------------------------------
IV. Кулланылган әдәбият исемлеге-----------------------------------------

Мин берничә айдан мәктәпне тәмамлаячакмын. Минемчә, мин инде- олыларча фикер йөртүче укучы. Моның өчен мин , беренчедән, әти-әниемә, икенчедән, мәктәбемә рәхмәтлемен. Мин татар гаиләсендә тәрбияләнүче малай. Элек-электән татар халкында әти кеше – гаилә башлыгы булган. Безнең гаиләдә дә нәкъ шулай. Әйе, гаиләдә төп кеше- әти кеше булырга тиеш. Ләкин хәзерге заманда күп кенә сыйныфташларымның бөтенләй әтиләре юк, яки ташлап киткәннәр, шуңа күрә әниләре белән генә яшиләр. Ни өчен күп кенә гаилә тарәге буласы әти гаиләсен ташлап китә, сәбәбе нәрсәдә, ни өчен балалар әтисез үсәргә мәҗбүр? Мин бу сорауларга җавапны Афзал Шамовның китабыннан эзлим.

"1961 нче елларда Татарстан Язучылар союзы идарәсе рәисе булып эшләгән һәм икенче бөтендөнья сугышы чорындагы шәхси батырлыклары һәм әдәби иҗат өлкәсендәге олы хезмәтләре өчен Кызыл Йолдыз, Хезмәт Кызыл Байрагы, Октябрь революциясе орденнары, уннан артык медаль белән бүләкләнгән Афзал Шамовның бай мирасы соңгы вакытта онытыла башлады кебек. Менә егерме елдан артык инде аның китаплары басылганы юк",-дип язган кайчандыр Минәхмәт Сәхапов "Хакыйкать йөзе" китабында. Мине бу сүзләр тетрәндереп җибәрде. Аның китаплары хәзер дә бик актуаль. Бу фикерне " Тормыш чынлыгын, тормышка ышаныч яшәү биргән, хәтердә калырга хокук яулаган иң төп сыйфатларның беренчесе мөгаен. Афзал Шамовның китабына кергән хикәясе булсын,очерк яки истәлеге булсын-һәрберсе фикерне уята, татлы бер кичерешкә әверелеп, күңелне кузгата, шәфкатькә, миһербанлыкка өнди. Афзал аганың геройлары әдәбият һәм тормышның тыгыз берлегендә яшиләр, хикәяләү процессындагы дөреслек ялкынлы автор сөйләме аша тормышка әйләнеп кайта",-дип язган тәнкыйтьче Фәрит Бәшир. Мин бу сүзләрнең дөреслеген күрсәтү өчен**, фәнни эшемнең максаты** итеп, Афзал Шамовның "Ата күңеле" әсәрен Ризаэддин Фәхреддин хезмәте белән чагыштырып , аталарның бала тәрбияләүдә гаиләдә зур роль уйнавын күрсәтергә булдым. Шул максаттан түбәндәге **бурычлар куям**:

-гаиләдә атаның дәрәҗәсен күтәрү өчен нишләргә кирәк;

-ни өчен аталар балаларын ташлап китәләр?

**Тикшерү объекты:** Риза Фәхретдиннең "Тәрбия китабы" һәм Афзал Шамовның "Атаның күңеле" дигән хикәясен алдым

**Гипотеза**: хәзерге чорда хатын-кызга ирек күп бирелдеме яки ир-ат көчсезме ?

**Кереш**

Вакыйгаларны сурәтләүдә, төрле персонажларга характеристика бирүдә Афзал Шамов еш кына үзенең геройлары белән бер булып сөйли. Язучы сурәтләгән вакыйгаларга һәм геройларына битараф түгел һәм актив позициядә тора. Әйтерсең лә үзенең укучыларына: «Менә сезгә тормыштан бер гыйбрәтле күренеш. Безнең тормышта шундый кешеләр булырга тиеш,"— ди ул. Мин дә якташымның "Ата күңеле" хикәсендәге Хәйрулла абыйлар кебек безнең заманда да шундый ир-атлар булса иде , ләкин аның кебек ничек булырга соң дигән сорауларга җавап эзлим.

Афзал Шамовның "Ата күңеле"хикәясенең сюжеты гади генә, ләкин анда мине борчыган сорауларның җаваплары ята .

Төп герой- Хәйрулла абый. Әсәр геройның балаларыннан, эшләреннән, гадәтләреннән, халык арасында үз-үзләрен тота белүләреннән канәгать иде. Кешеләр

балалары турында начар фикердә түгел. Моның өчен Хәйрулла абыйның үз принциплары бар: кеше һәр җирдә – өендә, гаиләсендә булсын, тышта, җәмгать арасында булсын,- бары яхшы ягыннан гына күренергә тиеш. Моның өчен аныңча халык теленә начар исем белән кермәүдә түгел, ә кешенең яхшы сыйфаты,тырыш хезмәте, һәр эштә гадел, тугрылыклы булуы ятарга тиеш ди.Үзе дә өч сугышның дарысын иснәгән, окобын күргән, газабын чиккән, тәмен татыган кеше. Ул гына түгел, өч бала атасы. Бер улы заводта эшли, кызы- кияүдә, өченчесе- Сабиры колхоз җитәкчесе. Җитәкче булгач, аңа тагын да башкача карый, чөнки халык белән эш итә. Бервакыт Хайрулла абый авырып киткәч, аны улы больницага алып барырга уйлады. Ә анда кеше бик күп. Малае Сабир регистрация янына килде, Ә Хәйрулла абзый күзәтеп тора. Аның нәтиҗәләре:

**Төп өлеш**

-аңа юл бирделәр

-тәрәзә янын бушаттылар

- ике номер бирделәр

Әйтерсең бу сүзләрне Ризаэтдин Фәхреддин үзенең “Нәсыйхәт” китабындагы сүзләрен Сабир үти: “Атам-анам минем белән горурлансын, шатлансын, кешеләр дә миңа рәхмәт әйтсен, мине яратсыннар һәм мине һәркемгә үрнәк итеп сөйләсеннәр”. Без моны җыелыш вакытында да күрә алабыз.

Хәйрулла абзыйга колхоз җыелышында катнашырга туры килә. Клубта ул арттагы рәтләренең берсенә барып утыра. Беренче секретарь сүз алганчы һәм тәнкыйтьли башлагач, аның хисләрен, үз- үзен тотышына игътибар итик әле:

| | Җыелышка кадәр | Җыелыштан соң |
|---|---|---|
| | Эченнән шатлана, яхшы тәрбияләве кеше итүе белән горурлана | Йөрәгеи бик каты чеметте, тынып калды, сулышы кысылды, председательнең сүзен ишетми калды |
| | Балалары турында нинди дә булса начар сүз ишетсә, кара көя иде<br>Күргән-белгәннәр исәнләшеп, сәлам биреп узалар, якын итәләр<br>Аның улын, аның Сабирын һәркайда хөрмәт итәләр | Салкын тир басты<br><br>Сабирның әтисе икәнен белмәсәләр иде...<br>Тагын Низамов Сабир! Мунча кертәләр дә соң үзен... |

Шулай итеп, капма-каршы хисләр. “Җыелыштан соң” хисләре Хәйрулла абзыйга малаен чын ирләрчә тәрбияләргә ярдәм итә .Хәтта кайчандыр күчтәнәчкә алып кайткан маен дә хатынына баздан чыгартып биреп җибәрә.

Сабирның әнисе дә каршы килә алмый , чөнки алар аны икәү бергә тәрбияләп үстергәннәр.

Афзал Шамовның “Ата күңеле” хикәясен олуг педагог, мәгърифәтче Ризаэддин Фәхреддин хезмәте белән чагыштырып барырга тырыштым, әйтерсең ике шәхес бер үк нәрсәне бер үк язалар.

| Ризаэддин Фәхреддин “Нәсыйхәт” китабыннан | “Ата күңеле” хикәсеннән |
|---|---|

| | |
|---|---|
| Балаларыгызны тәрбияләргә иң кечкенә чакларыннан башлагыз, урынына карап бераз йомшаклык вә вакытында карап бераз **катылык** күрсәтегез. | Әтисе аңа күтәрелеп карамады, җавап кайтармады**, коры** салкын тавыш белән сорау бирде. |
| Балагыз күз алдында үз- үзегезне хөрмәтле тотыгыз,алар сездән үзләрен тотарга өйрәнсеннәр. | Әтисенең тавышың күтәрмәскә, кызып китмәскә тырышуы сизелеп тора иде. |
| Сез тәрбияләгәндә хатыннарыгыз да арага кермәсен. | Карчыгы иренең холкын белә иде, карышып торуны кирәк санамады. Улына күзләрен тутырып карады да, шырпы алып , теләр-теләмәс чыгып китте. |
| Фикерләрегез белән әшнә итегез, дөнья көтү өчен аларның күзләрен ачыгыз, тормыш кагыйдәләрен аңлатыгыз | Җыелышта җир тишегенә керерлек булдым... Менә шулай.. Аңлый торгансың. Башыңа ат типмәгән. Егет сүзе бер булыр. Нәселемне хур итәсе булма. |
| Балаларыгызны кеше дип санап, аларны адәм итеп теләсәгез, мөгамәлә итегез; Зиһеннәрен ачарлык нәрсәләр сөйләгез, гакылларын нурландырыгыз. | Хәйрулла карчыгына: "Мин аңа иң зур комиссия.. Аның җитешсезләрен минем хәтле берәү дә күрә алмый. Мин өйрәтмәгәч, кем аны өйрәтсен" |

**Йомгаклау**

Афзал Шамовның исеме алтын хәрефләр белән язылырга, китаплары күп тиражлар белән чыгарылырга тиешлегенүземнең фәнни эшемдә күрсәтергә расларга тырыштым. Шуңа күрә якташымның әсәрләре мәктәп программаларында урын алырга тиешлеген аңладым. Әгәр якташыбызның "Ата күңеле" дигән хикәясе 10, 11 нче сыйныфларында булса, күп кенә сыйныфташ дус малайларыма, булачак әтиләргә, гаиләдә кем баш булырга тиеш дигән сорау ачык булып калыр иде. Замана үзгәрсә дә , татар халкының үз традицияләре калырга тиеш. Ата гаиләдә баш булып, гаиләнең төп терәге, бөтен яктан тәртипле, үрнәк әти булырга тиеш. Бернинди демократия дә хатын-кызларыбызны көчле зат итеп ясамас, ә, бәлки, ир-атны хөрмәт итеп, балалар алдына аның дәрәҗәсен күтәрергә тиештер. Ә бу үз чиратында татар гаиләрендә тату һәм тулы гаилә, үрнәк гаиләләр барлыкка китерер иде.

***Кулланылган әдәбият***

1. Афзал Шамов. Буранлы төндә (Повесть һәм хикәяләр). – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1981. 335– 354 бб.

2. Ризаэддин Фәхреддин. Нәсыйхәт (Әхлак гыйлеменнән).-- Казан: "Мәгариф"нәшрияты , 2005, 90– 93 бб.

3. Хәсән Хәйри "Олы әдип", Мәгърифәт- 2001-№13

4."Аҗаган"газетасы Ф.Мусин Афзал Шамовка 90 яшь.- 1991-№1.- 31-33бб

5. Сверигин, Рифат Яңа геройлар һәм яңа алымнар. Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татар кит. нәшр., 1985. 120 бит.

6. Фәрит Бәшир Сөйлә каләм( Әдәби уйлануар, тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләр) .-- Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2001, 101-107 бб.
7. Минәхмәт Сәхапов Хакыйкать йөзе, казан,” Мәгариф” нәшрияты, 2001, 279-280 бб.
8. Халит Г. Кешеләр һәм язмышлар// Халит Г. Кешегә һәм чынлыкка мәхәббәт белән. – Казан: Татар кит. нәшр., – 1975

*Автор: Фатыйхова Алисә Мөнир кызы, “Татарстан Республикасы Кайбыч районы Олы Кайбыч урта гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, 8 нче сыйныф*
*Фәнни җитәкче: Хәмидуллина Алсу Фәрит кызы*

## Афзал Шамовның “Рәүфә” повестендә тел-сурәтләү чаралары

Эчтәлек.

1. Кереш.
2. Төп өлеш. Афзал Шамовның “Рәүфә” повестендә тел-сурәтләү чаралары
- Портретлар бирелеше
- Чагыштырулар
- Фразеологик әәйтелмәләр
- Мәкальләр
- Җирле халык сүзләре
- Синоним, антонимнар
- Метонимия, эпитет, литоталар
3. Йомгаклау.
4. Кулланылган әдәбият исемлеге.

### 1. Кереш

“Әдәби әсәрнең теле, аның эчтәлеге кебек үк, билгеле, беркайчан да күктән генә килеп төшми, үзеннән-үзе генә чәчрәп чыкмый. Кыскасы, юктан бар булмый, - дип язды Гомәр Бәширов.- Ул чыганак — язучы үзе, аның туганнан бирле җыелып килгән тормыш тәҗрибәсе, белеме, тел хәзинәсе. Яхшы әсәр языйм, үз сүземне үземчә әйтим дигән әдип иң элек телен баетырга тырыша. Чөнки йорт салучыга төзү материалы никадәр кирәк булса, язучыга тел дә шул дәрәҗәдә үк кирәк.”

Әгәр кешенең сүз байлыгы җитәрлек түгел, ярлы икән, аның уй-хисләрен аңлатырга сүзләре табылмый. Матур әдәбият теле - образлы тел. Анда сурәтләү чаралары аша һәр язучының сөйләм үзенчәлеге күренә. Автор кулланган чаралар, алымнар җыелмасы язучының дөньяга карашын, иҗат ысулының юнәлешен дә билгели. Язучы сүзләрне билгеле бер максат белән сайлап ала, урнаштыра.

Димәк, әсәрнең тел-сурәтләү чараларын өйрәнү аның темасын, проблемаларын, идеясен, пафосын, сюжетын аңларга, ачыкларга ярдәм итә. Образларның характерларын өйрәнгәндә , табигать күренешләренең әһәмиятен ачыклаганда да тел-сурәтләү чараларына мөрәҗәгать итәбез.

Шундый үзенчәлекләрне исәпкә алып, без Афзал Шамовның 1926 нчы елда иҗат ителгән “Рәүфә” повестен өйрәнүгә алындык. Афзал Шамов әсәрләре белән генә түгел, якташыбыз булу белән дә, 1918 елның көзеннән 1919 елның ахырына кадәр, Кайбыч районындагы Кошман авылында балалар укытуы белән дә кызыксыну уятты.

### 2. Төп өлеш

Әлбәттә, “Рәүфә” әсәре теленең халыкчан гадилеге, сюжетның көндәлек тормыштан алынган вакыйгаларга нигезләнүе, композициянең җыйнаклыгы белән укучыны җәлеп иткән әсәрләрнең уңышлысы. Язучы искелек калдыкларын, кулак Шәмгун һәм аның улы Сафаның ерткычлыгын гына фаш итү белән чикләнеп калмый, ул Рәүфә язмышын сурәтләгәндә авыл тормышындагы яңалыкларны расларга омтыла. ( 4.165)

Тикшеренү эшенең **бурычлары**: әсәрнең урын-вакытын тикшерү; образларны аерып чыгару, аларның бирелешен ачыклау; әсәрдәге тел-сурәтләү чараларын табу, аларның ролен ачыклау.

Әлеге эшне башкарганда күзәтү, әдәби образларга анализ ясау, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау, кайбер өлешләрне җентекләп анализлау алымнарын, тикшеренү, эзләнү **методларын** кулландым.

Совет властеның беренче көннәреннән үк язучылар алдына социализм эпохасының үз әдәбиятын тудыру бурычы килеп баса. “Рәүфә” повесты яңа чынбарлыкны тасвирлауга багышланган тәүге әсәрләрнең берсе санала.

Вакыйгалар башланып киткән урын – Гөбенә буена урнашкан авылларның берсе. Әсәр барышында кулланылган таныш атамаларны күрү минем аеруча якын булды. Кайбыч районы белән чиктәш булган Яшел Үзәннең күп авыллары - безнең өчен күрше авыллар. Автор Норлат һәм Ачасыр авылларын атап үтә (76). Язгы ташуның беренче шарлавыклары басылган вакыт дип әйтелеп үтүне дә символик образ дип карарга кирәк, революция тудырган үзгәрешләр нәтиҗәсендә барган вакыйгалар чыннан да язгы ташудан соң тынычланып килүче табигатьне хәтерләтә.

Әсәрнең эчтәлегенә, образларга килик. Авылның төпле, ныклы нәселеннән булган Шәмгун Сафасы үзеннән 5-6 яшькә кечерәк ярлы Мифтах мәрхүмнең Рәүфә исемле кызына өйләнеп куя. Моңа, әлбәттә, илдә бара торган үзгәрешләр бик нык тәэсир ясый, чөнки йорт-җире, ишек алды, юан нарат бүрәнәләрне икегә ярып салынган каралтылары, тыкрыкны тутырып торган амбарлары, кара-каршылап, урта өйләп салынган йортлары, рус капкалары булган комсыз, тәкәббер Сафаның йорты да булмаган (моннан ике ел элек янып китә), ятим бер кызга өйләнүе авыл халкы өчен бик гаҗәп хәл була. Тик алдан уйлап эшләнгән бу эшнең Рәүфә өчен бик начар яклары ачыла. Чәчәк кебек кыз явыз кайнананың, сөйләшми торган тупас ирнең усаллыгыннан тилмерә, соңрак Сафа аны аерып җибәрә, бары тик яңа власть кына Рәүфәнең хокукларын яклый, туачак баласы да закон тарафыннан таныла. Г.Ибраһимовның “Татар хатыны ниләр күрми?” әсәрендәге Гөлбану белән охшаш язмышлы Рәүфәнең алдагы тормышы яңа власть аркасында бәхетле була.

Рәүфә образын Афзал Шамов бик яратып иҗат итә. Аны тасвирлауга ул сурәтләү чараларын кызганмый. Тал чыбыгы кебек зифа буй, шомырт төсле кара чәчләр, төз аяклар, озын, кара толымнар, таза, ап-ак тән, карасу күзләр, кояш нуры белән янган бит, алсу иреннәр, ап-ак, теп-тигез тешләр.(30). Эшчән, акыллы, сабыр, тыйнак татар кызы образын укучы яратып кабул итә, аның язмышы белән яши, бәхетле булуын көтә.

Сафаның тупаслыгы, дорфалыгы тышкы кыяфәтеннән үк күренеп тора. Автор моны авыл яшьләре авызыннан әйттерә: “Я, Сафаның нәрсәсе бар соң? Яшь дисәң – яшь түгел, матурлыгы дисәң – матурлыгы юк, ниндидер шунда балта белән юнып эшләнгән бер бәндә” (8). Бу егет атасыныкы төсле үк коңгырт күзле, төсе –бите белән атасына охшаса да, кыска базык буе-сыны белән, бигрәк тә кулларының гәүдәсенә караганда озынрак булулары белән беркадәр анасына охшый төшә. Әмма характеры белән ул анасына да, атасына да охшамаган иде.(25) Ул аз сүзле, күп вакыт я елмаеп, якаш җыерып кына теге яки бу мәсьәләгә үзенең карашын белдерә. (27) Язучы Сафаны тасвирлаганда, аның сүзсезлек сыйфатын иң зур кимчелеге итеп күрсәтә, шуның аркасында аның беренче хатыны да аерылып китә.

Ассоциатив сурәтләү чаралары арасында аеруча эпитет һәм чагыштырулар күп кулланыла. А.Шамов – чагыштырулар остасы. Язучы чагыштыруларга табигать күренешләрен, кешенең йөз-кыяфәтен,эш-хәрәкәтен, хис-тойгыларын, рухи дөньясын сурәтләгәндә мөрәҗәгать итә.

Бер күренешне икенче предмет янына куеп, шуңа охшатып , янәшә куеп сурәтләүне чагыштыру дип йөртәләр.Тиңләү өчен гадәттә үтә таныш , ачык билгеле әйбер алына.Әнә шулай тиңләү өчен генә алынган предмет, күренеш чагыштыру була. Охшату аша төп тасвирлау объекты җанлы, конкрет , сурәтле булып күз алдына килеп баса. Чагыштыруларның күрсәткечләре:

-дай/дәй,-рак/-рәк,-ча/-чә аффикслары белән ясалганнары: бизгәк тоткандай (50), биегәндәй (40)

-Кебек,төсле, шикелле бәйлекләре: тычкан койрыгы кебек (17), тау төшкән шикелле (24), ут кебек янып тора (48) поскан шикелле китеп барды (43)

Фразеологик әйтелмәләр:

Борчак пешеп җитми (13), ачуы кабара (13), борын күтәрү (13), җене сөйми (13), серкәсе су күтәрми (10), ачык-тишекләрне ямау (4), күз күрер әле (15), кара халык (17), эченә җылы керде (17), **ачык чырай (19**), таякның авыр башы (29), тәртәгә тибү (25), авызны чөйгә элү (26), башлы-күзле булу (26), шайтан төкергән (27), күңеле төшкән (28), караңгы чырай (42), канына тоз сала (45), Әндри казнасы (49), аягы уңмау (55), авызыңнан җил алсын (58), күңеле тулды (81), тузга язмаган (81), күздән югалу (81), йөрәккә май булып яту (81), эч пошу (78), сүзне аяк астына салып таптау (66), кәкре куллы (57)

**Мәкальләр:**

Җаны теләгән – елан ите ашаган.(8)

Иш ишен эзли, җил тишеген эзли (8)

Кызлар күңеле – кызган казан (9)

Майсыз таба купмый (6)

Яшьлек – юләрлек (5)

Коры кашык авыз ерта (15)

Белмәгәннең беләге авытртмый (17)

Күрәсен күрми, гүргә кереп булмый (18)

Эт авызыннан сөяк алып буламы (40)

Авыртмаган башка тимер тарак (49)

Кыз яхшы җиргә төшсә – чалпая, яман җиргә төшсә – картая. (59)

Өлешеңә чыккан көмешең (59)

Ана күрке – бала(70)

Асыл суга батмас (70)

Илдә чыпчык үлми (68,84)

Язучы үзебезнең халык сөйләмен - тау ягы сөйләше, диалекталь сүзләр кулланып, җанлы сөйләм барлыкка китерә.

Былчырак – пычрак, нәүрәп – баз, җәвит итү –явиться, кәнди – табак, тәлинкә, кырку – кырыс, мырдымлыгы - тынгысызлыгы

Гаптырахман – Габдрахман, Миңкамал – Миңлекамал, Гаптулла –Габдулла, Патый әби – Фатыйма әби, Ярман сугышы –Герман сугышы

Мәйтәм – мин әйтәм.

Яшел Үзән районына кергән авыллар: Ачасыр, Норлат, Күккүз.

Елгалар: Гөбенә,Зөя.

Әсәрдә синонимнарның күп төрләре китерелгән, фразеологизмнар белән бирелгән синонимнар да әсәрнең бай телен ассызыклый. Синонимнар:

Яратмый –җене сөйми (13), көләләр-мыскыллыйлар (28), кыйный –изә, таптый (), Өйләнү – башлы-күзле булу (28), пакъ –саф (51), ачулану – эттән алып эткә салу(53), үсә – зурая (54), ялган – нахак (83), рәхәтләнеп – ләззәтләнеп (86), хурлау – кешегә санамау, мыскыллау (84), сый – хөрмәт (68), узганда –барганда (68), елыйсы – үксисе (64), ватылу – чәлпәрәмә килү (61), көлгә әйләндерү –яндыру (61), бәла –начарлык, явызлык (61).

Антонимнар күп очрамады: ачык чырай - караңгы чырай, матур –йөрәк яргыч, куркыныч.

Литота нормадан тайпылышны аңлата. Ул –арттыру, тик зурайту ягына түгел, кечерәйтү ягына арттыру. Мисаллар: Инә очы кадәр гаеп (58), бер тамчы ялган юк (82), сүзебезнең тузан кадәресе (84).

Эпитет - әдәби ачыклау ярдәмендә образ тудыручы сурәтләү чарасы, ачыклаучы сүз әйбернең яки күренешнең төп, тотрыклы сыйфатын белдерүе. Мисаллар: зәңгәр төннәр (5), күгәреп каткан, мүкләнгән йөрәкләр (4)

Метонимия- грекча исемне үзгәртү мәгънәсен бирә, күренешне туры мәгънәсендәге сүз белән белдермичә, ул күренеш белән кайсыдыр яктан бәйләнешле икенче сүз ярдәмендә бәян итү метонимик сурәтне барлыкка китерә, икенче төрле әйткәндә, туры мәгънәле сүзне алыштырып килгән, аның белән өлешчә бәйләнешле сүз метонимия була. Мисаллар : сүз йөртүче кыек авызлар, Мәликә – яшел тавыш.

**3. Йомгаклау.**

Карап үтелгән күпсанлы мисаллардан күренгәнчә, Афзал Шамов сүзнең бөек көчен, тасвирлау мөмкинлекләрен тоеп, үзенә генә хас иҗат стилен тудырган, сүзнең үзенчәлекле мәгънә төсмерләрен тоеп сурәтли бергән. Аның әсәре халыкчанлыгы белән аерылып тора. Кешеләрне, туган җирне ярату кебек хисләрне А.Шамовча итеп сурәтли белүчеләр күп түгел. Минемчә, бу фикерне раслау өчен, Ә. Еники сүзләре бик тә урынлы булыр. “Без әдәби осталык турында күп сөйлибез. Ләкин әдәби осталыкны беренче чиратта тел осталыгы, телгә байлык, телне дөрес куллана белү дип аңларга кирәк. Язучы кешедә телгә карата аеруча бер сизгерлек булырга тиеш, ул һәр сүзнең тулы мәгънәсен аңлау гына түгел, аның эчке аһәңен, кай урында ничек яңгыравын, ниһаять, сүзләрнең үзара бәйләнешен тоя белергә тиеш”. (Ә. Еники. Язучылык хезмәте турында.)

**Кулланылган әдәбият исемлеге**


1. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231б.
2. Шамов А.Ш. “Сайланма әсәрләр” Татарстан китап нәшрияты, 1976
3. Д.Ф.Заһидуллина «Әдәби әсәргә анализ ясау», Казан «Мәгариф» нәшрияты, 2005.
4. «Татар әдәбияты тарихы» 4 том , Татарстан китап нәшрияты, 1989.
5. Ф. Хатипов «Әдәбият теориясе», Казан, «Мәгариф» нәшрият 2000.
6. http://kitap.net.ru/bashirov.php



*Автор: Хәмидуллина Ләйлә – 9 с.укучысы, Афзал Шамов исемендәге Татар Танае урта гомуми белем бирү мәктәбе*

*Җитәкче: Тимершина С.А, беренче квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*


## Афзал Шамов – төбәгебез горурлыгы

Эчтәлек


Кереш.........................................................................................................

Проектның максаты....................................................................................

Проектның бурычлары................................................................................

Проектның актуальлеге……………………………………………………...

Проектны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәләре.......................................

Проектның тикшерү объекты………………………………………………..

Проектның фәнни яктан әһәмияте...............................................................

Проектның практик яктан әһәмияте һәм яңалыгы...........................................

Төп өлеш......................................................................................................

Фаил Шәфигуллин –төбәгебез горурлыгы ....................................................

Авылдашыбыз язучы Афзал Шамов иҗатын өйрәнү проекты тарихыннан

Проект турында мәгълүмат........................................................................

Йомгаклау...................................................................................................

Кулланылган әдәбият исемлеге...................................................................


**Кереш**

Хәзерге көндә кеше мәгълүматлар чолганышында яши, яңа мәгълүмати технологиялардән башка ул аларны үзләштерә дә, җәмгыять үсеше өчен файдалана да алмый. Тормышыбызга компьютер һәм шуның белән бергә мәгълүмати технологияләр нык үтеп керде. Алар укучыга гына түгел, хәтта укытучының үзенә дә үсәргә киң мөмкинлекләр бирә. Белем бирү процессын компьютерлаштыру – мәгариф үсешендә өстенлекле юнәлешләрнең берсе.

Яңа мәгълүмати белем бирү мохитенә күчү шушы мохиткә хас педагогик мөмкинлекләрне, методларны, формаларны, җиһазларны һәм шулай ук укучылар өчен көтелгән нәтиҗәләрне тәэмин итәрлек төрле белем бирү эшчәнлекләрен өйрәнү һәм

анализлауны күзаллый. Шуңа күрә укытучы эшчәнлеге нигезендә компонентлар чылбырыннан планлаштырылган белем бирү нәтиҗәләренә анализ, уку-укыту процессларының максатлары һәм бурычларына, фәнне өйрәтү эчтәлеге барышына план төзү, педагогик сценарий булдыру, яңа уку-укыту эшчәнлек төрләрен проектлау, яңа укыту ситуацияләрен, методларын, оештыру формаларын сайлап алу, уку-укыту мәсьәләсе эчтәлеген ачыклау һәм планлаштырылган эшләрне тормышка ашыру өчен кирәкле ИКТ чараларны сайлап алуны күздә тотучы **проект компоненты** ята.

Мәгълүмати белем бирү мохитендә проект компонентларына нигезләнеп төзелгән уку-укыту процессы мөмкинлекләре зур **актуальлеккә** ия. Алар беренче чиратта бүгенге мәгълүмати белем бирү мохитенең элек укытучы арсеналында булмаган ИКТ чараларын куллану нигезендә дидактик мөмкинлекләр: мохитнең төрле вариантларга җайлаша, төрле уку-укыту бурычларын чишүгә юнәлтелә алуында. Уку-укыту процессын проектлаштыру мәгълүмати белем бирү мохитендә билгеле бер тәртиптә (эзлеклелектә) этапларны тормышка ашыруны күздә тота.

**Проектның максаты:**

1. “Фаил Шәфигуллин –төбәгебез горурлыгы” темасына проект эше төзү;
2. Белем сыйфатын үстерү һәм гамәлгә ашыру;
3. Проект эшенең нәтиҗәлелеген ачыклау.

**Проектның бурычлары:**

1. Күренекле язучы Ф.Шәфигуллин музеен, тормышын, иҗатын, әсәрләрен тирәнтен өйрәнү;
2. укучыларның белемен тикшерү, бәяләү;
3. проект эше кулланылып үткәрелгән дәресләрнең нәтиҗәлелеген бәяләү;
4. проектның нәтиҗәлелегеннән чыгып, уку-укыту процессына кертү өчен төзәтмәләр кертү.
5. Ф. Шәфигуллинны төбәгебез халкына таныту.

**Проектның актуальлеге**

Фаил Шәфигуллин әсәрләренең тәрбияви кыйммәте әйтеп бетергесез зур. Алар – безнең милләтебезнең рухи байлыгы, милли үзенчәлекләре турында чорыбыз вакыйгаларына бәйләп язылган әдәби әсәрләр.

Без күз ачып йомганчы зур тизлек белән әйләнүче Җир шарында яшибез. Бер рухи байлык, икенчесе белән алышына. Кайчандыр без тискәре итеп караган сыйфатлар, хәзер кешеләр өчен гадәти хәл булып бара.

Мәктәпнең төп максаты – балаларны җирле тамырларына, гореф-гадәтләренә, диннәренә таба йөз белән бору. Болар барысы да киләчәк буында миһербанлылык, мәрхәмәтлелек, игелеклелек, игътибарлылык, сизгерлек сыйфатлары тәрбияли. Бу сыйфатларның нигезендә мәхәббәт ята. Проза һәм драматургия, шигърият, сатира-юмор өлкәсенә караган кайсы гына әсәрен алсак та, аларда Туган иленә, халкыңа бирелгәнлек, туган телеңә сүнмәс мәхәббәт хисләре урын алган. Әлеге әсәрләрне укыгач, безнең күңелләрдә матур, нәфис хисләр уяна, без әхлакый кыйммәтләрне аңлыйбыз, уйлана башлыйбыз, матурлыкка омтылабыз.

Язучының халык тәҗрибәсенә нигезләнгән иҗтимагый–фәлсәфи карашлары безне яхшыны яманнан, дөреслекне ялганнан аерырга өйрәтә. Якташыбыз Ф.Шәфигуллинның омтылышлары, идеяләре, фикерләре бик актуаль, алар бүгенге көннең проблемалары, әһәмиятле мәсьәләләре белән аваздаш.

**Проектны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәләре**

Кешелек узганга нәтиҗә ясый, киләчәккә планнар кора. Бу традиция белем бирү сферасын да читләтеп узмады. Бүген үк инде белем бирү системасын камилләштерү, белем сыйфатын үстерү юллары эзләнелә.

Җәмгыятькә талантлы, иҗади фикерле, аралаша белүче, көчле рухлы, инициативалы шәхесләр сорала. Укып алган диплом гына тормышта үз урыныңны табуга

гарантия була алмый. Мәктәп бусагасын атлап чыгучы җаваплылык хисе, дисциплина, белем күтәрүгә омтылыш, эзләнүчәнлек кебек сыйфатларга ия булырга тиешлеге һәркемгә билгеле. Мәктәпләрдә шундый шәхесләр тәрбияләүгә укучы шәхесенә юнәлдерелгән яңа педагогик технологияләр ярдәм итә.

Бүгенге педагогика алдында укыту процессын кызыклы һәм файдалы итү проблемасы төп проблемаларның берсе булып тора.

Заманча укытуның бигрәк тә кызыклы методларының берсе – интерактив методлар. Мондый методлар кулланып эшләгәндә дәрестә укучы актив катнашучы, белемне, мәгълүматны чыганаклардан үзе таба, ә укытучы бу очракта аңа юнәлеш бирә, чыганакларны тәкъдим итә. Укучы актив – укытучы моның өчен шартлар тудыра.

**Проектның тикшерү объекты**

Татар әдәбияты дәресләрендә, дәрестән тыш чараларда белем алучы укучыларның якташ язучыларның иҗаты, тормыш юлы, әсәрләре, музейлары белән танышуы, алган белемнәргә нигезләнеп үз проектларын язу.

**Проектның фәнни яктан әһәмияте**

Әлеге проект эшендә укытучы һәм укучы эшчәнлекләре компонентлар чылбыры: шәхескә кагылышлы УУГ(универсаль укыту гамәлләре), регулятив УУГ, академик УУГ, коммуникатив УУГ планлаштырыла. Проектның максатлары һәм бурычлары, максатка ирешү методлары, оештыру формалары, җиһазлау чаралары билгеләнгән. Эш барышында укучыларның шәхсән яклары, тема эчтәлеген аңлау, дәрескә, дәрестән тыш чараларга әзерлек дәрәҗәләре күренә. Төрле төркемнәрдә укучы балалар белән эшләүче укытучыларга проектта күтәрелгән мәсьәләләргә күзәтү ясауның әһәмияте зур булыр дип саныйбыз.

**Проектның практик яктан әһәмияте һәм яңалыгы.**

Рус һәм татар балалары белән эшләүче татар теле һәм әдәбияты укытучыларына, татар теле һәм әдәбияты түгәрәге җитәкчеләренә үз эшләрендә куллану өчен материал була алуында. Проект 4 этаптан тора: мәгълүмат туплау, аны эшкәртү, хәзерлек, халык алдында чыгыш ясау.

**Төп өлеш**

Бүген белем бирү системасын камилләштерү, яңа дәүләт стандартларына күчү белән бәйле рәвештә белем сыйфатын үстерү юлларын эзләү бара. Чөнки җәмгыятькә талантлы, иҗади фикерли, аралаша белүче, инициативалы гражданнар сорала. Шундый шәхесләр тәрбияләүгә мәктәпләрдә таралып килүче укучы шәхесенә юнәлдерелгән яңа педагогик технологияләр ярдәм итә.

XX гасырның 20 нче елларында америкалы Джон Дьюи нигез салган “проектлар методы” Россиядә гасыр башында ук билгеле була. Ләкин Совет власте елларында әлеге технология үсеш ала алмый, 1931нче елда бөтенләй тыела. 90 нчы елларда кире әйләнеп кайткан бу технология “XXI гасыр технологиясе” дигән исем ала.

Яңа технологияләр ярдәмендә туган телне өйрәнү укучыны тагын да активлаштыра, мөстәкыйльлек тәрбияли. Компьютер технологияләрен куллану фәнне югары дәрәҗәдә үзләштерергә, максатка омтылучанлык, информацион технологияләр дөньясында яңалыклар белән кызыксыну теләгә уята.

Татар теле һәм әдәбиятын проектлар методы кулланып укытуның **максатлары:** өстәмә информацион чыганаклардан билгеле бер проблеманы яктырткан мәгълүматлар тупларга өйрәтү, уку эшчәнлегендә коммуникатив күнекмәләрне үстерү, укучыларны фәнни эзләнү эшенә тарту, фәнне тирәнтен өйрәнүгә этәрү.

**Өстенлекләре:** дәрестә бирелгән мәгълүматлардан да тыш белемнәр алуга этәрүче бер чара (эзләнүләр вакытында укучылар дәреслектән тыш төрле информацион чыганаклар белән эшлиләр), проект һәр укучының шәхси үзенчәлекләрен, кызыксынуларын, сәләтен исәпкә алып эшләргә мөмкинлек бирә (чөнки һәр бирем укучының кызыксынуыннан чыгып бирелә), проект методы кулланып, укучыларга ниндидер күләмдә белем бирелеп кенә калмый, бәлки шул белемнәрне алу һәм алынган белемнәрне практикада куллану юлы да күрсәтелә.

Шулай ук бу метод компьютер белән эшли белергә, текст процессоры ярдәмендә төрле документлар, график программалар ярдәмендә иллюстрацияләр әзерләргә, электрон таблицалар ярдәмендә төрле гамәлләр үтәргә, гади программалар төзергә, электрон почтада эшләргә, Интернеттан файдаланырга өйрәтә.

Бүгенге көндә " Минем беренче сүзлегем " һәм " Татар теле-2004-2013 елларга ТР дәүләт телләрен һәм ТР да башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча ТР дәүләт программасы" , "Татар телле Заман ", Һ.б. компакт-дисклар чыкты. Әмма бу дисклар гына безнең ихтыяҗларны канәгатьләндерми. Проектларны тормышка ашырганда укучылар әзер программа продуктларын да кулланалар, үзләре катлаулы булмаган программалар да төзиләр.

Әдәбият дәресләрендә аерым язучыларның тормышы һәм иҗаты турында кереш белемнәр бирүче монографик дәресләрдә проект методын куллану зур нәтиҗә бирә.

Үземнең тәҗрибәмнән чыгып, авылдашыбыз, якташыбыз, язучы, фронтовик – журналист Афзал Шиһабетдин улы Шамовның тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнү дәресләрендә проект методын куллану турында сөйләмәкче булам.

А.Шамов иҗаты турында башлангыч белемнәр 2 нче класста "Икмәк" хикәясен өйрәнгәндә бирелә башлый. Туган як матурлыгы, аның белән хозурлану темалары, аның сәнгатьчә хәл ителеше турында сөйләшкәндә укучылар үзләренең туган ягы, аның табигате, туган авылы турында истәлекләре белән уртаклашалар. Шул рәвешле укучы күңеленә кешегә туган җиреннән дә газиз җир юклыгы, туган җир иң кадерле һәм А.Шамов та үз әсәрләрендә туган як табигатен сурәтләгәндә, үзенең туган якларын күз алдында тоткан дигән фикер сеңдерелә. Шунда ук башка язучыларның да икмәккә, туган якка багышланган әсәрләре белән чагыштырулар да уздырыла.

Язучының башка әсәрләре сыйныфтан тыш уку дәресләрендә, сыйныфтан тыш чараларда, ел саен үткәрелә торган Афзал Шамов укуларында өйрәнелә. Укучыларда булган шушы белемнәрне күз алдында тотып, язучының 115 еллык юбилее уңаенннан ТНВ каналы тарафыннан "Әдәби хәзинә" тапшыруы төшереп күрсәтелде, туган авылы Татар Танаенда зур юбилей кичәсе үткәрелде. Бу чараларның проектларын эшләп, аны җиренә җиткерүдә Афзал Шамовның мәктәптәге музее җитәкчесе һәм экскурсовод-укучылар башлап йөрделәр.

Проектның исеме үк укучыларны уйландырырлык булырга тиеш. Нәрсә соң ул милли тамыр, язучының нинди әсәрләрендә бу турыда сөйләнелә, башка язучылар иҗатында да бу күренеш күзәтеләме?

Иң беренче эш итеп укытучы яки укучы үзе төзегән презентацияне укучылар игътибарына тәкъдим итә. Сыйныф төрле төркемнәргә бүленеп, һәрбер төркемгә сәләтләрен, шәхси үзенчәлекләрен истә тотып биремнәр бүлеп бирелә. Мәсәлән:

1нче группа: экскурсоводлар. Алар язучы яшәгән, булган урыннарны өйрәнеп, телдән сәяхәт маршрутын төзиләр.

2 нче группа: рәссамнар. Язучы әсәрләре буенча иллюстрацияләр ясыйлар һәм күргәзмә оештыралар. Бу группа эшчәнлеген рәсем сәнгате укытучылары белән берлектә оештырырга да була.

3 нче төркем: тарихчылар. Язучы яшәгән чор, татар халкының тормыш-көнкүреше, милли бәйрәмнәр, тарихи вакыйгалар турында информация туплыйлар.

4 төркем: дизайнерлар. Алар татар халкының милли бизәкләре, киемнәре турында мәгълүмат әзерлиләр. Сәхнәләштерелгән әсәрләр өчен киемнәр сайлыйлар.

5 төркем: музыкантлар. Халык җырлары турында информация туплыйлар, презентацияләрнең музыкаль бизәлеше өчен җавап бирәләр.

6 нчы төркем: библиографлар. Китап күргәзмәсе өчен материал туплыйлар, информацион бюллетень чыгаралар.

Һәр төркем эшчәнлеге проект барышында укытучы тарафыннан контрольдә була.

Эшчәнлеккә йомгак һәм иң мөһим этап - ул укучыларның проектны яклавы, халык алдында чыгыш ясарга өйрәнү. Чыгышлар презентация, буклет, телдән газета, интервью, әдәби – музыкаль кичә формасында узарга мөмкин.

Материалны шушы рәвешле өйрәнү укучыларга Афзал Шамовны халыкчан язучы, әсәрләренең үз туган ягы табигатен чиксез яратуы белән сугарылуы, язучы иҗатына аның милли тамырлары тәэсир итүе, язучы үзе яшәгән чор мохитеннән аерылгысыз икәнлеге турында нәтиҗәләр ясарга булыша.

Язучы иҗатын өйрәнгәннән соң, укытучы материалны ничек үзләштерелүен контрольгә алу өчен тест яки язма бирем тәкъдим итә, аннан соң белемнәргә коррекция уздыра.

Укытуның нәтиҗәлелеге дәресләрдән тыш чараларга турыдан-туры бәйле. Мәсәлән: "Якташыбыз Фаил Шәфигуллин – төбәгебез горурлыгы" дигән темага проект эшләргә дә була. Ул – безнең якташыбыз, Карашәм авылы егете. Мәктәбебездә шушы авыл укучылары да белем ала. Ул алар өчен дә, мәктәбебез өчен дә бик зур горурлык.

Укучылар Фаил Шәфигуллин иҗатын өйрәнеп, әсәрләрен укып кичәнең сценариен төзиләр. Проект өстендә эш барышында алар язучының "Сафура, Бәкер һәм трактор", "Сугышчан бурыч", "Кодагыйлар", "Театр ишеге төбендә" һ.б. әсәрләрен сәхнәләштереп күрсәтәләр. Интернеттан материаллар эзләп, буклет, презентация эшлиләр. Укучылар арасында " Якташыбыз Фаил Шәфигуллин иҗаты – рәсемнәрдә" дип аталган рәсем конкурсы уздырыла. Уку елы ахырында укучылар төзегән сценарий буенча уздырылган Фаил Шәфигуллинга багышланган республика күләмендә үткәреләчәк кичә балаларга бөтенләй яңача тәэсир итәр һәм аларның хәтерләрендә озак сакланыр.

**Йомгаклау**

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә, дәрестән тыш вакытта проектлар методын куллану – укучыларныд иҗади сәләтен үстерүгә этәргеч булып тора. Укучыларда яңа проектлар эшләү теләге туа һәм фәнгә, музейга карата кызыксыну уяна. Иҗади эшчәнлек тәҗрибәсенә ия булган саен укучыларның белем сыйфаты да үсә. Әдәбият фәне катлаулы да, кызыклы да, шуңа аны программада бирелгән дәрес кысаларына гына сыйдырып бетереп булмый. Безнең очракта әле ул икеләтә кызыклы, чөнки укучылар әдәбият белән генә түгел экскурсовод эшчәнлеге белән дә танышалар, шул юнәлеш буенча китәләр дә. Татар балалары гына түгел ( татар язучысы музее булу - үзе бер стимул), башка милләт балалары да (бездә исә 5 милләт вәкиле укый) музей белән, язучы белән кызыксынып фәнни хезмәтләр язалар.

Бу заманча проект эшкәртмәсендә балаларның аралашу күнекмәләрен камилләштерү, диалогик һәм монологик сөйләмне дөрес формалаштыру, сөйләмдә сүзләрне урынлы куллануга ирешү сөйләм телен камилләштерү юллары бирелә. Өстәвенә, укучылар язучының иҗаты, аның әйтергә теләгән уй-фикерләре аша әхлакый тәрбия нормалары да алалар, әдәбиятка тартылалар. Эш түбәндәге тәртиптә барса балалар регулятив, коммуникатив, танып-белү, шәхескә кагылышлы гамәлләрне үзләштерәчәк.

*Автор: Мостафина Алинә Равил кызы, Яшел Үзән муниципаль районыАфзал Шамов исемендәге Татар Танае урта мәктәбе, 11 нчы сыйныф укучысы*

*Җитәкчеләр: педагог-организатор Мостафина Сания Бари кызы, татар теле һәм әдәбият укытучысы Тимершина Сания Габрахман кызы*

## "Афзал Шамов музеена сәяхәт"

Эчтәлек

I. Кереш өлеш
II. Төп өлеш
1) Балачак сәхифәләре
2) Яшьнәп үткән яшьлек
3) Иҗат адымнары

4) Сугыш юллары буйлап

5) Иҗат иттең син халыкка,

Исемең керде тарихка.

III. Йомгаклау

IV. Кулланылган әдәбият-музей материаллары.

V. Кушымта

**Хезмәтне башкаручы:** Мостафина Алинә Равил кызы

**Җитәкчесе:** Тимершина Сания Абдрахман кызы

**Эшнең максаты:** Афзал Шамовның иҗади мирасын өйрәнү, татар әдәбияты тарихындагы күпкырлы эшчәнлеген ачыклау. Укучыларда гражданлык-потриотик хисләр тәрбияләү, китап укуга мәхәббәт уяту, китап уку аркылы рухи байлык, әхлак, мәрхәмәтлелек кебек сыйфатларны үстерү, туган телебездә милли тәрбия бирү

**Бурычлар:**

1. Авылдашыбыз Афзал Шамовның иҗади мирасын өйрәнү
2. Мәктәп укучыларында гражданлык-потриотик хисләр тәрбияләү

**Эзләнү ысуллары:**

-мәгълүмат туплау;

-мәгълүматны эшкәртү;

**Эзләнү объекты:** А. Шамовның музее.

Быел Афзал Шамовның тууына 116 яшь, шул уңайдан мин сезне бүген Яшел Үзән районы Татар Танае авылы мәктәбендә урнашкан Афзал Шамов музеена сәяхәткә алып китәм.

Музейның максаты:

1. Аның белән горурлану хисе уяту.
2. Язучының иҗатына, туган җиргә, туган телгә мәхәббәт тәрбияләү.

Кеше гомере шәм кебек бит ул. Күз ачып йомганчы яна да бетә. Кемдер кыска гына вакыт эчендә эзсез югала, ә кемдер исемен мәңгеләштереп калдыра.

Авылдашыбыз, күренкле татар язучысы Афзал ага Шамов әнә шундый бөек шәхесләрнең берсе.

Габдрахман ага Әпсәләмов сүзләре белән әйтсәк: “Ак чәчле, күркәм йөзле, тыныч табигатьле, кешелекле һәм мәрхәмәтле Афзал ага Шамов безнең әдәбиятның түренә яшенең өлкәнлеге, талантлы әдәби әсәрләр язганлыгы өчен генә түгел, бәлки кешелек сыйфатлары өчен дә менеп утырды”.

**1. “Балачак сәхифәләре”(Кушымта №1)**

Якташыбыз, авылдашыбыз Афзал Шамов, 1901 елның 4 мартында элеке Казан губернасы Зөя өязе Әҗәл волосте Татар Танае авылында хәлле крестьян гаиләсендә туган.

Ун яшенә кадәр әти-әнисе белән бергә бабасы йортында үсә. Бабайның гаиләсе авылдагы иң зур патриахаль гаиләләрнең берсе була. 4 улының 3есе өйләнгән, шулай да бабай улларының берсен дә үз башларына аерып чыгарырга теләми, хуҗалыкның таралуыннан, җимерелүеннән курка, гаиләсендә кашык күтәрүчеләр саны 20 дән артык булса да, бергә яшәүне артыграк күрә.

Башлангыч белемне 1907-09 елларда авыл мәзинендә ала. Шуннан соңгы 1909-1914 елларда Бузай, Олы Өтәк, Татар Танае кадим мәдрәсәсендә укый.

Күрше Колабирде авылының башлангыч земство мәктәбендә белем ала, 1915-16 елларда Акъегет авылының русча-татарча мәктәбендә укуын дәвам итә. 1916 елда ТатарТанаенда яңача мәктәп ачылгач, шунда кайта.

1917-18 елларда “Касыймия” мәдрәсәсендә укый.

**2. “Яшьнәп үткән яшьлек”(кушымта №2)**

Мәдрәсә тәмамлап, туган якларына кайткач, А. Шамов укытучылар әзерли торган курсларда укый. 1918-1919 елда башлангыч мәктәптә укыта башлый.

1919 ел башыннан Казандагы “Эш” (хәзерге “Ватаным Татарстан”) газетасында авыл хәбәрчесе булып катнаша. Хәбәрләрдән тыш, бер шигыре дә басыла. Ләкин Г. Камал белән Ибраһим Куди аңа шигырь язарга киңәш итмиләр. Шуннан соң “Очрашу” исемле хикәя яза.

"Газета мөхәррире Вәли Шәфигуллин кульязманы үз алдымда укып чыгып, бер төзәтүсез кабул итте, басарга булды", - дип яза А.Шамов истәлекләрендә.

1919 елның көзендә Олы Кошман авылына күчә, анда ай ярым чамасы мәктәптә эшли.

1920 елда берничә ай Казан хәрби хуҗалык курсларында укый. Кави Нәҗми дә аның белән бергә була.

1920 елның август ахырында үзе теләп гражданнар сугышына китә.

Курсантларның 3нче Киев бригадасы составында башта барон Врангель гаскәрләренә каршы сугыша, мәшһүр Перекоп сугышларында катнаша.

**3. "Иҗат адымнары"(кушымта№3)**

1922 елның сентябреннән – 1925 елга кадәр А. Шамов Казан дәүләт университеты рабфагында укый. Шул ук елларда Казанда клуб мөдире булып эшли.

1923 елда яңадан хикәяләр, нәсерләр яза башлый. "Мәрҗәннәр һәм кешеләр" әсәрен тәрҗемә итә.

1926-1930 елларда Афзал Шамов Мәскәүдәге Беренче дәүләт университетының әдәбият һәм сәнгать факультетында укый. Шул ук елларда Мәскәү пролетар язучылар ассоциясе (МАПП)нең татар секциясендә эшли.

А.Шамов "Эш" газетасында эшләгәндә, берничә псевдоним белән йөри: Әлифшин, Кызыл йөрәк, Юлаучы, Афзал Шиһабетдинов, Афзал Шамов, А. Туйгын имзалары белән дә басыла. 1925 елдан бер генә псевдоним – Афзал Тәүгилде кала.

1929 ел – Шамовлар гаиләсе өчен борылыш елы. Илдә бик кискен шартларда күмәкләштерү процессы бара. Шиһабетдин Шамов гаепләнеп кулга алынгач, зур гаилә таркала.

1929 елның 30 декабрендә "Литературная газета" да "Афзал Шамовка безнең арада урын юк" исемле мәкалә бастырыла һәм Афзал университеттан китәргә мәҗбүр була.

1920-1930 елларда А. Шамов МАПП ның татар бюросында эшли, секретаре булып тора. РСФСР Мәгариф Комиссариаты каршындагы Төрки халыклар бүлегенең укый-яза белмәүне бетерү комиссиясе әгъзасы буларак, зурлар өчен эш китаплары, мәктәп дәреслекләре, методик кулланмалар язуда һәм төзүдә актив катнаша.

1931-1932 елларда А. Шамов Совет язучылары оешмасының сәркатибе.

1931-43 нче еллар А. Шамов Татарстан китап нәшриятендә мөхәррир.

**4. "Сугыш юллары буйлап."№4**

«Халык үзенең батыр улларын онытмый. Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый. Барысы да хәтердә, барысы да күңелдә, барысы да йөрәктә», - дигән А. Шамов

А. Шамов 1943 елның гыйнварендә Бөек Ватан сугышына үзе теләп китә. "Алга, дошман өстенә!" һәм "Суворовча кысрыклау" исемле газеталарда хәрби корреспондент булып эшли.

"Алга, дошман өстенә!" дигән фронт газетасын татар сугышчылары беренче номерыннан ук үз итәләр, аның эчтәлеген, сыйфатын яхшырту турында үзләренең күп кенә кыйммәтле киңәшләрен бирәләр.

Биредә Сез шушы газеталарда басылып чыккан кайбер мәкаләләрне һәм Афзал Шамов үзе язган әсәрләрнең кайберләрен күрәсез.(кушымта №5)

Ә мин сезнең игьтибарыгызны шушы ике язмага юнәлтмәкче булам. (кушымта №6)

Берсе аның Татар Танае авылы кешесе Гатауллин Әсгатьнең Афзал Шамов очрашуы хакында фронттан язган хаты. Ә икенчесе А. Шамов көндәлегендә Гатауллин Әсгать белән очрашу турындагы белешмә.

1945 елның 18 апрелендә Көнчыгыш Пруссия фронтында танк янында Гатауллин Әсгать үзенең авылдашы язучы Афзал Шамов белән күрешүе хакында өенә әти-әнисенә хат язып җибәрә. Хатта озакламый дошманны җиңеп, исән-сау туган иленә кайтырга хыяллана. Өенә бер-бер артлы 5 хат җибәрә. Әсгатьнең яшәүгә булган зур мәхәббәте, туган иленә, әти-әнисе янына кайтуына зур ышаныч була. Әмма рәхимсез үлем Көнчыгыш

Пруссия җирләрендә аны ятып калырга мәҗбүр итә. Авылга килгән извещение нигезендә без аның 1945 елның 6 июлендә үлгән икәнен беләбез.

Язучы А. Шамовның кызы Әлфия апа Шамова истәлекләренә нигезләнеп язылган "Соңгы хатлар һәм соңгы сугышлар " исемле мәкаләсеннән күренгәнчә, язучының архивында Бөек Ватан сугышы чорына караган әллә никадәр документаль материаллар ята икән.

15 фронт блокноты, 1943-1945 нче елларда Калинин һәм I Балтыйк буе фронтларында язучы үзе очраткан һәм алар турында материаллары булган сугышчылар исемлеге ( 500дән артык исем!) дистәләрчә фронт газеталары, фронттан рәсемнәр, сугышчан листовкалар, гади солдат хатлары һәм фронтлардагы каләмдәш дусларыннан килгән хатлар.

Хат авторлары арасында- сугыш кырында ятып калганнары да, сугыштан соң арабыздан киткәннәре дә бар.

Язучы Афзал Шамов армиядән демобилизацияләнеп, 1946 елның 27 апрелендә Казанга кайта.

**5 . "Иҗат иттең син халыкка,**
**Исемең керде тарихка" (кушымта №7)**

"Иҗат иттең син халыкка,Исемең керде тарихка" исемле стендта Афзал Шамовның туганнары, балалары, оныклары белән төшкән фото сурәтләрен күрәсез. (кушымта №8)

Сугыштан соң, 1949-50 елларда Афзал шамов "Совет әдәбияты" журналының редакторы.

1958-1961 елларда Татарстан язучылар берлеге идарәсе рәисе була.

1962 елдан профессиональ язучы булса да, республикада мәдәни тормышында актив катнашуын дәвам итә.

1959-1963-КПССның Татарстан өлкә комитеты әгъзасы буларак та белешмә бирелгән.

Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары өчен Афзал Шамов Кызыл Йолдыз (1944), күпьеллык актив, җәмәгать эшчәнлеге һәм әдәби иҗаты өчен Хезмәт Кызыл Байрагы (1957), Октябрь революциясе (1971) орденнары һәм 15 ләп медальләр белән бүләкләнә.

Афзал Шамов бик оста тәрҗемәче дә була. Биредә сез Николай Островский, Александ Фадеев, Александр Сергеевич Пушкин, Лев Николаеевич Толстой әсәрен Афзал Шамов тәрҗемәсендә күрәсез. (кушымта №9)

Афзал ага публисцистика һәм тәнкыйть өлкәләрендә дә актив хезмәт итә.

Биредә Афзал Шамов үзе иҗат иткән бик күп төрле әсәрләрнең төрле елларда басылып чыккан кайбер нөсхәлләрен күрәсез.(кушымта №10)

Бөек Ватан сугышы чорында документлар арасында якын дусты Ибраһим Гази белән язышкан хатлар аерым урын алып тора.(кушымта №11)

А. Шамов 90 яшь тулган көнне күрә алмыйча, 1990 елда вафат булды. А.Шамов дигәч тә, искә кылт итеп "Рәүфә" повесте килеп төшә. Укучы күңелендә ничәмә-ничә еллар саклана икән, димәк, ул талантлы каләм иясе тарафыннан иҗат ителгән классик әсәр.

Күренекле әдипнең тормыш юлы да, ул тудырган әдәби геройлар да өйрәнүгә, үрнәк алуга лаеклы. Халкым олы язучыга хөрмәт күрсәтә. Халык яраткан язучысын онытмый, ә әсәрләре безне кешелекле, үз илен яратуга ватанпәрвәр булырга тиешлекне аңлата.


**Кушымта**
**№1**


БАЛАЧАК СӘХИФӘЛӘРЕ
АФЗАЛ ШАМОВ ИСТӘЛЕКЛӘРЕННӘН


ЯШЬНӘП ҮТКӘН ЯШЬЛЕК

№2

№3


ИҖАТ АДЫМНАРЫ



СУГЫШ
ЮЛЛАРЫ
БУЙЛАП
ФРОНТТА ОЧРАШУ

№4


№5


ФРОН
ГАЗЕТАСЫ
ЯЛГЫ

№6



Гатауллин Әсгатьнең Афзал Шамов белән очрашуы хакында фронтта язылган хаты. 19 апрель 1945 ел.



Афзал Шамовның көндәлегендә Гатауллин Әсгать белән очрашу турында белешмә. 18 апрель 1945 ел.

№7




№8



№9


А. ФАДЕЕВ
Н Островский
КОРЫЧ НИЧЕК ЧЫНЫКТЫ
ЯКТЫ ЯР
А. ТОЛСТОЙ
ХАҖИ МОРАТ
АФЗАЛ ШАМОВ
ТӘРҖЕМӘ ИТКӘН ӘСӘРЛӘР
Л.Н.ТОЛСТОЙ
А.С.ПУШКИН
ЯҢАДАН ТУУ
Тәрҗемә әсәрләр
QЬZЬL DESANT

№10


СайлАнмА Әсәрләр
Яңгырлы кичтә
Афзал Шамов
Зөя буенда
АФЗАЛ ШАМОВ
ӘСӘРЛӘРЕ

№11






Афзал Шамовның әтисе белән әнисе.

**Секциянең исеме: “Каләм! Калбеңдә ни сер бар, гаян ит. Килеп-кичмешләр әхвален бәян ит!”**

*Автор: Вахитова Илүзә Фиркать кызы, 8 сыйныф*
*Фәнни җитәкче: Җамалиева Ләйсән Ильяс кызы*
*Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Хәй Вахит исемендәге Мәмдәл урта мәктәбе*

## Үкенү

-Улым, кайттыңмы?-дип каршы алды Гөлүсә улын.

-Кайттым инде, ашарга нәрсә бар? – дип кычкырып җибәрде Рамил.

Рамил кухняга узды да, суыткычны ачып, нәрсәдер эзләргә тотынды. Әнисе аңа өстәл артына утырырга кушты. Рамил,шырылдап, ишекне каты ябып, үз бүлмәсенә чыгып китте.

Бер-ике минуттан әнисе пешергән тавык шулпасы өстәлдә иде инде. Әнисе Рамилгә бер кереп әйтте, ике әйтте, ләкин улы компьютердан аерыла алмады. Әнисенең сабырлыгы бетеп, барып компьютерны сүндереп куйды. Рамилнең бу хәлгә ачуы чыкты, әнисенә сүгенеп җибәрде.

- Синең ничек телең бара? Миңа, сөйләшергә өйрәткән әниеңә, ничек шулай дәшә алдың!?-диде дә, әнисе еларга тотынды. Нәкъ шул вакытта кухнядагы радиодан: “ Үз баламның сүзләре бит, рәнҗемә, йөрәгем, түз! Туры йөрәкка кадала бала әйткән авыр сүз. Балам, әйтмә авыр сүз!”-дип җыр яңгырады. Рамил кызарынды, бер сүз дә дәшмичә, урамга чыгып китте.

Сәгать кичке бишләр тирәсендә әтисе эштән кайтты. Рамил әтисенә ертык кроссовкасын күрсәтте. (Әнисе алып биргән кроссовканы ошатмыйча, ул үзе ертып куйган иде. Бу хакта беркем дә белмәде.) Әтисе яңа кроссовка алырга ризалыгын бирде. Ата белән улның сөйләшүен ишек яңагына сөялеп тыңлап торган Гөлүсә бу хакта беренче мәртәбә ишетә иде.

Аяк киемнәр шкафында яңа кроссовка үз хуҗасын көтүен дәвам итте. Рамилгә бу кроссовка да ошамады.

Әтисе улындагы үзгәрешләрне сизеп, аяк киемен тотып, урамга чыгып китте. Бер илле метр ара узгач, яланаяклы, ябык кына кара чәчле бер малай күренде. Бу ятим малайны Илдар белә иде. Малай да үзенә акча биргән абыйны бик тиз танып алды. Аягына яңа кроссовка киеп алган ятим малайның бәхете җиде кат күкләрдән дә ашты.

Бу хәлне күреп торган Рамилгә бик оят булды. Әнисе белән әтисеннән гафу үтенергә ул өенә ашыкты.

*Автор: Гафиятуллина Энҗе Илшат кызы*
*Фәнни җитәкче: Маннапова Диләрә Эльбрус кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
*Яшел Үзән шәһәре 4 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе*

**Илем- ак күгәрченем**

Бәхетлемен җирдә яшәвемә

Һәр нәрсәдән шатлык ,ямь табам.

Тыныч илнең бер шат баласы мин

Һәр тарафка карап сокланам.

Урманнарың иркен, кырларың киң,

Елгаларың чиксез,мәһабәт.

Кешеләрне дә гел бизәп торсын

Хөрмәт, шәфкать, ярдәм,мәрхәмәт.

Гөлчәчәкләр үсә җиребездә,

Ак күгәрчен оча һавада.

Тыныч илдә укып,белем алып

Яшибез бит , дуслар, дөньяда

Мин бәхетле җирдә яшәвемә.

Һәр нәрсәне сөям,сокланам

Җир йөзендә ап-ак күгәрченнең

Тыныч яшәвенә ышанам .

*Автор: Сабирҗанов Булат Рәис улы, 7 сыйныф*
*Фәнни җитәкче: Сабирҗанова Гөлнара Фоат кызы*
*МБГБУ «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Аксу урта гомуми белем мәктәбе”*

**Гомернең мизгелләре**

Казан һәр көнне кайнап шаулап тора. Һәркем үз мәшәкате белән каядыр ашыга. Яңа туган көн туу белән яңа борчу мәшәкатьләр, кайгы – сөенечләр барлыкка килә. Көн саен йөгерәбез, чабабыз, ә эшлисе эшнең очы – кырые күренми, гел каядыр ашыгабыз, янәшәбездә кемнәр, аларның нинди борчулары яки шатлыклары бар, нинди уйлар белән яшиләр – туктап ул турыда уйларга һич вакыт та, хәтта теләк тә юк.

Көн саен иртә белән күпчелек казанлылар эшкә ашыга. Яңа туган көнгә куанып, яңа өметләр белән урамга чыгалар. Кышкы көн искиткеч матур, иртәнге саф һаваны рәхәтләнеп сулыйлар, ә күктән иренеп кенә кар бөртекләре коела. Табигать искиткеч юмарт һәм гаделъ. Үзенең мамыктай ак бөртекләре мәһабәт йорт түбәләренә, тыз – быз чапкан машиналарга, бер ваемсыз урамда йөгереп йөргән көчеккә, эшкә ашыгучы казанлылар өстенә куна.

Әнә иртә таңнан авыр капчыгын асып көнбагыш сатарга чыгып утырган татар әбиләренә дә куна кар бөртекләре. Алар бит җылы өйләрендә оныкларына тәмле ашлар ашатып мәктәпкә озатып, балаларның кадерен күреп яшәргә тиешләр. Тормышлары җитеш булса, картлык көнендә болай изаланмаслар иде бит. Көнбагыш сатучылар рәтендә бүген бер урын буш тора. Сара әбинең оныгы Радикны җирләгәнгә җиде көн. Оныгын бик ярата иде Сара әби. Бу бәла алар гаиләсенә ничек кагылды соң?

Радик тыныч бала булды, мәктәпне дә ата – анасына борчу китермичә генә тәмамлады. Ә яңа танышлары тәкъдим иткән агулы рәхәтлекне бер татып карагач, наркоманиянең чәнечкеле тоткынлыгыннан ычкынырга үзендә көч тапмады.

Көнбагыш сатучы әбиләр бүген сүзсез. Мондый кайгы шәһәребезнең күп гаиләләренә кагылды. Бер–беребезгә игътибарлырак булсак иде,әй кешеләр! Тирә – ягыбызда кемнәр бар, алар безнең ярдәмгә мохтаҗ түгелме? Шәһәребез-киләчәгебезнең киләчәге. Киләчәгебез матур якты булсын, һәркем кулыннан килгәнне эшләсен иде.

Әйе, Сара әбинең кайгылы көннәре күп булды. Аның үткән көннәре шушы гүзәл шәһәр белән бәйле, барлык кайгы – хәсрәтләренә, шатлык – сөенечлә-ренә Казанның онытылмас кичләре, алсу таңнары, Казансу буйлары шаһит.

Казансуы өсләрендә акчарлаклар уйныйдыр.
Акчарлаклар елда кайта.
Үткән гомер кайтмыйдыр.
Әй Казансу, Казансу
Гомерләре ямансу.

Казанның үткәне дә бүгенгесе дә аның күз алдында. Казан көннән – көн үсә, матурлана.

И сокланыр иде Тукай күрсә,
Нурлы Казан, яңа Казанны,
Азат халкын,йолдызларга җитеп
Күтәрелгән безнең заманны.

Әйе, Казан үсте, үзгәрде. Ел саен яңадан – яңа йортлар калкып чыга, Казанның тарихы белән бәйле истәлекле урыннар, һәйкәлләр, музейлар ачыла, мәдәният учаклары халыкны әдәби кичәләре, яңадан–яңа спектакльләре белән шатландыра, яңа биек манаралар өстендә алтын айлар балкый, халыкны иманга өндәп азан ишетелә. Казансу буенда чал Казаныбызның тарихын чагылдырган мәһабәт бина – Сөембикә манарасы тора. Әйтерсең ул Казанның бүгенге көнен күрүенә горурлана.

Үсә Казан, гөрли Казан
Туган ил кочагында.
Бүген гүзәл, киләчәге
Гүзәлрәк тагын да.

Әйе, шушындый гүзәл Казанны Радикның гына күрә алмавына Сара әбинең күңеле әрнеде һәм моның белән килешергә теләмәде дә.

- Эх, Радик! Әнә дусларың рәхәтләнеп сөйләшәләр, шаяралар, бер- берсен аңлашып вакыт үткәрәләр, гомер сөрәләр. Ә син юк шул, сөйләшә алмыйсың. Бары тик, каберең ягыннан искән талгын җил шаярта, уйный гына.

Сара әбинең гомере бер мизгел булып күз алдыннан үтте. Узган гомерен сагынып һәм яшьли шушы матур тормыштан "китеп барган" оныгын кызганып, күзләреннән яшьләр тәгәрәде. Тиз генә кочаклыйсы, иркәләп аласы иде дә бит. Юк,Радикны күпме көтсә дә, кайтмый шул. Оныгын бик сагына ул.

Һәм кинәт Сара әбинең хәле китеп барды. Ул урындыкка барып утырды да, соңгы сулышын сулап , оныгы янына "ашыкты".

*Автор: Вахидова Кадрия Ринатовна, Яшел Үзән шәһәренең 10 нчы гимназиясе, 8 нче сыйныф*
*Фәнни җитәкче: Җамалиева Лилия Илгиз кызы*

**Татарлар без!**

Кайда гына яшәми ул татар,
Сибелгән ул дөнья, ил буйлап.
Кайда гына торса, яшәсә дә,
Милләтемне йөри ул данлап.
Уңган да ул, булган да ул татар,
Һәр өлкәдә бит ул сәләтле.
Җиң сызганып эшли, хезмәт сөя,
Үз итә ул җырны, сәнгатьне.
Акыллы да, горур да ул татар,
Ничә гасыр сынмый яшәгән.
Кылыч белән башын кискәндә дә,
Ул җыр булып җанда яшьнәгән.
Туган ягым-тау ягында гына
Күпме талант яши, яшәгән.

Татар дигән горур исемебезне
Данга күмеп алар эшләгән.
Олы галим- Насыйрины биргән
Гүзәл якта гомер итәбез.
Татар булуыбызга горурланып,
Без дә
Милләтебезгә хезмәт итәрбез.
Каюм бабай сызган олы юлдан-
Мәгърифәтле юлдан атлыйбыз.
Аң-белемле, уңган, горур халык,
Бик зур халык-татар халкы без!

*Автор: Загриева Камилә Рамилевна, Яшел Үзән шәһәренең 10 нчы гимназиясе,7 нче сыйныф*
*Фәнни җитәкче: Җамалиева Лилия Илгиз кызы*

**Бүре белән куян (мәсәл).**

Бердән бер көнне
Бүре ачыкты.
Азык эзләп ул
Зур юлга чыкты.
Шактый юл узгач,
Өшеде бүре...
Шулчак алдында
Бер куян күрде.
Әйтте ач бүре:
"Нихәл, куянкай!
Аяклы азык-
Озын колаккай!
Мин сине хәзер
Ашыйм бик тәмләп,
Тирең дә калмас,
Тормам мин жәлләп..."
Куян куркудан
Калтырап куйды.
Әмма шунда ук
Бер план корды:
-Ашама мине,
Бүре абзыкай,
Миннән башка да
Күп бит азыклар!
Ә-әнә тегендә-
Усак төбендә
Бергә гөрләшеп
Өч куян яши.
Үзләре таза,
Симезләр бик тә,
Алар бит сиңа
Өч көнгә җитә!
Бүре эченә
Җылы йөгерде:
Куян күрсәткән
Якка элдерде.
Әллә бүренең

Исен сизгәннәр,
Теге куяннар
Чыгып сызганнар...
Гарьлектән бүре
Бик тә дулады,
Яман үкерде,
Яман улады.
Алдар куянны
Эзләп тапты ул.
Шунда ук аны
Кабып йотты ул...
Бу мәсәлнең морале-
Алдар куян кебекләр
Арабызда бар әле.

**Якташым-горурлыгым!**

Шырдан. Каюм Насыйри.
Бу исемнәр ни сөйли?
Гүзәл як. Олы галим.
Күңелне
Горурлык хисе били.
Гади авыл. Зур галим!
Теләсә нинди өлкәдә
Булмаган бит аңа тиң!
Галим дә ул, мөгаллим дә,
Фольклорчы, тәрҗемәче,
Тәрбия өлкәсендә
Менә дигән киңәшче!
Хезмәтләре алдында
Килә башым иясе.
Ул бит минем якташым-
Бөек акыл иясе!

*Автор: Шәйдуллина Линиза Фәнисовна, Яшел Үзән шәһәренең 10 нчы гимназиясе, 6 нчы сыйныф*
*Фәнни җитәкче: Җамалиева Лилия Илгиз кызы*

**Суган нигә ачы?**

Мәдинәне бүген дусты Әминә кунакка чакырды. “Дәү әнием тәмле өчпочмаклар пешерә, кил әле, чәй эчәрбез бергә”,-диде. Дустына барырга ярата Мәдинә. Алар бергә дәресләр әзерлиләр, уйныйлар. Дәү әнисе Сания апа да бик әйбәт кеше.Ул беркайчан да аларны әрләми. “Кызларым минем,”-дип кенә тора. Әминәнең әнисе юк. Ул тугач та үлеп киткән. Аны әтисе белән дәү әнисе тәрбияли. Әнисе бик матур булган аның. Фотосын күрсәткән иде Әминә. Әнисе турында сөйләгәндә әллә ничек моңсуланып кала ул...

Мәдинә килгәндә Сания апа камыр ясый, Әминә суган турый иде.”Мәдинә кызым килгән икән, әйдә, уз,”-дип каршы алдылар аны. “Миңа суган турарга булышасыңмы?”-диде Әминә. Әлбәттә инде,булыша. Дустына булышмыймы соң?!

“Суган нигә ачы икән шулай?Елата бит!”-диде Мәдинә. ”Ә синең суган турындагы әкиятне ишеткәнең юкмыни?”-диде дусты суган турый-турый.”Юк “ дигәнне аңлатып, башын селкеде Мәдинә. Үзе күзеннән аккан яшьләрен сөртеп куйды. “Тыңла алайса, сөйлим,”-диде Әминә һәм менә шушы әкиятне сөйләде.

Борын-борын заманда, бик матур бакчада яшәгән, ди, суган гаиләсе. Сугансылу исемле кыз һәм аның әтисе Суганбаш белән әнисе Суганбикә. Бик матур гаилә булган ул.

Сугансылу әтисе белән әнисен бик-бик яраткан. Аларның сүзләрен тыңлаган, күзләренә генә карап торган.

Шундый матур, кояшлы июль көннәренең берсе була. Бик эссе, кояш кыздырыпмы кыздыра. Шулчакта әллә каян гына җил чыга, күк йөзе караңгылана башлый. Күктәге болытлар шундый карала, шундый карала. Җил тагын да көчәя. Менә эре-эре тамчылар төшә башлый.Тукта! Боз түгелме соң бу?Боз ич, боз! Шундый каты төшә! Шул вакытта Сугансылу әтисенең: ”Кызыбызны саклыйк, кызыбызны,”-дигән сүзләрен ишетеп кала. Кинәт бөтен дөнья караңгылана. Әтисе белән әнисе үз гәүдәләре белән аны каплаганнар икән...

Ничек кинәт башланса, шулай тиз генә туктый бозлы яңгыр.Туктавын да туктый, тик бик күп яшелчә, җиләк-җимешне юк итә. Сугансылуның әтисе белән әнисе дә һәлак булалар...Йә, Ходай! Бу кайгыга ничек түзәргә??? Елый да елый Сугансылу, елый да елый...Күз яшьләре шундый ачы булган, шундый ачы! Яшь ачысы бөтен тәненә таралган, ди. Шуннан сон бөтен суганнар да ачы булып туганнар.

Сания апа белән Мәдинә шаккатып тыңлады бу экиятне . Кайдан ишетте икән моны Әминә? Үзе уйлап чыгаргандыр әле. Үзедер. Мәдинә Сания апага күтәрелеп карады. Аның күзләрендә яшь бөртекләре җемелди иде. Елатты шул Сылу, елатты...

*Автор: Галәтдинова Алия Илсур кызы, 4нче гомуми урта белем бирү мәктәбе МГББУ,3 А*
*Фәнни җитәкче: Ишметова Фирдинә Салих кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Кышның салкын айлары**.

Салкын кышлар килде җиргә
Акка күмеп дөньяны.
Сөендереп,шатландырып
Барлык бала-чаганы.

Кыш айлары шундый матур,
Назга төрә дөньяны
Ап-ак юрган ябындырып,
Иркәли агачларны.

Әй ,рәхәт тә,күңелле дә
Кышның салкын айлары.
Җәйләр җиткәч,сагындыра
Чана шуган чакларым.

*Автор: Җантимерова Илүзә Илһам кызы, 4нче гомуми урта белем бирү мәктәбе МГББУ,3 б*
*Фәнни җитәкче: Ишметова Фирдинә Салих кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Габдулла Тукайга**

Кошлар кайта төркем-төркем
Сандугачлар,тургайлар.
Яшәреп китә табигать
Үзәнлекләр,тугайлар.

Шундый матур язгы көндә
Габдулла Тукай туган,
Илебезнең җире-күге
Бәхет нурына чумган.

Тукай абый әсәрләрен
Без яратып укыйбыз:

“Туган тел”ен гел җырлыйбыз,
Әкиятләрен уйныйбыз.

Бөек Тукай,синең исемең
Мәңге яши күңелдә.
Шигырьләрең зур этәргеч
Туган телне белергә.

*Автор: Хәйретдинова Камилә Илнур кызы, Гомумбелем муниципаль бюджет учреждениесе Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы 1 нче Лицей, 2 нче сыйныф*
*Фәнни җитәкче: Сабирова Зөлфия Сәлимҗан кызы*



**Беренче адымнар**

Әнием- иң якын кешем.
Әниемә булышам.
Минем исем– Камилә.
Укыймын икенчедә.
Әниемә булышам,
Булсам да нәни генә.
Чәчәкләргә су сибәм,
Матур гөлләр үстерәм.
Тәмле коймак пешерәм,
Барысына да өлгерәм.



Минем әнием.

Минем әнием бик матур, акыллы һәм яхшы. Шулай ук ул чисталык ярата. Һәрвакыт әни авыр минутта миңа ярдәм итә. Әни безнең өчен тәмле аш пешерә. Без аны барысы өчен дә бик яратабыз!

Безнең дусларыбыз.

**Минем канатлы дусларым.**

Кошларга җимлек ясарга,
Булышты әтием дә.
Әнием дә ярдәм итте,
Җим сипте әбием дә.
Безнең серле ашханәгә
Рәхим итегез, дуслар!
Тәмле- тәмле җимнәр сиптек,
Көтәбез сезне, кошлар.
Чыпчык көнбагыш яратса,
Ә песнәккә ит кирәк!
Канатлы дусларыбызга
Ярдәм һәрвакыт кирәк!.
Кызыклы конкурс өчен,
Сезгә рәхмәт әйтәбез!
Әйдәгез, кошкайларга
Һәрчак ярдәм итәбез!

Туган ягым- яшел бишек.

Туган җирем.

Түгәрәк күл, яшел урман,
Елга-суларга бай як.
Кошлар сайрый тирәкләрдә
Ямьле дә син, туган як.

Минем песием- Шаян.

Минем песи бик тә наян,
Исеме аның Шаян.
Интернетны бик ярата,
Рәсемнәр таба кайдан?

Әкият сөйлим сезгә...



Тамчы.

Бервакыт яңгыр ява башлады. Яңгыр тамчыларының берсе тылсымлы һәм тере иде. Ул бер кызның учына тамды. Алар икесе дә курыктылар. Кызның тере тамчыны күргәне юк иде. Алар дуслаштылар һәм бергә уйный башладылар. Ләкин тамчыны өйдә әнисе көтә һәм борчыла иде. Тамчы кыз белән саубуллашты да, яңадан өскә күтәрелде. Аны өйдә әнисе каршы алды һәм бик шатланды.

*Автор: Ахметзянов Артур Рамисович, 17 мәктәп, 8 нче сыйныф.*
*Фәнни җитәкче: Миндибаева Зөмәрә Тәхәү кызы*

**Әбием мәкальләре.**

Кайчакларда әбиемнең,
Сүзләренә хәйран калам.

Мәгънәсен  аңлар өчен,
Кулларыма сүзлек алам.

Мәгънәле сүзләр икән:
Илен сөйгән мәңге яшәр.
Муса кебек ир-егетләр
Бөеклеккә безне дәшәр.

Киләчәккә юл күрсәтер,
Шигырендәге һәрбер сүзе.
Батырлыкта-матурлык,–дип
Әйтә кебек шагыйрь үзе.

Үлем аша үлемсезлек,
Яулый алган тугры йөрәк.
Җәлил бөркет- патриот,
Без,яшьләргә, һәрчак кирәк!
Без ,яшьләргә, һәрчак үрнәк!

**Уйлану.**
Үскән саен уйландыра,
Яшәвемнең асылы.
Тормышымда эз калдыра,
Елның һәрбер фасылы.

Җәйләр мине иркәлиләр,
Кояш тулы иртәләр.
Кызынасың, коенасың,
Юк бит безгә киртәләр.

Көзләр мине тукландыра
Муллык итә тантана.
Белем дигән сарайларга
Күпме юллар таптала.

Кышлар миңа аклык бирә
Салкын,чиста,саф һава.
Күңелләрне сафландырып
Салмак кына кар ява.

Язлар миңа яшәү яме,
Чәчәк бүләк итәләр.
Зәңгәр карлар сулар булып,
Еракларга китәләр.

Һәр фасылның үз төсе бар
Табигатьтә юк ялган.
Матурлыкны саклау хисе
Күңелне биләп алган.

*Автор: Лужаев Вадим Сергеевич, Куралово урта гомуми белем бирү мәктәбе , 10 нчы сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Нуруллина Сүрия Илгиз кызы*

*ПЕСИКӘЙ*

Минем песи бик шаян
Тора ул иртә таннан
Иң беренче киерелә
Аннан сыртын күпертә
Аннан мине уята
Мыраулап, битен юып
Әгәр ашатмасан син
Мин сине тырныйм ди ул
Ә инде ашап туйгач,
Битләрен юа башлый
Бик тырышып ялый ул
Бөтен җире ялт итә
Их син песи, песикәй
Битне алдан юалар
-“Юк” ди ул мыек  астыннан
Песиләр алдатмыйлар.

**Туган ягым**

Югары Ослан-
Минем туган ягым
Нинди матур таулы ягым син
Чишмәләре, Идел елгалары
Челтерәп ага тәмле сулары
Нинди горур карап торасын син
Кыя ярдан Казан  ягына
Мәчетләре,чиркәүләре сине
Сәламниләр һәр көн саенда

*Автор: Ярматова Ильмира Искәндәровна, Яшел Үзән шәһәренең 10 нчы гимназиясе, 6 нчы сыйныф*
*Фәнни җитәкче: Җамалиева Лилия Илгиз кызы*

**Мин-табигать баласы**

Болында йөримен мин,
Матурлык күзлимен мин.
Яшел болын, зәңгәр күк-
Гүзәллеккә чикләр юк!
Чирәмгә ятам әле,
Күзләрем йомам әле.
Нинди рәхәт, беләмсез?
Яшел бишек, күрәмсез?
Чәчәкләрдән мендәрем,
Зәңгәр болыт-юрганым.
Җил тирбәтеп йоклата,
Кояш назлап уята.
Мондый тиңсез матурлыкны
Тагын кайдан табасы?
Туган җирдә бәхетлемен,
Мин-табигать баласы!

*Автор: Багабиева Регина Рәмил кызы, Яшел Үзән шәһәре,  А.С.Пушкин исемендәге 9 нчы лицей, 10нчы сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Бәдретдинова Динә Сәлим кызы*

**А.С.Пушкинның “Евгений Онегин” романыннан “Татьянаның Онегинга хаты” тәрҗемәсе**

Сезгә язам – инде тагын,
Мин нәрсә әйтә алам?
Минем язмыш сезнең кулда,
Җәзагызны көтеп калам.
Ә сез, минем бәхетсез өлешкә,
Хет тамчы кызгану саклап,
Мине китмәссез ташлап.
Алдан дәшмәскә теләдем,
Ышаныгыз: хурлыгымны,
Сезгә, һич сиздермәс идем.
Әгәр өмет булган булса,
Хет сирәк, хет атнага бер,
Авылыбызда сезне күрү,
Сезнең сөйләгәнне тыңлау,
Сезгә дәшү, ә соңыннан
Яңа очрашуга кадәр
Көне-төне сезне уйлау.
Әйтәләр, сез читләшәсез;
Тын почмакта, авылда,
Сезгә бар да күңелсез.
Ә без... берни белмибез,
Шат булсак та эчкерсез.
Ни өчен соң сез килдегез
Бу онытылган авылга?
Мин сезне белмәгән булсам,
Дучар булмас идем җәзага.
Үз вакытым белән (кем белә?)
Бәлки, тиң табар идем.
Булыр идем тугры хатын,
Мәрхәмәтле ана булып,
Тәҗрибәсез йөрәгемнең
Ярсуларын басар идем.

## Секциянең исеме: Татарстан Республикасының яшь язучылары һәм шагыйрьләре иҗаты

*Автор: Сәлахов Инсаф Марат улы, 1нче Лицей*
*Фәнни җитәкче:Гайнетдинова Рима Абдулла кызы*

# Шагыйрь Рифат Сәлах - гармунчылар нәселеннән

**Эчтәлек**

1. Максат.
2. Бурычлар.
3. Кереш.
4. Төп өлеш:

а) татар гармуны тарихы;
а) шагыйрь Рифат Сәлахның нәсел тарихы;
б) Рифат Сәлах истәлекләре.

5. Йомгаклау.
6. Кулланылган әдәбият исемлеге.
7. Кушымта.( видеофильм)

**Максат.** Яшь шагыйрь Рифат Сәлахның нәсел тарихын **,** әдәп-әхлагын, шөгыль-кәсепләрен өйрәнү**;** нәсел тамырларын өйрәнү өчен кирәк булган мәгълүматны аерып ала белү; фәнни-тикшеренү эшләре белән шөгыльләнергә өйрәнү.

**Бурычлар:**

- туганнырымның нәсел тарихына, шөгыль-кәсепләренә битараф булмау;
- Сәлахлар нәселеннән чыккан яшь шагыйрь Рифат Сәлах белән горурлану;
- нәселебезнең гасырлар буена тупланган әдәп-әхлак нормаларын булдыру;
- иҗат итү омтылышы уяту.

**Кереш**

Сәлахов Инсаф Яшел Үзән муниципаль районы 1 нче Лицей укучысы. Бүгенге сүз башым туганым – яшь шагыйрь Рифат Сәлах турында булыр.

Изге Корбан айларында Сәлаховлар гаиләсе Васильево бистәсенә җыела. Шул көннәрнең берсендә Рәхинә әбием миңа ике альбом бирде. Бу альбомнар гаиләбезнең тарихы, нәселебезнең танылган шәхесләрнең фото- рәсемнәре белән тулыландырылган иде. Аларның тарихы турында, ягъни Рифат Сәлахның нәсел җепләрен эзләнүләрем турында сөйләп китәсем килә. Нәсел альбомын төзүне беренчеләрдән булып, Сәлах бабамның оныгы Ркыяның ире җизнәбез,сугыш ветераны Нурулла абый башлап җибәргән. Ул шәҗәрәне ир туганнары ягыннан да, кыз туганнары ягыннан да алып барган. Нурулла абыйның тырышлыгы нәтиҗәсендә бөтен киләчәк буын туганнарым да ике яклап, үзләренең әби-бабайларын, архивларга бармыйча эзләп таба алачаклар. Ә инде мин әтием Марат ягыннан булган туганым Рифат абыем Сәлахның нәсел тарихын өйрәнергә булдым. Талантлы кеше бөтен яктан да талантлы була инде ул. Рифат абыем матур шигырьләр язу белән беррәттән бик матур итеп гармунда да уйный бит әле ул. Бүген мин сезне аның нәсел җепләре белән таныштырып китәм. Ә инде иҗаты турында киләсе укуларда киңрәк тукталырмын.

**Төп өлеш**

Гармун тарихына тукталып китәсем килә.Борынгы заманнардан ук татар халкы моңлылыгы, уен коралларында оста уйнавы белән аерылып торган. Татар халкында киң таралган уен коралларының берсе – гармун. Уен кораллары арасында иң тирән тойгыларны бирә алган, тормыш сукмагының һәр мизгелендә кешегә юлдаш көмеш телле

татар гармуннары халыкның тормышында аерым урын алып тора. Гармунчының урыны һәрчак түрдән: йөрәктә дә, туй мәҗлесендә дә, бәйрәмнәрдә дә. Халык музыка коралы-гармунның тарихы әллә ни зур түгел. Аны, беренче булып 1782 елда Бушман ясаган дип исәпләнә. Аннан соң гармуннарны Вена шәһәрендә һәм Италиядә, соңрак узган гасырның 30 нчы елларында Россиядә дә ясый башлаганнар. Бу эшнең беренче үзәге Тула шәһәрендә була. Безнең ил осталары гармунны камилләштерәләр, аның берничә төре барлыкка килә. Тула, Саратов, татар гармуны әнә шундыйлардан. Халык арасында киң таралган уен коралы булганлыктан, гармун турында бик күп шигырьләр, чәчмә әсәрләр иҗат ителгән һәм хәзерге көндә дә иҗат ителәләр.

Әби-бабайларыбызның яшьлек елларында иң кадерле әйберләре тальян гармуны булган. Тормышның бар матурлыгы һәм гүзәллеге нәкъ менә шул тальян моңнарында кебек. Тальян моңнары элеккедән килгән гореф-гадәтләр турында сөйләүче дә. Татарларда элек-электән гармунсыз авыл булмаган. Яшьләрнең аулак, өйләре, кичке уеннары берсе дә уен-җырсыз, гармунсыз үтмәгән. Сугыш вакытында да гармун тарта белүче гармун кадәр генә бәләкәй малай авылда иң кадерле зат булган. Аны әнисеннән ялынып сорап, кышкы кичләрдә, кадерләп, чанага утыртып алып киткәннәр, китереп куйганнар. Иң авыр да, иң караңгы көннәр дә халыкны гармуннан аера алмады.

Моннан бик күп еллар элек Буа районының Яңа Чәчкап авылында да гармунчылар бик күп булган, диләр. Сәләх, Сафа бабамнар, Ризатдин, Низаметдин Сәләховлар гына ни тора! Гәрчә бүген дә биредә гармун телләрен тартучылар юк түгел. Алар барысы да заманында оста гармунчылар булганнар, гармуннарын кулларыннан төшермәгәннәр. Өйләрендәге гармун, тальяннарның исәбе-хисабы булмаган.

Бабам Сәләх 1879 нчы елда Чәчкап авылында крестьян гаиләсендә туган. Тормыш иптәше Нәгыймә белән 5 бала- ике кыз, өч ул үстергәннәр. 1941 елдан алып 1945 елга кадәр Бөек Ватан сугышында катнаша. Сугыштан кайткач, төрле җаваплы постларда эшли. Сугыш вакытында да кулыннан гармунын төшерми. Үз һөнәрен улы Сафа бабама тапшырып калдыра. Сафа бабам үзе дә, уллары Низаметдин белән Ризатдин бабамнарның кулларында гармуннар сандугачтай сайраган, күңелләрне айкаган. Үзеннән соң дәвамчы калдыра алуына сөенгәндер Сафа бабам. Кайсы гына туганымны алсам да, барысы да диярлек оста гармунчылар булганнар. Димәк, Рифат абыем да, мин дә – гармунчылар нәселеннән. Бабамнарның шөгыль- кәсепләрен, әдәп-әхлагын, әтиемнең һөнәрен дәвам итүем белән мин горурланам. Бүгенге чыгышымны да шулай дип атадым. Әтием Марат 7 яшендә гармунда уйнарга өйрәнгән, музыка мәктәбендә, хәрби училищеда укыган, армиядә Чита шәһәрендә хезмәт иткән, бер чара да аның катнашыннан башка узмаган. Мин үзем дә, энем Бәхтияр дә төрле музыка коралларында уйныйбыз, Яшел Үзәннең музыка мәктәбендә бик күп төрле чараларда катнашабыз, бигрәк тә татар гармуннарына багышланган чараларда яратып, рәхәтләнеп, татар халкының борынгы көйләрен уйныйбыз.

Низаметдин бабамның туганы Ризатдин бабамның уллары Гадел, Гомәр, Гали абыйлар баянда да, тальянда да күзләрен йомып уйный ала алар. Районда, республикада узган бәйгеләрдә, авыл бәйрәмнәренең үзәгендә кайный алар. Гали абыйның улы Рифат Гали улы Сәлахов 1987 елның 8 июлендә Татарстанның Буа районы Яңа Чәчкап авылында эшче һәм укытучы гаиләсендә дөньяга килә. Үз авылларында урта мәктәпне тәмамлый һәм 2004-2009 нчы елларда Казан дәүләт университетының юридик факультетында белем ала. Рифат Сәлах тел-әдәбият белән мәктәптә укыганда ук кызыксына башлый. Беренче шигырен бишенче сыйныфта яза. Унынчы-унберенче сыйныфларда белем алганда, район газетасында шигырьләре басыла башлый. Тел һәм әдәбият буенча олимпиадаларда катнаша. Ул 2004 елдан актив иҗат итә башлый. Казан дәүләт университетының «Әллүки» әдәби-иҗат берләшмәсендә чыныгу ала. 2007-2009 нчы елларда әлеге берләшмәнең студентлар ягыннан җитәкчесе була. Студент чагында Казан дәүләт университетының татар студентлары газетасы «Тәрәзә»не чыгаруда катнаша. 2006-2009 нчы елларда әлеге газетаның баш мөхәррире урынбасары булып эшли. Татарстан Республикасы Яшьләр, спорт һәм туризм министрлыгының «Идел» яшьләр үзәге оештырган «Иделем акчарлагы — 2005» конкурсында шигърият буенча беренче

урынга, «Иделем акчарлагы — 2006»да «Гран-прига», Казан дәүләт университеты үткәргән Идел-Урал төбәге студентларының иҗат бәйгесе «Шигъри Сабантуй — 2006» — икенче, «Шигъри Сабантуй — 2008»дә беренче дәрәҗәдәге дипломга лаек була. Шигырьләре матбугатта даими басыла, «Безнең гәҗит», «Мәдәни җомга», «Татарстан яшьләре» газеталарында мәкаләләре дөнья күрә.

Татар шагыйре Рифат Сәлах та әтиләре кебек оста гармунчы. Рифат Сәлахны төрле әдәби кичәләрдә дә күрергә мөмкин, гармунына кушылып моңлы тавышы белән тамашачыларны әсир итә белә ул. Халкыбызның гармун көйләрен яңартып торуы һәм аны онытмавы күңелләргә җылылык, горурлык өсти. "Кечкенәдән гармунда уйнарга яратам. Әтидән күреп, үзлегемнән өйрәнгән идем. Инде бик күп еллар кулдан төшергәнем юк. Сабантуйларда уйнамыйча калсам, бер ел кәефем булмый"- дип искә төшерә ул.

**Йомгаклау**

Гармунчы бабайларым, туганнарым, бигрәк тә Рифат абыем турында күпме кызыклы мәгълүмат тупладым. Нәселебездән шундый күренекле кешеләр,гармунчылар чыкканга, мин бик горурланам. Мин энем Бәхтияр белән – нәселебезне дәвам итүчеләр. Нәселемнең корыган, черегән агачы булырга теләмибез без. Безнең өчен хурланырга, йөз кызартырга туры килмәсен. Гаилә шәҗәрәсен алып бару, нәселнең абруе турында кайгырту- безнең төп бурычыбыз.

Кадерле дусларым, сезгә әйтер сүзем бар. Без – үткәнне һәм киләчәкне тоташтырып торучы чылбыр. Әгәр бабаларыбызның үткәне, тарихы, гореф-гадәтләре, йолалары, шөгыль- кәсепләре белән кызыксынмасак, чылбыр өзелер. Моңа һич юл куярга ярамый. Эзләник, һичшиксез, әти-әниләребез, әби-бабайларыбыз да, туганнарыбыз да бик теләп безгә ярдәм итерләр. Мин дә киләчәктә бу эзләнүләрем нәсел шәҗәрәм булыр дип ышанам калам.

**Кулланылган әдәбият исемлеге**

1.Әхметҗанов М.И. Татар шәҗәрәләре.- Казан: Татар китап нәшрияты, 1995, 128 бит.

2. Рәхинә әбием истәлекләре.

3. Сугыш ветераны Нурулла абыебыз төзегән альбомнар.

5.Фәхертдин Р.Нәсел ыруыбыз вә кыскача тарихыбыз.-Казан, 2008.

*Автор: Сабирҗанова Язилә Рәис кызы, МБГБУ «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Аксу урта гомуми белем мәктәбе" , 2 нче сыйныф*
*Фәнни җитәкче: Сабирҗанова Гөлнара Фоат кызы*

## РИФАТ СӘЛАХ ИҖАТЫНДА ТУГАН ЯКНЫҢ ЧАГЫЛЫШЫ

Эчтәлек

1.Кереш
2.Төп өлеш
Рифат Сәлахның тормыш юлы.
Рифат Сәлах иҗатында туган якның чагылышы
3. Йомгаклау
4. Кулланылган әдәбият
5. Кушымта

**Кереш**

Безнең районыбыз талантлы шәхесләргә бик бай. Кемнәр генә юк алар арасында? Әдәбият һәм сәнгатьнең, фән һәм мәдәниятнең, хезмәт һәм батырлыкның кайсы гына тармаган алсаң да, тарихта үз исемен зур хәрефләр белән язып калдырган шәхеслеребез күп безнең. Татар халкының күренекле шәхесләрен дөньяның төрле почмакларында очратырга мөмкин. Шуларның берсе - Рифат Сәлах.

Рифат Сәлах - алгы сафта баручы яңа, яшь буын шагыйрьләрнең берсе. Аның шигырьләрендә мәхәббәт тә, тирән фәлсәфә дә, милләтебез язмышы өчен борчылу да бар. Бүгенге көн яңа татар әдәбияты күгендә Рифат Сәлах дигән яшь шагыйрьнең үз йолдызы кабынды.

Шагыйрьнең бер генә шигыре дә укучыны битараф калдырмый, күңел кылларын тибрәндерә, күңелне дулкынландыра, кыбырсыта. Алай гына да түгел, бер дулкын булып үзенә алып кереп китә. Шагыйрь төрле темаларны күтәрә.

Мин бүген үзебезнең якташ шагыйребез - Рифат Сәлах иҗатында туган як темасының чагылышын ачыкларга телим.

Мин эзләнү эшемнең төп максаты:

1. Рифат Сәлах иҗатында туган якларына карата изге , соклану, сагыну , ярату хисләрен ачыклау.

2. Шушы илаһи хисләрне йөрәкләреннән кайнап чыккан шигъри юллары белән исбатларга тырышу.

Максатка ирешү өчен без түбәндәгеләрне башкардык:

- Рифат Сәлахның китапханәдә булган китапларын барлап чыктык.
- Туган як турында язган шигырьләрен укыдык.

Газет, журнал, өстәмә әдәбият һәм интернет чыганаклар аша табылган материалларны тикшердек.

Темабызның өйрәнү объекты – Рифат Сәлах шагыйрь

Өйрәнү предметы – Рифат Сәлахның туган як турында язган шигырьләре

Әйтелгән максаттан чыгып, түбәндәге бурычлар куелды:

-Рифат Сәлах иҗатын өйрәнүгә кызыксыну уяту;

- Рифат Сәлах шигырьләрендәге тел үзенчәлегеннән кабатлауларны ачыклау;

- Тупланган материалны киң катлау укучыларына тәкъдим итү.

Эзләнү эшем кереш, төп өлеш һәм йомгактан тора. Төп өлештә Рифат Сәлахның кайбер шигырьләреннән мисаллар китерелде

Минемчә, өйрәнелә торган бу тема мәктәп кысалары өчен бик актуаль мәсьәлә. Чөнки, кешедә туган якка мәхәббәт тәрбияләүдә әдәбиятның –сәнгатьнең әһәмиятле роленә басым ясала.

**Төп өлеш**

**Рифат Сәлахның тормыш юлы.**

Туган ягым, туган авылым! Һәркем үз ягын матур итеп, аны үз мәхәббәте белән баетып, шигъри бизәкләргә төреп, ямьләндереп күрә. Аның гүзәллегенә, ке-шеләренә соклана, алар белән хаклы рәвештә горурлана. Шуңа да Туган як җырларга күчкән, аның турында язучылар күләмле әсәрләр иҗат иткәннәр.

Һәрбер иҗат кешесе,үзенең иҗатында туган якның табигатен, дөньядагы иң изге, иң матур, күңелгә үтеп керә торган саф сүзләр белән тасвирлый. Кеше тормышында әти-әни беренче урынны алып торган кебек, туган туфрак, туган җир икенче урынны алып тора. Аны башка берни белән дә алыштырып булмый. Ул газиз, бердәнбер! Үзенең тормышын иҗатка багышлаган әдипләребез иҗатларында туган якка булган мөнәсәбәт ачык чагыла. Үзләренең туган булган бөтен назын, рәхмәтен алар ак кәгазъ битләренә терккәгәннәр, китап итеп бастырганнар. Күңелдән ташкып чыккан сүзләр кеше күңелендә генә калмыйча тышка бәреп чыгып, башкаларга барып җитәргә һәм күңелләрдә онытылмаслык хисләр уятырга тиеш. Шул вакытта гына каләм осталарының иҗат җимешләре яхшы бәяләнә.

Безнең якташ шагыйрьләребез үзләренең иҗатында туган як темасын ачык чагылдырганнар. Хәзерге вакытта яшәп иҗат итүче, кешеләрне үзләренең иҗат җимешләре белән сөендерүче якташыбыз да бар. Ул - Рифат Сәлах.

Рифат Сәлах (Рифат Гали улы Сәлахов) 1987 елның 8 июлендә Татарстан-ның Буа районы Яңа Чәчкап авылында эшче һәм укытучы гаиләсендә дөньяга килә. Үз авылларында урта мәктәпне тәмамлый һәм 2004–2009 елларда Казан дәүләт университетының юридик факультетында белем ала.

Р.Сәлах тел - әдәбият белән мәктәптә укыганда ук кызыксына башлый. Беренче шигырен бишенче сыйныфта яза. Унынчы-унберенче сыйныфларда белем алганда, район газетасында шигырьләре басыла башлый. Тел һәм әдәбият буенча олимпиадаларда катнаша.

Ул 2004 елдан актив иҗат итә башлый. Казан дәүләт университетының «Әллүки» әдәби-

иҗат берләшмәсендә чыныгу ала. 2007–2009 елларда әлеге берләшмәнең студентлар ягыннан җитәкчесе була. Студент чагында Казан дәүләт университетының татар студентлары газетасы «Тәрәзә»не чыгаруда катнаша. 2006–2009 елларда әлеге газетаның баш мөхәррире урынбасары булып эшли. Татарстан Республикасы Яшьләр, спорт һәм туризм министрлыгының «Идел» яшьләр үзәге оештырган «Иделем акчарлагы – 2005» конкурсында шигърият буенча беренче урынга, «Иделем акчарлагы – 2006»да «Гран-прига», Казан дәүләт университеты үткәргән Идел-Урал төбәге студентларының иҗат бәйгесе «Шигъри Сабантуй – 2006» – икенче, «Шигъри Сабантуй – 2008»дә беренче дәрәҗәдәге дипломга лаек була. Шигырьләре матбугатта даими басыла, «Безнең гәҗит», «Мәдәни җомга», «Татарстан яшьләре» газеталарында мәкаләләре дөнья күрә.
Р.Сәлах – 2008 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

**Рифат Сәлах иҗатында туган якның чагылышы**

Рифат Сәлах “Күңел бөртекләре”(2007) ,“Яшел ай” (2009) ,“Ташта үскән гөлләр” (2012) ,“Кызыл юл” (2015) исемле шигырь китаплары авторы. Аның иҗатында үзенә генә хас булган сыйфатлар бик күп. Мәсәлән: аңа риториклык хас. Ул табигатьне бөтен нечкәлеге белән аңлый, аның телен белә, иген кырлары, инеш-чишмәләре белән эчкерсез сөйләшә, алар белән сер бүлешә. Шулай ук, татар милләтенең катлаулы язмышы, бүгенге проблемалары аның җанын, рухын нык борчый. Аның хисләре каләм очыннан кисәтү авазы булып тамалар.

Ераклардан ничек итеп
Сәламнәрне юллыйсы?
Сагындыра,үзенә тарта
Туган туфрак җылысы.
Күңел тулы моңнар гына,
Җырлыйсы да җырлыйсы!
Читләргә киткәч тоела
Туган туфрак җылысы.
(“Туган туфрак җылысы”)

Бу шигъри юллар белән ул үзенең сагынуын басарга телидер сыман.Чөнки кеше кайда гына яшәмәсен, барыбер үзенең туган туфрагын тоеп яши. Аның матурлыгын бервакытта да онытмый.

Кайда калдың, и газиз җир,
И сөйгән туган ягым?!
Синдә чакта былбылның да
Сайравын тыңламадым.

Күрмәдем гөлләрнең ямен,
Күкләрнең яктылыгын.
Ишетмәдем урман шавын
Һәм туган якның моңын.
(“И газиз туган җирем!”)

Туган җир табигате - шагыйрьнең иң зур байлыгы.Туган җир-шагыйрь җанының тормыштагы иң ныклы таянычы.Туган туфрак табигатеннән ераклашу, шагыйрь өчен иң каты җәза. Киң, яшел урман шаулавын ,былбыл сайрауларын сагына. Әлбәттә, кеше балачакта бу матурлыкларны күрми, ишетми. Ничек бар, шулай кабул итә. Ә яшь барган саен, болар барысы да күңелгә якынырак тоела бара. Бигрәк тә кеше туган җиреннән, туган туфрагыннан ерак булса...

И туган ил,илем,илкәй генәм!
Иркен синең басу кырларың.
Кочагымда сине иркәләргә
Кулны сузам...Җитми кулларым.
И илкәем!
Атың ничек синең?
Мөһим түгел миңа ансы да.

Алсу таңнар, алсу гөлчәчәкләр,
Алсу өмет – синдә барсы да.
И туган ил!
Илем,илкәем.
Югыйсә бу шундый изге сүз.
Туган илгә дәшәр өчен, нигә
Башка төрле сүзләр эзлисез?!
(“Илкәем”)

Бу шигырендә дә шагыйрь туган илен сагынуын сурәтли. Илкәендәге иркен басу – кырлар, алсу таңнар, алсу гөлчәчәкләр белән горурлана. Һәм озаграк торган саен ул боларның барысын да ешрак искә ала.

Туган авылым,Яңа Чәчкап
Гөрләп торасың микән?
Чит җирләргә чыгып киткәч,
Сагындырасың икән.
Бик сагындым, туган авылым,
Чәчәкле үзәнеңне.
Синең якты урамнарың
Күрмичә түзәрменме?
Кайтып бер әйләним әле
Елгаларың, суларың.
Нарат урманына кереп,
Саф һаваңны сулармын.
Бик сагындым, туган авылым,
Ямьле Лашчы буйларын.
Еракка китеп барсам да,
Һәрчак синдә уйларым.
Уңган – булган халкың белән
Җиһанга нур чәч тагын!
Син һәрвакыт күңелләрдә,-
Җырга күчтең ,Чәчкабым.
Җырларымда яшисең син,
Исемең дә чәчә моң.
Еракларга китсәм дә мин,
Бер кайтырмын, Чәчкабым.
(“Яңа Чәчкап”)

Сиңа кайттым әле, сагынылган.
Болыныңа чыктым кичкырын.
Мин яратам сине,туган ягым,
Бик яратам, диеп кычкырдым.

Кемдер,бәлки ишеткәндер мине...
Миңа җитә,үзең ишетсәң.
Туган ягым, мин тирбәлеп ятам
Күккә элгән яшел бишектә.
Егылсам бер торырмын әле,
Бишегеңнән генә төшермә!
...Мин җиһанның күккә элә торган
Йолдызлары туар төшендә!
(“Туган авылыма”)

Бу шигырьләрен Рифат Сәлах үзенең туган авылы Яңа Чәчкапка багышлый. Шунда балачак еллары сизелми дә үтеп китә. Туган авылының чишмә-инешләренең челтерәп аккан суының тәмен шагыйрь һич онытмый.

**Йомгаклау**

Туган ягыбызның гүзәл табигате кешегә яшәү өчен көч, дәрт бирсә, шагыйрьләребезгә илһам, иҗатларына ямь өсти.

Рифат Сәлах иҗатын колачлап, чорнап алган тема-туган җирләренә дан җырлау.Алар өчен туган җирендәге һәр кечкенә тереклек иясе үз һәм якын, туган яктан килгән яңгыр алар өчен шифа чыганагы, болын-урманнары тынычлану, ял итү, мәшәкатьләрдән арыну урыны. Шагыйребез туган ягы өчен борчылып, андагы һәр үзгәрешне тоеп, үз йөрәге аша кичереп яши.

Шигырьләреннән күренгәнчә, якташым Рифат Сәлах туган якны сагынып, бигрәк тә табигать күренешләренә мөрәҗәгать итеп, шулар аша кеше күңеле, кичерешләре белән бәйле хәл- вакыйгаларны сурәтләргә, аларга олы мәгънә салыргаярата.

Күңелебездә рухи төшенкелек вакытында Рифат Сәлахның шигырьләр җыентыкларын кулыгызга алсагыз , һәм уйландыра, моңландыра, сөендерә, көлдерә торган әсәрләр сездә горурлану хисләре уятыр. Шуның өчен дә аңарга иҗаты өчен рәхмәт әйтәсе килә.

Без укучылар, аның шигырьләрен укып балачакның, туган якның матурлыгын күрергә өйрәнәбез. Шагыйрь дә үз халкының балаларын, киләчәген зирәк, акыллы, уңган, көчле, кыю, тапкыр, батыр итеп күрергә тели.

Мин үземә шундый нәтиҗәләр ясадым:

1. Рифат Сәлахның иҗат мирасы бай һәм күпкырлы.
2. Аның иҗаты бик югары бәяләнә.
3. Рифат Сәлах иҗаты мәктәп дәреслекләрендә дә урын алсын иде.

Татарстанга күренекле җырчылар, язучылар, шагыйрьләр, сәнгать, мәдәният, дәүләт эшлеклеләре, Хезмәт алдынгылары биргән Буа ягы бүген дә тулы канлы тормыш белән яши. Безнең халык һәрчак белемгә, яктылыкка омтылган, киләчәк буынны да шул рухта тәрбияләгән. Тирә-ягыбызда милли рухлы кешеләр булганда, уңдырышлы Буа ягыннан әле байтак талант ияләре чыгар.

Хезмәтемне төгәлләп шуны әйтәсем килә: туган ягының гүзәл табигате кешегә яшәү өчен көч, дәрт бирсә, шагыйрьләребезгә илһам, иҗатларына ямь өсти.

Якташымның илһамы туктаусыз ташып, уйлары йолдызлы күкләргә ашып торсын! Ни д дисәк тә , татар шигъриятенең киләчәге Рифат Сәлах кебек шәп егетләр кулында!

**Кулланылган әдәбият**

1. Сәлах Р.Г. Күңел бөртекләре: - Казан :Татарстан китап нәшрияты , 2007
2. Сәлах Р.Г. Яшел ай : - Казан :Татарстан китап нәшрияты , 2009
3. Сәлах Р.Г. ташта үскән гөлләр : - Казан :Татарстан китап нәшрияты , 2012
4.Сәлах Р.Г. – Wikipedia материаллары.

*Автор: Рахматуллин Илназ Дамир улы, Татарстан Республикасы, Зеленодол муниципаль _районы Норлат урта гомуми белем мәктәбе” бюджет муниципаль белем бирү учреждениесе, 6 Б сыйныфы*

*Фәнни җитәкче: Гыймадиева Дания Малик кызы*

## Мулла Иленең яшь шагыйрәсе Рәмилә Майорова иҗаты

Минем туган ягым –гүзәл табигатьле Яшел Үзән районы. Безнең якларда элек-электән укымышлы һәм тырыш кешеләр яшәгән. Әби-бабайларыбыз уңдырышлы җирләрдә иген иккәннәр, мул уңышка сөенгәннәр.



Биредә яшәүче халык бүген дә матди һәм рухи байлыклар тудыра, күкрәтеп икмәк үстерә, яланны тутырып мал үрчетә, һөнәрчелек белән шөгыльләнә. Алдагы буыннарга затлы мирас калдырырлык итеп яши халкым, төрле һөнәр ияләрен мулдан бирә. Шул мирасны дәвам итүчеләр дә бар туган ягымда. Мулла Иле авылында туган чибәр, самими, шигъри җанлы кыз- Майорова Рәмиләне мин шулар рәтенә кертер идем.

**Бу эзләнү- тикшеренү эшемнең максаты:** аның тормыш һәм иҗат юлын өйрәнү.



Майорова Рәмилә Фәһим кызы, 1988 нче елның 21 нче августында Яшел Үзән районы Мулла Иле авылында туган.

Ул башта балалар бакчасында тәрбияләнгән. 1994 нче елда Мулла Иле урта мәктәбенең 1 нче сыйныфына укырга кабул ителгән. Иң беренче шигырьне 3 нче сыйныфта укыганда язган, әдәбият түгәрәгенә йөреп Иҗаты “Яшел Үзән”, “Көмеш кыңгырау”,“Сабантуй” газеталарында дөнья күргән. Казан Федераль Университетына укырга керә, ТНВ каналында эшли.



Казан Федераль университетын тәмамлагач тормышка чыга, хәзерге вакытта гаиләсе белән Ульяновск шәһәрендә яши.

Шигьри җыентыклар, “Өмет бар туар көннәремдә” дигән китаплар чыгарган.Туган як, туган мәктәп, авылдашлар, табигать темалары Рәмилә апа иҗатында төп урын алып тора.

Табигать турында, уңган Мулла Иле халкы турында Рәмилә апа бер- берсен кабатламыйча нинди генә эчтәлекле шигырьләр язмаган! Шигырьләрен укыган саен укыйсы килә! Искиткеч моңлы, сагышлы, һәрбер балага аңлаешлы аның шигырьләре. Бөек шагыйребез Габдулла Тукайга багышлап та үзенең

“Арабыздан син, Тукай” шигырен иҗат иткән. Бүген сезнең игътибарыгызга “Арабызда син, Тукай” шигырен тәкъдим итәм.

Бишектә чакта әнием
Әллүкөен көйләгән,
Ә аннан соң, үсә төшкәч,
Әкиятләрен сөйләгән.

Кечкенәдән, сабый чактан
“Шүрәлеләрең” белән
Яши алар күңелемдә
“Су аналарың” белән...

(“Арабызда син, Тукай”)

Безнең җирлекне яратып, куакланып таралып үсүче, көзләрдә мул уңыш биреп, кызыл комач кебек балкып утыручы балан, күптөрле шифага, дәвалау үзлекләренә ия булган кебек, Рәмилә апаның шигырьләрендә дә төрле төсмерләргә кереп сокландыра.

Минем әле шундый чагым:
Ут булып янам кебек,
Кыраулардан соң күз башында
Балланган балан кебек.

Елата да, җырлата да, канатландыра да аның шигырьләре.

Аның шигырьләрендә яшьләргә хас мәхәббәт, кешелеклелек турында уйланулар белән сугарылган.

Нигә кирәк болай дөрләп яну
Мең хисләрдән көеп, газапланып?
Егыласын беләм, әмма барыбер
Очыйм әле, очыйм –канатланып!

Озак еллар буе Мулла Иле мәктәбе директоры булып эшләгән Равил абый Сәйфетдиновка да багышлап, “Юк, сез бездән әле китмәгез” шигырен язган.

Авылымда яшәп иҗат итүче җирле яшь шагыйрьләребез - укучыларның яраткан шагыйрьләре, күпкырлы талант ияләре. Мин аларның талантлары алдында башымны иям. Елата да, юата да, көлдерә дә, шатландыра да, уйландыра да, сагышландыра да аларның иҗат җимешләре.

Туган төбәкләребездә моңлы күңелле кешеләр булганда, бөек халкыбыз да, аның матур, бай теле дә яшәр дип ышанам. Искиткеч моңлы шигырьләрең өчен рәхмәт сиңа, Мулла Иле тургае!

*Бигрәк матур туган авылым,*
*Язгы сулар ярсып акканда,*
*Хуш исләрен бөркеп, бар җиһанга*
*Алмагачлар чәчәк атканда...*

*Автор: Гайфуллин Әмир Рәмил улы, Яшел Үзән муниципаль районы 1нче номерлы Лицей 5А сыйныф*
*Фәнни җитәкче: Абдуллина Фәния Зөфәр кызы*

## Тормышны яратучы шагыйрә

Эчтәлек

1.Кереш
2.Шагыйрәнең тормыш юлы һәм иҗаты турында.
3.Йомгаклау
5.Кулланылган әдәбият.

**Кереш**

Әлеге фәнни-эзләнү эшен язарга алынганда, мин үз алдыма түбәндәге максатларны куйдым:

Шагыйрә иҗатына төпле күзәтү ясау, аның әдәбиятка килү шартларын ачыклау, иҗат үзенчәлекләрен билгеләү.

Максатыма ирешү өчен мин Л.Сәлахетдинованың шигырь җыентыкларын җентекләп карап чыктым.

Сайлап алган теманың актуальлеге шунда дип саныйм: шагыйрьнең тормышын һәм иҗатын тирәнтен өйрәнү, шигырьләрен кайта-кайта уку, аларны пропагандалау бик әһәмиятле. Шигърият ул - беркайчан да югалмый һәм искерми торган зур хәзинә, буыннан буынга тапшырыла торган олы мирас.

Фәнни-эзләнү эшенең өйрәнү объекты итеп, Лилия Сәлахетдинова үзе, ә өйрәнү предметы итеп, шагыйрәнең җырга әйләнгән шигырьләре.

Бүген Йолдыз Миңнуллина, Рүзәл Мөхәммәтшин, Лилия Гыйбадуллина, Эльвира Һадиева, Рифат Сәлаховларны шигърияттә үз юлларын тапкан авторлар дияргә була. Чын шагыйрь булыр өчен аларда табигый талант та, амбиция дә, гыйсьянчылык рухы да бар. Әлеге агымга Булат Ибраһимов, Айдар Җамал, Рүзәл Әхмәдиев кебек яшьләр дә килеп кушыла. «Яшьлек – шигърият, картлык – проза», дисәләр дә, Рөстәм Галиуллин, Айдар Зәкиев кебек авторларыбыз проза жанрында үз урыннарын табып, татар прозасының киләчәге өметле дигән ышаныч тудырырга өлгерделәр. «18яшьлек язучылары булмаган әдәбиятның киләчәге шикле», – дигән бер акыл иясе. Минемчә, татар әдәбиятының киләчәге бар һәм ул ышанычлы кулларда.

**Шагыйрәнең тормыш юлы һәм иҗаты турында.**

Лилия Сәлахетдинова Буа районы Күл-Черкен авылында бишенче кыз бала булып гади колхозчылар гаиләсендә 1986 елның 22 ноябрендә туган. Язмыштыр инде, дүрт апасы сәламәт туса да, ул “бәллүр кеше” (несовершенный остеогенез) диагнозы белән дөньяга килгән. Тугачтын ук Казанга күренергә алып баргач, республиканың клиник хастаханәсе табиблары: “Бу бала озак яшәмәс, яшәсә дә башы эшләмәс, күзе күрмәс, калдырып кына китегез”, дип күндерергә тырышуларына карамастан, әти-әнисе: “Язмышка ни язса шул булыр, дүрт бала янына бишенчесе сыяр, тере баланы ничек итеп калдырып китәргә кирәк”, дип алып кайтып китәләр. Әти-әнисенә бу адымнары өчен ул мәңге рәхмәтле.

Кечкенә чакта сөякләре сынып дөрес ялганмыйча кабат-кабат сынулары сәбәпле үз формаларын югалталар. Гәүдәсе үсмәгәч, йөри алмас була. Бу җитешсезлекләр аркасында кайбер мөмкинлекләр чикләнсә дә, тулаем алганда диагнозы аңа яшәргә комачауламый. Мәктәптә алырга тиешле белемне өйдә ала, укытучылар килеп укыталар. Үзлегеннән компьютер кулланырга өйрәнә. Югары белем алырга да кызыга ләкин, кире уйлый. Читтән торып укып чыкса да, авылда яшәп транспортсыз кая да булса эшләп йөрү мөмкин хәл түгел шул.

Тормыштан тәм табып яшәргә – кешеләрнең миңа ышанулары ярдәм итә ди ул үзе турында. Әти-әнисенең, туганнарының оялмавы ул гадәти, ә менә тирә-яктагыларның үзләре белән тиң күрүләре башка булуын да азсызыклый. Бу әлбәттә яшәргә теләк уята, көч бирә ди ул. Ул табигатькә чыгарга, дуслар белән күңел ачарга ярата. Җай чыкса, концертларга, бәйрәмнәргә бара. Шулай ук әлбәттә яшәргә аңа иҗаты булыша. Ак бит – ул минем чын сердәшчем ди ул иҗаты турында.

Шигырьләр иҗат итә башлавына 16 ел . Композитор Оскар Усманов белән бергәләп җырлар яза башлый. Ул көй язып кына калмый, җырчыларга тәгъдим итеп, аларны яздырып – автор буларак аның барлыгын кешеләргә күрсәтә. Бу аның өчен бик мөһим, чөнки өйдә утырып яки елга берничә мәртәбә кая да булса барып кына кемгәдер үз иҗатыңны тәкъдим итү мөмкин түгел. Оскар Усмановка ул бик рәхмәтле.Мәсәлән барыбызга да таныш Лилия Хәмитова репертуарында бар ("Ялгышларга юл куйма"), шулай ук Артур Бәдретдинов ("Танышулар"), яшь җырчы Гөлназ Шакирова ("Мәхәббәтсез булмый дөньяда"), Энҗе Шәймурзина ("Мәхәббәт") башкара. Гөлназ Шакировага аерым тукталып үтсәк , “Мәхәббәтсез булмый дөньяда” җырына клип та төшертергә өлгерә. Һәм тагын барлык чыгарылыш укучыларына һәм шулай ук мәктәпне инде күптән бетергән, гел сагынып искә алучылар өчен композитор Айнур Шәрапов исемле егет ярдәмендә яңа җыр туа. Ул “Мәктәп еллары” дип атала.

Шулай ук, әлегә профессиональ булмаган автор-башкаручы егетләр белән төрле стильдә эксперементлар ясый ул. Мәсәлән, рэп стиленә кагылсак, Башкортстан егете Алмаз Борһанов белән “Рәнжетмәгез ятимнәрне”, Түбән Кама егете Илсур Нуретдинов белән “Үзгәрү безгә кулай” дигән җыр яздыралар. Аларны үсмерләр дә, өлкән кешеләр дә яхшы кабул итә. Шулай ук Төмән егете Денис Сагадиев интернеттан текстны алып аңа сюрприз ясый, “Сине кочар” дигән трек яздыра. Димәк, башка шәһәрләр дә татарча тыңлыйлар һәм җырларга әзер яшьләр бар – бу куандыра. Игорь Смирнов атлы егет гитара белән райондагы бер мәктәп чыгарылыш сыйныфы өчен “Вакыт бигрәк тиз үтә” дигән җыр иҗат итә.

Идел пресс нәшриятендә, 520данә тираж белән Лилия Сәлахетдинованың “Күңелем көндәлеге” диеп аталган җыентыгы дөнья күрә. Китапта шигырьләре белән бергә, кайбер җыр текстлары да урын алган.

Авторның өченче”Ярдәм” дип исемләнгән китабы “Зур Казан” басмаханәсендә Казан мэры Илсур Метшинның ярдәмендә нәшер ителә. Лилия Сәлахетдинованың шигырьләре тормыш, мәхәббәт һәм мәңгелек кыйммәтләр хакында. Соңгы вакытларда рухи тематика да Лилиянең иҗатына үтеп керә. Китапның кереш өлешендә шагыйрәгә Татарстанның халык шагыйре, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Разил Вәлиев үзенең киңәшләрен, үгет-нәсыйхәтләрен биргән.

Өченче эшлекле хатын-кызлар форумында Лилия Сәлахетдинова танылган шагыйрә генә түгел, ул шулай ук “Ярдәм” тернәкләндерү үзәгенең актив волонтеры да. Гомерен инвалид арбасында үткәрәенә карамастан, ул социаль яктан актив тормыш рәвеше алып бара.

“Ярдәм” Милли ислами хәйрия фонды хезмәткәрләре шагыйрә Лилия Сәлахетдиновага электр көчергечле сиртмәле арба бүләк итә.

Лилия Сәлахетдинованың: “Иҗатымда минем тормышым” (“2012), “Күңелем көндәлеге” (2013), “Ярдәм” (2015), 13тән артык җыр авторы. Җырларын Лилия Хәмитова, Рәмилә-Рәзилә Батыровалар, Миләүшә Сәгъдуллина, Булат Җиһаншин һ.б күп танылган җырчылар башкара.

Аның үзе турында сөйләгән сүзләре мине таң калдыра.Менә ничек сөйли ул үзенең иҗатка килүен. “Мәсәлән, мин шигырьләр яза башлаган вакытта үзем өчен генә яза идем һәм шулай әкрен генә әти-әнигә әйтмичә шигырьләремне матбугатка җибәрә башладым. Алар басыла, кеше күрә башлады. Әлбәттә, әти-әни дә күрә башлады инде аны. Әкрен генә минем беренче китабымны чыгару идеясы туды. Мин социаль яклау идарәсенә мөрәҗәгать иттем һәм районыбызның администрациясе ярдәме белән ул чыкты. Бер әйберне күргәч, икенче әйбер кирәк. Ул йомшак тышлы гына иде. Аның шатлыгы бик зур иде, әлбәттә. Бераз гына вакыт үтте дә, минем каты тышлыны чыгарасы килә башлады. Анда да миңа ярдәм иттеләр. 500 данә тираж белән без аны чыгардык. Өченче китабым “Ярдәм” типографиясендә, Казанда чыкты. Анысы 1000 тираж белән. Планнар юк түгел. Уйлыйм тагын аудиокитаплар чыгарырга. Аудиокитаплар бик кирәк, чөнки безнең кешеләребез күп һәм аларның да үзләренең тыңлап карыйсылары килә. Ярый, без аларга укып күрсәтәбез, әмма аларда бит ул китаплар калмый. Аудиокитап ясасаң, ул аны кайчан тели, шунда кабызып тыңлый ала.”

**Йомгаклау.**

Поэзия күгендә һәр чорның үз йолдызлары кабынып тора. Аларның кайберләре, халык күңелен биләп, мәңге сүнми торган нурлы йолдызга әвереләләр. Әнә шундый сүнми торган йолдызларның берсе булып Лилия Сәлахетдинова да татар әдәбияты күгендә үзенә урын алыр.

Бәхет өчен күп кирәкми. Шагыйрә өчен бәхет – ул шушы эшендә исән-сау эшләү, иҗатын дәвам итүе, тагын китаплар чыгару. Бу тормышта үзеңне эзләп табарга кирәк, чөнки гомер – ул шушы бүгенге көн белән бармый. Бер көн әти-әниләрсез, туганнарсыз да калырга мөмкинбез. Үзеңне барыбер шушы көнгә әзерләргә кирәк. Үзеңне эзләп тапсаң, үзеңнең юлыңнан барсаң, сине кеше дә хөрмәт итә. Син үзеңне яратсаң, сине кеше дә ярата ди ул үзе турында. **Үзеңне эзләп табу өчен ди ул,** син нәрсәгәдер хәвәс икән, сине чынлап нәрсәдер кызыксындыра икән, син бу эшне эшләргә өйрәнергә тиеш,

шулай ук үзеңә мин моны белергә тиеш дип максат куярга тиеш һәм нинди дә булса яктан сиңа мөмкинлекләр ачыла.

Ул үзенең шагыйрь, язучы , драматург Фәнис Яруллин иҗатын аеруча яратып кабул итүен азсызыклый. Аның язмышы, аның шушы сынаулар аша үтүе һәм аның гаиләсе, пар канаты Нурсөя апаның аңа терәк булып, карап яшәве. Фәнис Яруллинның сынмаган рухы, аның ныклы терәге, аның иҗаты аны үстерә, чөнки чыннан да аның китапларын укый-укый ул үзенең дә шагыйрә буласы килүе турында сөйли.. Үзенең фикерләрен ак бит белән бүлешәсе килә аның. Ул аны бик озак вакытлар өйрәнә. Шагыйрьлек ул, әлбәттә, күңелдән чыкса да, аны дөрес итеп кешегә тапшыра белергә кирәк. Шуңа күрә Лилия Сәлахетдинова өчен Фәнис Яруллинның иҗаты бик зур роль уйный.

Бу тормышта ни булса да, түзәргә кирәк ди ул. Ни генә булса да, сөенечтән дә, мәсәлән, артык шатланырга да ярамый. Кайгыларга артык көенергә дә ярамый. Барысы да үтә торган әйберләр. Бу дөнья өч көнлек. Нәрсәгәдер көенеп утыру, нәрсәгәдер артык сөенү шулай ук һәр әйбер үзенең кысаларында булырга тиеш. Үз-үзеңне вакытында кулга алырга кирәк дип үз киңәшләрен бирергә дә онытмый ул.Һәм әлбәттә мин аның белән килешәм, бик дөрес һәм гыйбрәтле сүзләр. Йомгак ясап әйткәндә, шагыйрә үз иҗатында бүгенге көннең мөһим мәсьәләләрен күтәрә. Безгә тагын шунысы да ачык: ул һәрвакыт бөтен җаны- тәне белән үзенең укучылары язмышы өчен янып яши, аның тормыш-көнкүрешен яхшырту турында кайгырта, телебез, гореф- гадәтләребезне саклау һәм үстерү өчен тырыша. Шушындый зур талантка ия булган шагыйрәбездән мин тагын да күбрәк образлар тудыруын, актив иҗат итүен, иҗатының шулай һаман үсә баруын теләп калам.Укылган шигырьләргә анализ ясап, шуны әйтәсе килә: аның шигырьләре халык, милләт, туган тел,әниләр,ярату, бәхет турында. Алар безне сафлыкка, гаделлеккә өнди; матурлыкны яратырга өйрәтә, җырлый.Лилия Сәлахетдинова - заман сулышын, табигатьнең һәр хәләтен, кеше күңеленең иң нечкә тибрәлешләрен, матурлыкны үтә сизгер тоеп, аны һич кételмәгән яктан ачып, тылсымлап иҗат итә белүче шагыйрә.Аның шигъриятендә – табигый гадилек, җан гаме, гомер аһәңе. Болар үтә дә ихласлылыктан килә. Шул ихласлылыктан күңелләр яктырып китә. Аның шигырьләрен укыганда, акыллы, тыйнак, һәрвакыт шат күңелле һәм юл куючан кеше белән сөйләшкән кебек буласың.

Татар халкы – батыр халык. Лилия Сәлахетдинова – халкыбызның батыр кызы. Аның шигырьләре, рухы сау-сәламәт. Күп кенә яшь шагыйрьләрне укысаң – зарлану да уфтану. Язмышы шигырьләрендә чагыла, язмышы бик гыйбрәтле. Шагыйрәнең офыклары тагын да киңәер дигән теләктә калабыз.Шигырьләрен укыган саен укыйсы килә! Аның шигърияте- күңелләрне сафландыра һәм рухны баета. Халыкка хезмәт итеп, киләчәк буынга тәрбия бирүдә зур эш башкаруы, сагышлы минутларда онытылып укырлык шигырьләре, искиткеч моңлы, эчтәлекле җырлары өчен бик зур рәхмәт аңа диясе килә.

**Кулланылган әдәбият.**


1. Гатина Римма “Безнең тормыш-үлчәү ул” // Идел., февраль 2017, 2-7бит.
2. Рәшит Минһаҗ “Орчык кадәрле Лилиянең яшәү дәрте тау кадәр”// Ватаным Татарстан, №10, 27.01.2015, 3бит.
3. Лилия Сәлахетдинова “Мине ничек бар, шулай кабул итүләрен телим” http://www.azatliq.org/a/24623304.html
4. “Бәхетләр сынауга түзгәнгә” ://www.tatar-islam.com/publ/bloglar/lilija_salakhutdinova/b_khetl_r_synauga_t_zg_ng/37-1-0-17373



*Автор: Зиннатуллина Алия Рустамовна, МБОУ "Средняя общеобразовательная школа №11 с углубленным изучением отдельных предметов Зеленодольского муниципального района РТ", 5А сыйныфы.*
*Фәнни җитәкче: Сибгатуллина Рафида Дамировна*

**Фидаил Мәҗитов татар шагыйре.**

Фидаил Мәҗитов татар шагыйре ,язучы,журналист,1984 елның 24 маенда Татарстанның Актаныш районы Кыркаентүбә авылында туа. Туган авылында башлангыч, Иске Кормаш авылында урта мәктәпне тәмамлый. 2001 елда Яр Чаллы дәүләт педагогия институтының филология факультетына укырга керә. 2006 елның июль аенда кызыл дипломга тәмамлый. Аспирантурада "Россия Федерациясе халыклары әдәбияты (татар әдәбияты)" белгечлеге буенча белем ала.

Фидаил Мәҗитов Чаллыда узган «Туган телем – Тукай теле», Муса Җәлилнең 100 еллыгына карата үткәрелгән «Татарстанның шигъри бәйләме», «Студентлар язы» конкурсларында, Әлмәт шәһәрендә узган С. Сөләйманова исемендәге «Тормыш, исәнме!» республикакүләм фестивалендә шигърият буенча беренче урыннарга лаек була. Әсәрләре һәм мәкаләләре «Шәһри Чаллы», «Ватаным Татарстан», «Мәдәни җомга», «Юлдаш», «Яңарыш» (Ижау), «Кызыл таң», "Башкортостан" газеталарында һәм «Казан утлары»,«Мәйдан», «Идел», «Тулпар» журналларында басыла. «Сагышлар да алтын була икән...» (2006) исемле шигырьләр һәм поэмалар җыентыгы авторы. Институтны тәмамлагач, Фидаил «Мәйдан» әдәби-нәфис, иҗтимагый журналына бүлек редакторы итеп эшкә чакырыла. "Күңел" радиосында кичке тапшырулар алып бара.. Шагыйрь, язучы, журналист Фидаил Мәҗитов яшь булуы- на карамастан, "Мәйдан" журналының баш мөхәррире булып эшли. Кыю фикерле шигырьләре бар, тарих белән кызыксына. Төбәк тарихы, татар тарихына багышланган мәкаләләре төрле газета-журналларда басыла: Ф.Мәҗитов – 2014 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

Әйе, Ф.Мәҗитов күргәнебезчә данлыклы Актаныш егете. Актанышның шифалы суын эчеп, хуш исле икмәген ашап, аның борынгы әмма мәнге яшь туфрагында аунап үскән, җиргә баскан саен туган җир җылысын йөрәкләре аша уздырган егет ул. Актанышның ургылып аккан чишмәсе һич тә саегырлык түгел, бөтен илгә, дөньяга танылган шәхесләрне тәрбияләп үстерде бит ул! Мин үзем яратып укыган шигырьләр, авторы турында тагы шуны үәйтәсем килә,

аның әсәрләре белән танышып чыккач шундый фикергә киләсең: ул туган иле, туган җиргә, үз авылына багышланган искиткеч матур шигырьләр яза. Алар: "Ак каеннар иле", "Эх сез таллар", _."Кайтып киләм" "Кыркаентүбә". "Ак каеннар иле" шигырендә ул болай яза:

**Ак каеннар иле –**
**Минем туган җирем,**
**Тургай җыры бизи күкләрне.**
**Таңнары да монда**
**Алсурак ата,**
**Сокландырып узенә күкләрне.**

Туган җиргә, туган авылга мәхәббәт яшь шагыйрьнең бөтен рухи дөньясын яктыртып тора. Фидаил Мәҗитов барыннан да элек – лирик шагыйрь, мәхәббәт турында күп яза. Аның шигырьләрендә сагыш та, моң да, тулып ташып тора. Сәнгатьлеклек ягыннан Ф.Мәҗитов шигырьләре камил эшләнгән. Араларында "Җырлап торганнары", ягъни үзләренә көй сорап торганнары да бар.

Әнә шулай илһамланып, халкыбыз язмышы өчен ңан атып, тормышның һәр мизгелен үзенең йөрәге аша үткәреп, борчылып – сызланып иҗат итә безнең яшь шагыйребез Фидаил Мәҗитов. Мин бу әсәрләрне һич шикләнмичә, поэзиябезнең җәүһәрләре дип атар идем.

*Автор: Цветкова Карина Владимир кызы, МБББУ "Макыл урта гомуми белем бирү мәктәбе", 4 сыйныф*
*Җитәкче: Гордеева Миләүшә Миннулла кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Күңел бөртекләрен күккә сибәм!**

**(Яшь шагыйрь Рифат Сәлах)**

Эчтәлек

Кереш өлеш
I .Төп өлеш
1.1.Рифат Сәлахның тормыш юлын, иҗатын өйрәнү
II. Йомгак
III.Кулланылган әдәбият исемлеге
Кушымта

**Кереш**

Татар теле укытучысы безгә бер яшь язучы яки шагыйрь иҗаты буенча проект эше әзерләргә тәкъдим иткән иде. Мин бүгенге көндә дә иҗат итүче яшь язучылар, шагыйрьләр белән танышып чыктым. Мине Рифат Сәлах иҗаты кызыксындырды. Мин, аның турында күбрәк белер өчен, мәгълүмат эзләргә керештем.

Мин бик күп китаплар укырга яратам. Аеруча татар телендә язылганнарын. Бүгенге көндә татар әдәбияты минем тормышымда зур урын алып тора. Кечкенәдән китаплар белән мине дәү әнием таныштыды, бүгенге көндә әдәбият дәресләрендә татар теленә генә хас булган, матур, эчтәлекле әсәрләр белән мин үзем танышам. Һәрбер укыган китапны минем тормышыма бер яңалык булып керә.

Минем уйлавымча,һәр кеше үзенең туган телен яхшы белергә тиеш. Минем өчен үз туган телемдә укый алу -зур бәхет. Еллар үтсә дә, бөек шагыйрьләр күтәргән темалар хәзер дә актуаль булып кала. Нинди генә шигырьне, әкиятне укысаң да, алар күңелне баета, бу гүзәл дөньяның серләрен ача. Татар әсәрләренең һәрберсен җыр белән тиңләп була. Без аларның шигырьләрен әбием белән бергә укырга яратабыз.Ә нинди күренекле шәхесләр бизи безнең әдәбиятны: Г. Тукай, М. Җәлил, А. Алиш, Ә. Еники, М. Мәһдиев, Фәнис Яруллин, Шәүкәт Галиев. Без алар белән горурланабыз бит.

Хәзерге көндә дә күп кенә яшь язучылар, шагыйрьләр үсеп килә.Аларның берсе Рифат абый Сәлахов. Миңа бигрәк тә Рифат абый Сәлаховның шигырьләре ошый. Минем **тикшеренү эшем”Күңел бөртекләрен күккә сибәм!”** Рифат абый Сәлахов турында .

**Тикшеренү эшенең актуальлеге** –минем яшьтәшләремә, шигырьнең кеше тормышындагы ролен аңлату, раслау. Рифат Сәлахның тормышын һәм иҗат юлын ачыклау.

**Эшнең максаты**: төрле чыганаклар аша Рифат Сәлахның тормыш юлына һәм иҗат юлын ачыклау, тикшерү, материаллар җыю, өйрәнү.

**Тикшерү объекты:** язучының тормышына караган документлар, мәкаләләр, шәхси фотографияләр, әсәрләре.

**Алымнар**: Рифат Сәлах буенча булган әдәбият белән танышу, китапханәдә эшләргә өйрәнү; шәхси фотоларын җыю.

Рифат Сәлахның тормышы һәм иҗат эшчәнлеге дигән эзләнү эше кереш, төп өлеш һәм йомгактан тора. Рифат Сәлах - алгы сафта баручы яңа, яшь буын шагыйрьләрнең берсе. Аның шигырьләрендә мәхәббәт тә, тирән фәлсәфә дә, милләтебез язмышы өчен борчылу да бар. Бүгенге көн яңа татар әдәбияты күгендә Рифат Сәлах дигән яшь шагыйрьнең үз йолдызы кабынды.

**I .Төп өлеш**

**1.1.Рифат Сәлахның тормыш юлын, иҗатын өйрәнү.**

Рифат Гали улы Сәлахов (Рифат Сәлах) 1987 елның 8 июлендә Татарстанның Буа районы Яңа Чәчкап авылында дөньяга килә. Ул тел-әдәбият белән мәктәптә укыганда ук кызыксына башлый. Беренче шигырен бишенче сыйныфта яза. Унынчы-унберенче сыйныфларда белем алганда, район газетасында шигырьләре басыла башлый. Тел һәм әдәбият буенча олимпиадаларда катнаша. 2004 елда туган авылындагы урта мәктәпне алтын медальгә тәмамлый.

Рифат Сәлах студент елларында иҗат дөньясына кереп китә. Казан дәүләт университетының "Әллүки" әдәби-иҗат берләшмәсенә йөри башлаганчы ук, ул әсәрләрен район, республика матбугатында бастырып өлгерә. Мәктәп елларында төрле иҗади бәйгеләрдә катнаша. Шулай да, Рифат Сәлах иҗаты өчен "Әллүки" мөһим роль уйный. Анда ул камилләшә, каләмен чарлый. "Иделем акчарлагы" конкурсында 2005 елда шигърият буенча беренче урын, ә 2006 елда Гран-При яулый. "Шигъри Сабантуй" бәйгеләрендә 2006 елда икенче, 2008 елда беренче урынга лаек була. 2008 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. 2009 елда Казан дәүләт университетының юридик факультетын тәмамлый. "Идел" журналында, "Шәһри Казан", "Дарелфөнүн" газеталарында хезмәт куя. 2014 елда шәхси эшмәкәр - хокукчы булып эшләп ала. 2016 елдан Татарстан китап нәшриятында редактор. Балалар һәм яшүсмерләр әдәбияты бүлегендә мөхәррир.

2013 елда шагыйрьгә Кыргызстанның Бишкәк шәһәрендә үткән "Төрки шигырь фестивалендә" Төркия Язучылар берлегенең Намык Кемал исемендәге премиясе бирелә. 2015 һәм 2017 елларда ТР Язучылар берлеге аны Муса Җәлил исемендәге Республика премиясенә тәкъдим итә.

Шигырьләре матбугатта даими басыла, «Безнең гәҗит», «Мәдәни җомга», «Татарстан яшьләре» газеталарында мәкаләләре дөнья күрә.Рифат Сәлах бүгенге көндә алты китап авторы. "Күңел бөртекләре" (2007), "Яшел ай" (2009), "Ташта үскән гөлләр" (2012) шигырь китаплары һәм автор-төзүче буларак Муса Җәлил иҗатына багышланган балалар өчен "Җәлил варисларына" (2016) китаплары Татарстан китап нәшриятында басыла. Сүрәя Гайнуллина тәрҗемәләре белән татарча-русча "Кызыл юл - Алый путь" (2015) китабы "Ак бүре" нәшриятында, Азәрбайҗан шагыйрәсе Сона Вәлиеваның татарчага тәрҗемә итеп, "Аразбары" китабы "Илһам" нәшриятында дөнья күрә. Шагыйрь Рифат Сәлахның чираттагы китабында аның өр-яңа шигырьләре туплап бирелә. Алар укучыны уйландыра, гаҗәпләндерә, сискәндерә, күңелдә хисләр өермәсе уята. “Җәлил варисларына” исемле яңа китап дөнья күрде. Советлар Союзы Герое, шагыйрь, көрәшче Муса Җәлилгә багышланган китапның автор-төзүчесе – шагыйрь Рифат Сәлах.

Автор китапның Муса Җәлилнең кызы – Чулпан Җәлил белән киңәшләшеп язылганын билгеләп узды. 95 битле китап 1 мең данә тираж белән чыккан. Китапның редакторлык эшендә, шулай ук, Энҗе Хөснетдинова катнашкан.

“Җәлил варисларына” – “Наследникам Джалиля” китабы ике телдә язылган. Анда шагыйрьнең биографиясе һәм фотографияләре, шигырьләре, кульязмалары, “Моабит дәфтәре” оригиналы фотосурәте урын алган. Автор әйтүенчә, китапта Муса Җәлил истәлеге сакланган урыннар турында да мәгълүмат бар. «Казан егетләре», «Райян», «Рәхәт Лукум» төркемнәре башкарган кайбер җырлар да аның сүзләренә язылган. Дус-ишләре арасында гармун тартырга хирыс егетнең зур сәхнәләргә менмәгән, үзе көйгә салган җырлары да байтак әле. Бик талантлы бит ул.

Фәнни эзләнү эшемнең ахырына кадәр, шагыйрә нинди булырга тиеш, нәрсә соң ул шигырь? - дигән сорауларга җавап эзләдем. Җирлектәге шагыйрьләр иҗаты белән танышканнан соң, мин сорауларыма җавап таптым. Шагыйрә булу, минемчә, шагыйрь ихлас булырга тиеш. Ә шигырь, ул күңелнең бер халәте. Тормышта без шатлыклар һәм кайгылар, табышлар һәм югалтулар, сокланулар һәм ачынулар, җиңүләр һәм җиңелүләр кичерәбез. Нindидер гаделсезлектән елыйсы, яки сөенеч – шатлыклардан йолдызларга сикерәсе килә. Беркемгә дә сөйләргә теләмәгән яшерен серләр бар. Менә шундый чакта кеше күңелендә шагыйрьлек уяна да торгандыр. Әлбәттә, һәркем шигырь язмый. Ләкин күңелендә матурлыкны күреп соклана, яманлыкка нәфрәтләнә белү хисләре бар икән, син җаның белән шагыйрь, синең күңелең бай. Бай күңелле кешеләр генә дөньяга матурлык өләшә ала.

**Йомгаклау**

Минем уйлавымча, Рифат Сәлахның шигырьләрендә саф мәххәбәт тә,тирән фәлсәфә дә,милләтебез язмышы өчен борчылу да,сүз уйнату –шаянлык та бар.Милли темага кагылышым әсәрләрендә татар тарихы һәм аны барлау,бүгенге вазыять һәм милләтнең киләчәге турында уйлану ачык тоемлана.Яшьләр арасында иң моңлы, иң

романтик шагыйрь кем дип сорасалар, һич тартынмыйча, Рифат Сәлах исемен атар идем. «Казан егетләре», «Райян», «Рәхәт Лукум» төркемнәре башкарган кайбер җырлар да аның сүзләренә язылган. Дус-ишләре арасында гармун тартырга хирыс егетнең зур сәхнәләргә менмәгән, үзе көйгә салган җырлары да байтак әле. Бик талантлы бит ул. Кайчандыр «Шәрык» клубы кичәләренә йөргән кызлар, аның гармун тартып, җыр сузуларын әле дә сагынып искә ала. 25 яше тулганчы ук, хаҗга да барып кайта. Әдәбиятка һәм күңелләргә үзәк өзгеч мәхәббәт сагышыннан торган иҗаты белән килеп керә. Әлбәттә, шагыйрь шигырьләренең популяр, халыкчан булуын ассызыклый.

**Кулланылган әдәбият**


1. Әдәбият белеме сүзлеге. Редакторы Ахмадуллин. –Казан: Татар кит. нәшр, 1990
2. Әдипләребез. Биобиблиографик белешмәлек. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2009 ел.
3. Батулла Р. Сихрилек //Мәдәни җомга. — 2006. — 9 июнь.
4. Газизова Э. Илһам вакытны сорап килми... // Афәрин. — 2008. — № 12.
5. Зарипова А. Эзләнүчән укучыларыгыз булсын // Мәдәни җомга. — 2009. — 5 июнь.
6. Зәйдулла Р. Шигырьләргә кереш сүз // Идел. — 2005. — № 10.
7. Зәйдулла Р. Яңгыравык балчык // Идел. — 2008. — № 2. — 36-37 б.
8. Латыйпова А. Законны да шигырь итеп язып була... // Ватаным Татарстан. — 2006. — 8 дек.
9. Рәшит Ә. Гомерләрнең кызыл юлы // Мәдәни җомга. — 2007. — 7 сент.
10. Рифат Сәлах– Wikipedia материаллары.
11. Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. Казан: Мәгариф, 1994.
12. Сәлахов Р.Г. Күңел бөртекләре. –Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2007.
13. Сәлахов Р.Г. Ташта үскән гөлләр. –Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2012.
14. Сәлахов Р.Г.Яшел ай. –Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2009.
15. Хаков В.Х. Татар стилистикасына кереш. –Казан унив. нәшр, 1993.


Кушымта



Рифат Сәлах шигырь укый




Гармун тартып, җыр сузулар.

*Автор: Ханмурзин Салават Сәйдәшевич, __"ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЛАР СОЮЗЫ ГЕРОЕ ШАФРАНОВ П.Г. ИСЕМЕНДӘГЕ ЗУР ФРОЛОВО ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ" МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ , 6 нчы сыйныф*
*Фәнни җитәкче: Исмәгыйлева Гөлнара Таһир кызы*

## РИФАТ СӘЛАХНЫҢ ШИГЪРИ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ТЕЛ-СУРӘТЛӘҮ ЧАРАЛАРЫ КУЛЛАНЫЛЫШЫ

**План.**

I. Кереш.
Рифат Сәлах поэзиясе һәм аның әсәрләрендә тел-стиль үзенчәлекләре.
II. Рифат Сәлах иҗатында тел-стиль чаралары:
а) чагыштырулар;
б) сынландырулар;
в) оксюмороннар;
г) синонимнар;
д) рефрен юллар;
е) эпитетлар.
III. Йомгаклау. Шагыйрьнең лирикасы.
IV. Кулланылган әдәбият
V. Кушымта

**Кереш**

Һәр төбәк үзенең танылган шәхесләре белән горурлана. Безнең якларда да андыйлар аз түгел. Ренат Харрис, Әхмәт Рәшитов, Тәүфикъ Камалиев, Рифат Сәлахов, шагыйрә Йолдыз Шәрәпова, Динә Камалетдинова, Гөлнур Айзатуллова һ.б. кемнәр генә белми икән? Аларның иҗатында тирә-юнь гүзәллеген ачучы әсәрләр зур урын алып тора.

Рифат Сәлах - алгы сафта баручы яңа, яшь буын шагыйрьләрнең берсе. Аның шигырьләрендә мәхәббәт тә, тирән фәлсәфә дә, милләтебез язмышы өчен борчылу да бар. Бүгенге көн яңа татар әдәбияты күгендә Рифат Сәлах дигән яшь шагыйрьнең үз йолдызы кабынды.

Шагыйрьнең бер генә шигыре дә укучыны битараф калдырмый, күңел кылларын тибрәндерә, күңелне дулкынландыра, кыбырсыта. Алай гына да түгел, бер дулкын булып үзенә алып кереп китә. Шагыйрь төрле темаларны күтәрә. Бигрәк тә ул мәхәббәт лирикасында көчле. Табышлары да байтак. Шигырьләрнең халәти үлчәмнәре, хисси

контрастлары төрле: бәхетле – бәхетсез, сагышлы – сөенеч катыш, җавапсыз – нәтиҗәле, моңсу – шатлыклы, көчле – очкынланып торучан, тирән – җиңелчә... Аларның Рифат Сәлах каләменнән агылганын тоеп була. Димәк, шагыйрьнең үз стиле бар дигән сүз.

Рифатның милли темага кагылышлы шигырьләрендә татар тарихы һәм аны барлау, бүгенге вазгыять һәм милләтнең киләчәге турында уйлану ачык тоемлана. Ул борчыла, үз халкын горур, көчле, ирекле итеп күрергә тели.

Шагыйрьнең шигырьләре метафораларга, стилистик фигураларга, кабатлауларга бай. Мин эзләнү эшемдә Рифат Сәлах иҗатында очраган кайбер чагыштырулар, оксюмороннар, синонимнар һәм сынландыруларга салынган фикерне ачыкларга тырышырмын.

Тикшеренү эшенең актуальлеге һәм фәнни кыйммәте –шагыйрәнең шигъри әсәрләрендә тел-сурәтләү чараларының кулланылышын билгеләүдә.

Эшнең максаты –Рифат Сәлахның күпкырлы эшчәнлеген билгеләү.

Бурычлары:

1) Якташымның күпкырлы талант иясе булуын күрсәтү.
2) Хәзерге татар поэзиясенә җитди өлеш керткән булуын раслау.
3) Шагыйрәнең әсәрләрендә тел-сурәтләү чараларын барлау.

Эзләнү эшем кереш, төп өлеш һәм йомгактан тора.

Өстәлемдә Рифат Сәлах китаплары. Эзләнүләр барышында аларны кат-кат актарып, өйрәнеп, аерым очракларда бик тә үзенчәлекле шигырьләрен рәхәтләнеп, яңадан укыйм. Шигырь бит ул укучы күңеленә катлаулы вакыйгалар, мавыктыргыч сюжет белән генә кереп калмый. Шигырьнең төп максаты - укучының күңеленә, йөрәгенә, бәгыренә үтеп кереп, аның уйларын тирәнәйтү. Шигырь язучыларның эчке рухи дөньялары искиткеч бай, катлаулы, каршылыклы икән!

Якташымның шигърият диңгезендә лаеклы урыны бар.

**Төп өлеш**

Тропларның иң гади һәм киң таралган төрләренең берсе – **чагыштырулар.** Рифат Сәлах иҗатында алар бик күп.

Мисалга түбәндәге юлларны китерә алабыз:

Алларымда
Истәлегең тора –
Соңгы ядкяр – тәүге китабың.
<u>Сурәтеңне</u>
Яңа бөреләнгән
<u>Ак каеннар белән бутадым.</u>
(“Саташу”)

Дөньяда сүзләр генә җитмәс,
Әйтеп бирер өчен күңелдәген.
Төнге күктә <u>йолдыз</u> дигән идем –
<u>Чыклы иртә икән иреннәрең.</u>
(“Тәүге адашу”)

Алдагы троп шигъри юлларның тәэсир көчен арттыра.

Ашың булса әгәр,
Башың булса,
Күкләреңдә аең бер калкыр.
<u>Үзебез</u> дә илсез-җирсез килеш
<u>Таш өстендә үскән куактыр!</u>
(«Таш өстендә үскән куаклар»)

Шагыйрь хисләрне сурәтләгәндә дә чагыштырулардан оста файдалана.

Күз яшеңне яшермә син, яме,
Күренәсе инде күренгән.
Кочак-кочак кызыл гөлчәчәкләр
Ташып чыккан чагы күңелдән.

("Гөлчәчәкләр")

"Кыйгач кашым" шигыре Рифат Сәлах иҗатында чагыштыруларның шактый күп булуын раслый, алар сөйләмгә җанлылык, эмоциональлек бирә, автор хикәяләвенә төзеклек, үтемлелек өсти.

Карлыгачтай кыйгач синең кашың,
Ә күзләрең – күзгә төннең үзе.
Сабырсыз дип гаеп такма, җаным,
Күңелкәем инде күпме түзде?
Төнге җилдәй озын толымнарың!..
Кем үрелде аңа, кемнәр кисте?
Сабырсыз дип гаеп такма, җаным,
Күтеп торалмадым айлы кичне.
Күңел дөньяң диңгез сыман синең,
Язмышың да шундый: дулкын-дулкын.
Син дөньяның иң гүзәле идең...
Ә мин сиңа тагын гашыйк булдым.

Сурәтләнә торган объектына туры китереп шагыйрь чагыштыруларның яңадан-яңаларын иҗат итә.

Тәрәзәң төбендә карашың...
Син дә мин атлыйбыз янәшә.
Офыклар – ул безнең тәрәзә,
Үзенә чәчәкле җәй дәшә...
("Тәрәзәңдә нинди моң?")

Баткан кояш яктысында
Чагыла гүя йөзең.
Бит очларың әйтерсең лә
Кызарып пешкән йөзем.
("Кызарып пешкән йөзем ")
Син дә күңелем түрендә
Сары яфрак сыман.
Ничек котылырмын икән
Көзләр арасыннан.
("Көзге элегия")

Алдагы мисаллар Рифат Сәлах иҗатында чагыштыруларның шактый күп булуын раслый, алар сөйләмгә җанлылык, эмоциональлек бирә, автор хикәяләвенә төзеклек, үтемлелек өсти.

Киң таралган поэтик тропларның тагын берсе – **сынландыру.** Сынландыру табигать күренешләрен, тере булмаган әйберләрне җанлы әйберләргә хас сыйфатлар белән сурәтләүдән гыйбарәт. Алар әдәби текстта сурәтләнә торган предметка җанлылык бирү өчен кулланыла. Рифат Сәлах шигъри әсәрләрендә сынландыруларга да мисаллар табып була:

Моңсу караш дисәм, алай түгел,
Төште микән аңа авыр уй?
- Хәлең ничек, дустым, нәрсә булды?
- Берни дә юк. Җаным авырый!...
("Җаным авырый")

Чынында җан – авырмый. Автор аларны җанлы, тере итеп тасвирлый.

Гармунда уйныйсың, эти,
Тирбәтеп күңел кылын.
Яныңда уйнап утыра,
Бу – улың, эти, улың.
("Эти")
Иман да бит һәрчак мәңге түгел,
Ул җуела кайчак, киселә.

Киселмәгән кая, нишләп була,
Кызыл балта төшсә өстеңә?!
(“Яңа мәчет”)
Намазга басар вакытта
Әрнидер мескен җаның.
Тыңлаучыларың табылыр,
Гомерлек булса зарың.
(“Намазга басар вакытта...”)
Гөнаһлар тәүбәгә китерә,
Ялгышлар төзәлер – үкенмә.
Сагынасыңдыр ул таңыңны,
Гомерең тиң булса бер көнгә.
(“Күбәләк”)
Алдагы троп шигъри юлларның тәэсир көчен арттыра.
Каләмемнең очына нур кунды –
Бәйрәм көн бүген.
(“Күтәренке кәеф”)

Шулай итеп, авторның бай теле, чагыштыру, сынландыруларны оста куллануы – аның кабатланмас язу стилен формалаштыруга һәм мәхәббәт, табигать кебек олы төшенчәләрне ачуга китерә. Шагыйрьнең әсәрләре үзенең ритмы һәм аһәңе белән укучының җанын, рухын җәлеп итә, аларның камиллеге, гармония бөтенлеге һәм нәфислеге үзенә тарта.

Мисалга китерелгән сынландыруларда автор абстракт күренешләргә җан өрсә, түбәндәге юлларда табигатьнең матурлыгын сурәтләү өчен тропларның бу төренә мөрәҗәгать итә:

Айның бүген тулып көлгән чагы –
Тау эчендә тора эленеп.
(“Ай кызы”)

Шулай итеп, авторның бай теле, чагыштыру, сынландыруларны оста куллануы – аның кабатланмас язу стилен формалаштыруга һәм мәхәббәт, табигать кебек олы төшенчәләрне ачуга китерә. Шагыйрьнең әсәрләре үзенең ритмы һәм аһәңе белән укучының җанын, рухын җәлеп итә, аларның камиллеге, гармония бөтенлеге һәм нәфислеге үзенә тарта.

Рифат Сәлах үзенең шигырьләрендә **оксюмороннарны** да мул куллана.

Кеше күңеле – мең кат челтәр генә,
Челтәрләрен кемнәр үргәндер?
Упкыннарга меңләп сукмаклар бар,
Аннан чыгу юлы бердәнбер!
(“Челтәр”)
Мин әзермен иртән кабынуга,
Мин әзермен кичен сүнүгә.
Сүнеп торуларым мөһиммени,
Кояш чыкса бүген күгемә?!
(“Кояш чыга”)

Шагыйрь теленең байлыгы да, андагы **синонимнарның** күп булуы белән билгеләнә.

Сагышларым ерак калды синнән,
Сөен-шатлан, һәрчак көлеп тор.
Оныттыра алсаң, җанымдагы
Бөтен борчуларны оныттыр.
(“Сагышларым ерак калды синнән”)
Син ягымлы... Рәхмәт! Гел шундый бул,
Якын дустым, җаным, матурым!...
Син ачасың мине иркәләргә

Тәрәзәдән төшкән таң нурын.
(“Таң нуры”)
Хаталы укысак намазны,
Ходаем, гафу ит син, кичер.
Казасыз калмабыз,
Газаптан коткарчы
Иманга сусаган җан өчен.
(“Ураза гаете”)

Шагыйрь **рефрен** юллар кулланып күпмедер дәрәҗәдә шигырьләренең гомум рухын, моңын билгели. Мәсәлән,

Язмыш мәллә безне бәйләп куйган,
Китә алмыйм синнән һаман да.
Мин талпынам, синнән китәрмен дип,
Китәрмен дип әллә кайларга.
Язмыш безне бәйләп куйган бугай,
Якын бара алмыйм үзеңә.
Бөтен хисләремне бүләк итәм,
Бүләк итәм синең исемгә.
(“Сөйгәнем”)

Шагыйрь үз иҗатында сурәтлелек тудыруда иң актив файдаланыла торган чараларның берсе **эпитетларны** файдалана. Алар күп төрле һәм сурәтлелек тудыруда катнашучы башка чаралар белән катнашып, аралашып киләләр:

Йокларга да кем яратмый аны?!
Иркә булып үстем бугай мин.
Күзләремдә гамь сүнсә дә, әни,
Таш йөрәкле кеше булалмыйм.
(“Син иртәгә иртә уят, әни!”)

Көмеш ай нурлары биешә,
Йолдызлар чаткысы чагыла.
Тәүбәгә, тәүбәгә ашыга
Күңеле иң садә чагында.
(“Намазлык”)

Гомереңнең таныш кыйгач нуры
Күчкән, диләр, диңгез артына.
Идел нурсыз хәзер. Ялкау кояш
Идел аръягында яктыра.
(“Эңгер-меңгер”)

Гомумән алганда, Рифат Сәлахның тел-сурәтләү чараларын өйрәнү, беренчедән, аның шигъри осталыгын аңлау мөмкинлеге бирде. Икенчедән, авторның иҗат лабораториясен ачуга юл күрсәтте.

**Йомгаклау**

Яшьләр арасында иң моңлы, иң дини, иң романтик шагыйрь кем дип сорасалар, һич тартынмыйча, Рифат Сәлах исемен атар идем. «Казан егетләре», «Райян», «Рәхәт Лукум» төркемнәре башкарган кайбер җырлар да аның сүзләренә язылган. Дус-ишләре арасында гармун тартырга хирыс егетнең зур сәхнәләргә менмәгән, үзе көйгә салган җырлары да байтак әле. Бик талантлы бит ул. Кайчандыр «Шәрык» клубы кичәләренә йөргән кызлар, аның гармун тартып, җыр сузуларын әле дә сагынып искә ала. 25 яше тулганчы ук, хаҗга да барып кайта. Әдәбиятка һәм күңелләргә үзәк өзгеч мәхәббәт сагышыннан торган иҗаты белән килеп керә.

Саф, эчкерсез шигъри тәлгәшләр. Аларны укыгач, ничектер үзең дә караңгы вазгыятьне онытып, дөньяга, кешеләргә мәхәббәт белән, Рифат Сәлах күзләре аша карый башлыйсың.

Шагыйрьнең әсәрләре метафораларга, кабатлауларга бай. Без эзләнү эшебездә Рифат Сәлах иҗатында очраган кайбер кайбер стиль чараларын күрсәтергә тырыштык.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Рифат Сәлах шигъриятенең сәнгатьчә җитлегүе, эчтәлек һәм форма берлегенә, гармониясенә ирешүе, актуаль - тормышчан яңгыраулары, аларның сюжет һәм композицион бөтенлеге, барлык тел - сурәт чаралары байлыгын, поэтик активлыгын даими бер максатка буйсындыру белән тудырыла диеп әйтә алабыз. Бу, әлбәттә, шагыйрь шигырьләренең популяр, халыкчан булуын ассызыклый.

Эш барышында алдыбызга куйган максат һәм бурычлар чишелде. Тикшерү эшебездә Рифат Сәлах китапларын кулландык, җырлары белән таныштык, “Контактта” челтәрендәге яңалыкларны күздән кичердек, фото һәм видеоматериаллар карадык. Якташымның иҗаты миңа якын һәм кадерле.

**Кулланылган әдәбият**


1. Әдәбият белеме сүзлеге. Редакторы Ахмадуллин. –Казан: Татар кит. нәшр, 1990
2. Әдипләребез. Биобиблиографик белешмәлек. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2009 ел.
3. Батулла Р. Сихрилек //Мәдәни җомга. — 2006. — 9 июнь.
. 4. Газизова Э. Илһам вакытны сорап килми... // Афәрин. — 2008. — № 12.
5. Зарипова А. Эзләнүчән укучыларыгыз булсын // Мәдәни җомга. — 2009. — 5 июнь.
6. Зәйдулла Р. Шигырьләргә кереш сүз // Идел. — 2005. — № 10.
7. Зәйдулла Р. Яңгыравык балчык // Идел. — 2008. — № 2. — 36-37 б.
8. Латыйпова А. Законны да шигырь итеп язып була... // Ватаным Татарстан. — 2006. — 8 дек.
9. Рәшит Ә. Гомерләрнең кызыл юлы // Мәдәни җомга. — 2007. — 7 сент.
10. Рифат Сәлах– Wikipedia материаллары.
11.Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. Казан: Мәгариф, 1994.
12. Сәлахов Р.Г. Күңел бөртекләре. –Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2007.
13. Сәлахов Р.Г. Ташта үскән гөлләр. –Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2012.
14. Сәлахов Р.Г.Яшел ай. –Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2009.
15. Хаков В.Х. Татар стилистикасына кереш. –Казан унив. нәшр, 1993.




Рифат Сәлах шигырь укый






Төркиядә





Гармун тартып, җыр сузулар.

*Автор: Сафиуллина Ләйсән Радик кызы, 11 нче мәктәп сыйныфы: 5 в*
*Фәнни җитәкче: Ильясова Миннәзия Тимергали кызы*

**Татарстанда туып, Германиядә яшәүче яшь шагыйрә – Гөлназ Вәлиева**






Гөлназ Мөдәррис кызы Вәлиева 1983 елның 25 августында Казанда язучы Мөдәррис Вәлиев гаиләсендә дөньяга килә. Сабый чагыннан ук гаиләдә милли тәрбия алып, туган телнең тәмен тоеп, әдәби иҗат эшенә һәвәс булып үсә. Гөлназның әтисе дә шагыйрь. Ә әнисе Даимә ханым — дәреслекләр бастыручы. Рус мәктәбендә укыганлыктан, тәүге әдәби тәҗрибәләрен ул рус телендә яза, мәктәп балалары өчен уздырылган иҗат конкурсларында беренче урыннарны яулый. 1998 елдан Гөлназ татар яшьләренең «Сәләт» иҗтимагый оешмасы эшләренә якыннан катнаша. «Сәләт» мохите, иҗатка сәләтле татар яшьләре белән аралашу аның иҗат омтылышларына уңай йогынты ясый. Ул татарча язылган шигырьләре, хикәяләре, әкиятләре белән «Мәдәни җомга», «Мәгърифәт», «Сабантуй», «Шәһри Казан», «Ватаным Татарстан» газеталары, «Казан утлары», «Ялкын», «Идел» журналларында күренә башлый.

2000 елда Казандагы 70 нче урта мәктәпне тәмамлап, берьюлы ике югары уку йортына – Казан дәүләт университетының журналистика һәм Казан дәүләт педагогика университетының чит телләр факультетына укырга керә. Шул ук елда аның «Милли китап» нәшриятында Равил Фәйзуллин кереш сүзе-фатихасы белән шигырьләре һәм хикәяләре тупланган «Тылсым» исемле китабы дөнья күрә. «Тылсым» республика күләмендә үткәрелә торган «Ел китабы» бәйгесендә кызыксындыру дипломына лаек була. Яшь каләм тибрәтүченең әдәби язмалары 2001 елда «Мәгариф» нәшрияты бастырып чыгарган «Җәйнең җиде төсе» дигән җыентыгына кертелә. Бу ике китаптагы әсәрләре уңаеннан республика газеталарына язган рецензияләрендә Ф.Яруллин, Р.Әхмәтҗанов, Р.Гаташлар каләм тибрәтүченең беренче иҗат нәтиҗәләренә уңай бәя бирәләр. Аның 2005 елда Татарстан китап нәшриятында «Күңел күзе» дип аталган икенче китабы басылып чыга. Шул ук елны Гөлназ Казан дәүләт педагогика университетының чит телләр факультетын тәмамлый. Яшь шагыйрә Казан дәүләт университетының француз теле кафедрасы аспиранты буларак, фәнни иҗат белән дә шөгыльләнә. Гөлназ хәзерге вакытта Германиядә яши. Ул Германиядә яшәүче татар яшьләренең "Аргамак" берләшмәсендә эшли **.** Бу оешма 2015 елда барлыкка килгән. Оешманың төп максатларыннан берсе – балаларга татар телен өйрәтүгә шартлар булдыру. Чит илдә туган сабыйларга бу аеруча кирәк. "Аргамакка" йөрүчеләр арасында Германиягә күптән күчкәннәр дә, студентлар да бар. Проектның төп максатлары – милли үзаңны үстерү һәм саклау максатыннан, Германиядә, гомумән, Европада яшәүче татарларны берләштерү, аларны милли рухлы чаралар үткәрүгә өндәү, Татарстанны, татар халкын, аның мәдәниятен башка милләтләр арасында таныту, чит илләрдә популярлаштыру. "Көзге очрашу"га, гадәттә, Европаның төрле илләреннән 150ләп кеше килә. "Очрашу гаилә белән кич утыру форматында үтә. Профессиональ башкаручылардан кала, һәркемгә чыгыш ясау мөмкинлеге бирелә. Шул рәвешле, кунаклар да бәйрәмнең режиссеры була ала. Теләгән кеше татарча шигырь сөйли, җыр җырлый. Балалар өчен аерым бүлмә эшли. Анда татар мультфильмнары күрсәтелә. Кунаклар өчен сабыйлар катнашында татарча спектакльләр дә куела", дип сөйләде "Аргамак" вәкиле. Ул Германиядә "Көзге очрашу"дан тыш та, мәдәни чаралар, татар милли тәм-томнары кичәләре, балалар өчен очрашулар уздырыла. Үзенең гаиләсе, балалары, дустлары турында шагыйрә болай дип сөйли: "Минем ике балам бар. Олысына беренче тел итеп татар телен өйрәттек. Аңа хәзер 5 яшь. Ул саф татар телендә сөйләшә. Әмма балага кимендә тагын 3 тел өйрәнергә кирәк: Германиядә яшәгәнгә күрә – немец

телен, Россиягә кунакка кайтканда аралашыр өчен – рус телен, шулай ук халыкара саналган инглиз телен. Әлбәттә, бу җиңелләрдән түгел. Шундый очраклар да була: әтисе яки әнисе татар булган катнаш гаиләдә туган бала көннәрдән бер көнне татар телендә сөйләшүдән бөтенләй баш тарта. Әнисе татар телендә эндәшсә дә, ул аңа алман телендә җавап бирә. Башка милләт вәкилләрендә кияүдә булган татар дус кызларым еш кына балам татарча сөйләшми дип елап шалтырата", ди. Гөлназ Вәлиева. Казанга елга 1-2 тапкыр кайтып килергә тырыша. . Интернет аркылы Татарстандагы, Казандагы вакыйгаларны, шулай ук милли дизайн өлкәсендәге яңалыкларны күзәтеп бара.

Ә Татарстанда аның "Урманчы әкиятләре , "Күңел күзе" китапларындагы әкиятләрне , шигырьләрне балалар яратып укый.Түбәндә Гөлназ Вәлиеваның "Үкенеч" исемле шигырен тәкъдим итәм.

Үкенеч.
Әй, әбием, әбекәем минем,
Тау битендә җиләк җыйганда
Шулай бик тиз бездән китәрсең дип
Кермәде дә хәтта уйларга.
Тау битендә җиләк яфраклары
Чыланыр ла яшемә....
Син гел безне көтеп яши идең,
Калды сине сагынып яшәргә.

*Автор: Җиһаншин Ринас Рафаил улы, 5 нче гимназиянең 6 сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Җиһаншина Җәмилә Хаҗиәхмәт кызы,5 нче гимназиянең башлангыч сыйныф укытучысы*

## Фәнил Гыйләҗев иҗатына күзәтү

**Эчтәлек**

1. Кереш өлеш.
2. Төп өлеш. Яшь шагыйрь иҗаты белән таныштыру .
3. Йомгаклау.

Эзләнү эшемне башларга мине гап-гади бер очрашу этәрде. Ул көнне гимназиябезгә «Казан утлары» журналы хезмәткәрләре килгән иде. Шунда яшь шагыйрьгә сүз бирелде. Ул үзенең берничә шигырен укып китте. Кызыксынуым шундый көчле булды ки, аның иҗаты белән якыннанрак танышырга булдым. Бүген сезне дә яшь буын шагыйре, «Эт өрә тора, бүре йөри тора» дигән тормыш девизы белән яшәүче, Фәнил Гыйләҗев иҗаты белән таныштырасым килә. Күбрәк иҗтимагый-сәяси темаларга иҗат итүче егет милләтне, кешелекне борчыган сорауларны, бүгенге көн кадагына сугардай темаларны күтәрә.



Язу эшчәнлегемнең максаты, Тукайча әйтсәк, «*Халыкка хезмәткә, Хезмәт эчендә йөзмәккә*» – ди яшь шагыйрь.

Фәнил Фаил улы Гыйләҗев 1987 елның 16 маенда Казан шәһәрендә туа. Чирмешән районының Ибрай Каргалы (Керкәле) авылында үсә. 2005 елда Чирмешән районының Югары Кәминкә урта мәктәбен тәмамлап, шул ук елны Казан Дәүләт Университетының журналистика һәм социалогия факультетына читтән торып укырга керә. Студент елларында «Әллүки» түгәрәгенә йөри. 2010, 2011 елларда «Иделем акчарлагы», «Таян Аллага» яшь язучыларның әдәби бәйгеләрендә Гранпри иясе була, 2012 елны ТАТМЕДИА үткәргән бәйгедә 1 урын яулый. 2011-2014 елларда «Шәһри Казан» газетасында журналист булып эшли. Шигырьләре Республика матбугаты битләрендә, шулай ук «Ак юл» күмәк җыентыгында урын ала. 2014 елда Татарстан китап

нәшриятында «Ризасызлык» дигән шигырьләр җыентыгы дөнья күрә. 2015 елның февраленнән «Казан утлары» журналында бүлек мөхәррире булып эшли башлый .

«Җәй көне балык тотарга, төрки илләргә сәяхәт итәргә яратам. Шигырь язуны хоббига саныйм. Язу – ул күңел таләбе. Кумирларым юк. Стимулны күңел халәте, һәртөрле кичереш-тәэсирләр бирә. Бүгенге көнне матбугат битләрендә басылучы шигырьләрне кызыксынып укып барам. Бигрәк тә үземнең яшьтәшләрнең иҗатын яратып күзәтәм» – ди шагыйрь.

Ф. Гыйләҗевнең бер генә шигыре дә укучыны битараф калдырмый, күңел кылларын тибрәндерә, дулкынландыра. Алай гына да түгел, бер дулкын булып үзенә алып кереп китә.

Шагыйрь “**Тукай китабы”, “Татар теле”**шигырьләрендә туган тел проблемаларын күтәрә.

Тукай багып ачы көләр сыман,
Көләр сыман бездән кычкырып.
Һәм ютәлләр ил ютәле белән:
«Бетәсез бит, – диеп, – тончыгып».

Хәзерге заманда туган телен дә, русча һәм инглизчә дә белгән кешеләр кирәк. Әмма без туган телдә иркен аралашырга тиеш. Бу милләтнең, халыкның саклануы өчен төп шарт.

**Татар теле**

«Татар теле – туган тел ул!» – дибез.
Тууын ул үзе туган да,
Яши бирә, никтер, бер «почмакта»,
Оялчан ул, чыкмый урамга.

Шагыйрьнең милли темага кагылышлы шигырьләрендә татар тарихы һәм аны барлау, милләтнең бүгенгесе һәм киләчәге турында уйлану ачык тоемлана. Ул борчыла, үз халкын горур, көчле, ирекле итеп күрергә тели.

**«Исхакый кабере» шигырендә шагыйрь гомер буена халыкка хезмәт иткән, үз бәхете өчен түгел, ә халкының, милләтенең бәхете өчен көрәшкән әдип белән сөйләшә.**

Танып алдык сине әллә каян,
Кабереңнән якты нур балкый!
Чытырманлы зират ватаныннан
Күп сәламнәр сиңа, Исхакый.
Син дә безне таныдыңмы икән?
Син язганнар безгә көч бирә.
Бер кайтырсың, диеп, бөек улын
Көтә әле, көтә Яуширмә.

**Һәркем үзенең нәсел тамырларын, кан кардәшләрен, ата-бабаларының кем булуын белергә тиеш бит. Үз ата-бабаларыңның, халкыңның, илеңнең чын тарихын, тормышын өйрәнү, белү – һәркемнең бөек бурычы.**

**«Хәтер җиле» шигыре шуңа дәлил.**

Алар тез чүкмәде, буйсынмады...
Шуңа алар исән бүген дә.
Баш бирмәгән яугир халкым минем –
Горурлыгым күңел түремдә.
Шул дәвердән киткән йола белән
Мин дә дәшәм: «Халкым, исәнме?!»
Чорлар аша хәтер җиле исә:
«Мәңге исән, улым, без мәңге!»

**Ә “Исемсез ташлар”шигырен үткәннәрне, бүгенгене һәм киләчәкне күз алдына китереп иҗат итә.**

Чалгы чыжлый. Печән арасыннан
Ташлар калка анда-санда ауган.

Дала уртасында һәйкәл булып
Исмен җуйган ташлар гына калган...

**Татар халкын авылларсыз күз алдына китерү бик авыр. Авыллар гомер буе әхлакый-тәрбияви сыйфатлар бирүче изге урын булган. Кызганычка каршы авылларның күбесе җир йөзеннән мәңлеккә юкка чыкты... Авыллар белән бергә хәтер, тарих, ядкәрьләр югалды. Күпме матурлыклар, күпме гаилә истәлекләре, үрнәк яки гыйбрәт булырлык язмышлар, тарих кайнаган нигезләр гасырлар чоңгылына күмелде. Авыллары юк ителгән кешеләрнең кайтып сыеныр почмаклары, зиратларында әрвахлары катында баш ию мөмкинлеге калмады. «Авыл янган», «Җуелган киртәләр» шигырендә Фәнил Гыйләҗев шушы проблемаларны күтәрә.**

**"Авыл янган"**

Эшсезлектән түгел,
Чарасызлыклардан янган ул.
Тыныч кына,
Утсыз-төтеннәрсез
**Хәрәбәләр булып калган ул...**

**Хәдистә болай диелгән «Ризыгы киң һәм гомеренең озын булуын теләгән кеше туганнары белән элемтәне өзмәсен».**

**Ә күренекле галимебез Р.Фәхреддиннең «Нәсыйхәт» исемле хезмәтендә менә шушындый юллар бар «Туганнарыгыз ата–аналарыгыздан соң иң якыннарыгыздыр. Шуның өчен алар белән һәрвакыт әдәпле һәм мәрхәмәтле булыгыз. Олы яшьтәге туганнарыгызга итагатьле булыгыз, сүзләрен тыңлагыз. Кечкенәләренә карата рәхим–шәфкатьле булыгыз». Шушы фикерләргә таянып булса кирәк, «Туганнар» шигыре язылган.**

**Туганыңның сүзе рәнҗетми ул –**
**Чит тукраннар каты томшыклы.**
**Тукраннарың булу бәхет бит ул –**
**Үзе чукый, читтән ышыклый...**

**Һәр кеше бу дөньяга бәхет өчен яратылган. Гомер юлы бик озын тоелса да, тиз үтә. Шуңа күрә һәрберебез тигез юлдан тайпылмыйча, изге гамәлләр генә кылып яшәсәк иде. «Ялвару» шигырендә шагыйрь, барчабыз исеменнән Ходайга ялварып, гөнаһларыбызны кичерүне үтенә.**

Йа Ходаем, рәхмәтең киң,
Кичерүче Син үзең!
Дөньялык ваклыкларыннан
Арындыр күңел күзем...

Яшьләр арасында милләтне, кешелекне борчыган сорауларны күтәреп чыгучы шагыйрь кем дип сорасалар, һич тартынмыйча, Фәнил Гыйләҗев исемен атар идем.

**Нәтиҗә ясап әйткәндә, Фәнил Гыйләҗевнең шигырьләре актуаль, популяр, халыкчан.** Безгә тагын шунысы да ачык: ул һәрвакыт бөтен җаны- тәне белән үзенең укучылары язмышы өчен янып яши, аның тормыш- көнкүрешен яхшырту турында кайгырта, телебез, гореф- гадәтләребезне саклау һәм үстерү өчен тырыша. Табигый таланты, гаять зур тырышлыгы, ил язмышы белән яшәве аны республикабызның әйдәп баручы шагыйрьләре рәтенә бастырыр. Шагыйрь шәхесе һәм иҗаты җентекләп, кызыксынып, үз итеп, якын күреп, зурлап өйрәнүгә лаек.

**Секциянең исеме “Дәрестән тыш эшчәнлектә яшь шагыйрьләр һәм язучылар иҗатын файдалану”.**

*Автор: Сабирҗанова Гөлнара Фоат кызы*
*Муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Аксу урта гомуми белем мәктәбе”*

# Рифат Сәлах – иҗатында туган як

**Дәрестән тыш эшчәнлекнең план - конспекты**

| Этаплар | Бурычлар | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге | Формалаштырыла торган УУГ |
|---|---|---|---|---|
| **I.Оештыру. Максат.** Балаларда яхшы кәеф, эшлисе килү халәте тудыру. | Шигырь сөйләү, эшкә әзерләнү. | Яхшы кәеф булдырам.<br>-Хәерле көн, укучылар! Менә бу экрандагы кояшка карап, бер-беребезгә елмаю бүләк итеп, эшкә керешик. | Шигырь сөйлиләр, эшкә әзерләнәләр.<br>Кояш безне сәламли,<br>Без кояшны сәламлик.<br>Нурларыннан җылы алып,<br>Бер-беребезгә өләшик!<br>“Мин сиңа яхшылык телим.<br>Син дә миңа яхшылык телисең.<br>Авырлык килсә, мин сиңа ярдәм итәрмен!” | Укытучы-укучы, укучы-укучы хезмәттәшлеген планлаштыру. |
| **Мотивлаштыру. Максат.** Буа төбәгеннән чыккан нинди язучыларны, шагыйрьләрне барлау. | Укучыларның иҗади фикерләү сәләтен үстерергә җирлек булдыру | Безнең районыбыз талантлы шәхесләргә бик бай. Кемнәр генә юк алар арасында? Әдәбият һәм сәнгатьнең, фән һәм мәдәниятнең, хезмәт һәм батырлыкның кайсы гына тармаган алсаң да, тарихта үз исемен зур хәрефләр белән язып калдырган шәхеслеребез күп безнең.<br>Буа төбәге язучыларга да, шагыйрьләргә дә бай як. Ә сез Буа төбәгеннән чыккан нинди язучыларны, шагыйрьләрне беләсез? | Укучылар сорауга җавап бирәләр.<br><br>Йолдыз Шәрәпова<br>Ренат Харис<br>Гөлнур Айзатулова<br>Лилия Сәлахетдинова<br>Динә Камалетдинова<br>Әхмәт Рәшит | әңгәмәдә катнаша белү, эзлекле фикер йөртергә өйрәнү |
| **Белемнәрне актуальләштерү Максат.** Якташ шагыйрьләрнең балалар өчен язган берничә шигырләре белән танышу. | Шигырьләрне сәнгатьле уку. | Укучылар, әдәби уку дәресләрендә без сезнең белән инде шактый гына шигырьләр укыдык, аларны иҗат иткән якташ шагый-ребез белән дә таныштык. Ягез әле, аны искә төшереп үтик.<br>Әхмәт Рәшит , Йолдыз Шәрәпова портретлары белән эш оештырыла .<br>шагыйрьләр сезнең күз алдына нинди кеше буларак килеп баса? | Әхмәт Рәшит портреты өстендә эшлиләр . Әңгәмәдә катнашалар.<br>Әхмәт Рәшит, Йолдыз Шәрәпованың шигырьләрен сөйлиләр.<br>1нче укучы.<br>Ә.Рәшит “Кояшлы ил” шигыре.<br>2 нче укучы.<br>Й.Шәрәпова “ Кәефсез куян” | Иптәшеңне тыңлый белү, әңгәмәдә катнашу, нәтиҗә чыгару, тышкы портрет буенча кешегә бәя куярга, танырга өйрәну; |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Алар турында ниләр әйтерсез? Нинди шигырьләрен укып, ишетеп беләсез? | | |
| **Уку мәсьәләсен куюу** **Максат.** Проблемалы ситуация тудыру. | Укытучы куйган сорауларга җавап бирү. | Укучылардан теманы һәм дәреснең максатын билгеләтү.<br><br>Проблемалы сорау бирәм.<br><br>-Сез Әхмәт Рәшитнең авылдашы, яшь шагыйрь иҗаты белән танышырга телисезме?<br><br>Моның өчен нәрсә эшләрбез? Кичәбез кем турында булыр икәнен сез үзегез әйтерсез.<br><br>Әйе,бүгенге кичәбездә якташ шагыйребез Рифат Сәлахның иҗатында туган якның чагылышын өйрәнербез. | Сорауны тыңлыйлар, уйлыйлар, җавап бирәләр.<br>-Әйе, телибез.<br>Китап күргәзмәсенә һәм экранга игътибар итәбез.<br>Теманы билгелиләр: бүгенге дәресебездә якташ шагыйребез Рифат Сәлах иҗаты белән танышырбыз.<br>Дәреснең максатын билгеләү: Рифат Сәлахның тормыш һәм иҗат юлын өйрәнербез. | Укытучы юнәлеш биргәнчә уку мәсьәләсен куя, дәреснең максатын билге-ли белү, иптә-шенне тыңлый белү. |
| **Уку мәсьәләсен чишү.** **Максат.** Рифат Сәлахның шигырьләрен уку | Иҗади фикерли, үз хезмәтеңнән илһамлану алу. | | Бу шигъри юллар белән ул үзенең сагынуын басарга телидер сыман.Чөнки кеше кайда гына яшәмәсен, барыбер үзенең туган туфрагын тоеп яши. Аның матурлыгын, җылылыгын бервакытта да онытмый. | Нәтиҗә ясый, нәтиҗәне иптәшләренә җиткерә белүләре. |
| **Уку мәсьәләсен адымлап чишү эше** **Максат.** Р.Сәлахның туган авылына багыш-ланган шигырьлә-ре белән танышу. | Укучыларның сәнгатьле укуы | Р.Сәлахның туган авылына багышланган нинди шигырьләрен укыганыгыз бар?<br>Әйе ,бу шигырьләрен Рифат Сәлах үзенең туган авылы Яңа Чәчкапка багышлый. Шунда балачак еллары сизелми дә үтеп китә. Туган авылының чишмә-инешләренең челтерәп аккан суының тәмен шагыйрь һич онытмый. | **ТУГАН АВЫЛЫМА**<br>Сиңа кайттым әле, сагынылган.<br>Болыныңа чыктым кичкырын.<br>Мин яратам сине,туган ягым,<br>Бик яратам, диеп кычкырдым.<br>Кемдер,бәлки ишеткәндер мине...<br>Миңа җитә,үзең ишетсәң.<br>Туган ягым, мин тирбәлеп ятам<br>Күккә элгән яшел бишектә.<br>Егылсам бер торырмын әле,<br>Бишегеңнән генә төшермә!<br>...Мин җиһанның күккә элә торган<br>Йолдызлары туар төшендә!<br>**ЯҢА ЧӘЧКАП**<br>Туган авылым, Яңа Чәчкап<br>Гөрләп торасың микән?<br>Чит җирләргә чыгып киткәч,<br>Сагындырасың икән.<br>Бик сагындым, туган авылым,<br>Чәчәкле үзәнеңне.<br>Синең якты урамнарың<br>Күрмичә түзәрменме?<br>Кайтып бер әйләним әле<br>Елгаларың, суларың.<br>Нарат урманына кереп,<br>Саф һаваңны суламын.<br>Бик сагындым, туган авылым,<br>Ямьле Лашчы буйларын. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Еракка китеп барсам да,<br>Һәрчак синдә уйларым.<br>Уңган – булган халкың белән<br>Җиһанга нур чәч тагын!<br>Син һәрвакыт күңелләрдә,-<br>Җырга күчтең ,Чәчкабым.<br>Җырларымда яшисең син,<br>Исемең дә чәчә моң.<br>Еракларга китсәм дә мин,<br>Бер кайтырмын, Чәчкабым. | |
| **Ныгыту эше.**<br>**Максат.**<br>Укучының уку эшчәнлегенең мөйстәкыйльлеген тудыру. | Синквейн төзи, төркемнәрдә эшли белү. | Синквейн төзибез<br>1 нче төркем – Илкәем<br>2 нче төркем – Туган җирем | Укучылар синквейн төзиләр<br>Көтелгән җаваплар.<br>1 нче төркем<br>Илкәем<br>Матур,иркен<br>Сагындыра,чакыра ,иркәли.<br>Мин илкәемне бик яратам.<br>Ватан<br>2 нче төркем<br>Туган җирем<br>Газиз, ямьле<br>Дәшә, сагындыра,иркәли<br>И минем газиз җирем<br>Илкәем | Төркем белән эшләгәндә үз эшен оештыра белүе, үз-үзенә ышаныч булдыра, бәяләргә өйрәнүе, төркем эчендә аралашу калыбын төзүе, логик фикер йөртергә өйрәнүе |
| **Проект эше.**<br>**Максат.**<br>Белемнәрне яңа ситуациядә иҗади куллану. | Китапчык төзү.<br>Китапның исемен, авторын язу.<br>Төркемнәрдә эшләү:<br>1 нче төркемгә:<br>1. Рәсем ябыштыру.<br>2.Р.Сәлахның туган якка багышланган шигырьләреннән туган як турында язылган үзегезгә ошаган өзекләрне күчереп язарга.<br>3.Үз эшләрен яклау.<br>2 нче төркемгә:<br>1 Рәсем ябыштыру.<br>2. Р.Сәлахның туган якка багышланган шигырьләрдән туган як табигате турында язылган үзегезгә ошаган өзекләрне күчереп язарга.<br>3.Үз эшләрен яклау. | Эш тәртибе белән таныштырам. | Төркемнәрдә эшләү.<br>**1 нче төркем:**<br>1.Бик сагындым, туган авылым,<br>Ямьле Лашчы буйларын.<br>Еракка китеп барсам да,<br>Һәрчак синдә уйларым.<br>2.Ераклардан ничек итеп<br>Сәламнәрне юллыйсы?<br>Сагындыра, үзенә тарта<br>Туган туфрак җылысы.<br>3. Сиңа кайттым әле, сагынылган.<br>Болыныңа чыктым кичкырын.<br>Мин яратам сине,туган ягым,<br>Бик яратам, диеп кычкырдым.<br>**2 нче төркем:**<br>1.И туган ил,илем,илкәй генәм!<br>Иркен синең басу- кырларың.<br><br>2. Туган якта яңгыр коя икән...<br>Кайттым сиңа,яңгыр каршы ал.<br>Бөтен нәрсәдән дә якын җанга<br>Туган якта тамган тамчылар.<br><br>3. Кайтып бер әйләним әле<br>Елгаларың, суларың.<br>Нарат урманына кереп,<br>Саф һаваңны сулармын. | Кыенлыклардан чыгу юлларын эзләү, төркем-нәрдә эшли белү иптәшең фике-рен тыңлау, ур-так нәтиҗәгә килү, үз фике-реңне яклый белү,сөйләм төзү. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **Өй эше. (Төрле авырлыкта бирелә.)** | | 1. Үзегезгә ошаган шигырьне ятларга<br>2. Үзегезгә ошаган шигырьне сәнгатьле укырга, шигырь буенча рәсем ясап килергә.<br>3. Үзегезгә ошаган шигырьне сәнгатьле укырга. | | |
| **Рефлексия.** | Сорауларга җавап бирү. | Сораулар бирәм.<br>- Бүгенге эшчәнлегебездә нишләдек?<br>-Нәрсәгә өйрәндек?<br>-Дәрес башында үз алдыбызга нинди максат куйдык?<br>-Моның өчен нәрсәләр эшләдек?<br>-Максатыбызга ирештекме? | Монологик җаваплар. | Укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү. Белемнәрне үзләштерүне, аның сыйфатын билгели белү. |
| **Йомгаклау.** | Эшчәнлеккә нәтиҗә ясау | -Укучылар, сез дәрестә бик тырышып эшләдегез. Бүгенге эшчәнлегебезне төсле чәчәкләр ярдәмендә бәялик.<br>Кызгылт сары - дәрес ошады , барлык материалны аңладым<br>Яшел- дәрес ошады, материалларны бик аңлап бетерә алмадым.<br>Сары - материалны аңламадым. | Эшчәнлекләрен төсле чәчәкләр ярдәмендә бәялиләр. | Уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү. |